**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**

**ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ**

***Гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы***

**З.Н. Кириллова**

# Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (1920-1930 нчы еллар)

**Казан – 2015**

**УДК 373.167.1**

**ББК 81.2Тат**

*Гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы утырышында кабул ителде (беркетмә №1, 2015 елның 2 сентябре).*

**Фәнни мөхәррире:** К.С.Фәтхуллова, педагогика фәннәре кандидаты, доцент

**Рецензенты:** Г.Ә.Нәбиуллина, филология фәннәре кандидаты, доцент

**Кириллова З.Н.** Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (1920-1930 нчы еллар). – Казан: Казан ун-ты, 2015. – 301 б.

Хезмәттә татар теленең 1920-1930 нчы елларда тарихта беренче тапкыр рәсми рәвештә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүе, бу процессның иҗтимагый тормышның барлык өлкәләренә үтеп керүе тикшерелә.

Китап фәнни хезмәткәрләргә, югары уку йортында укытучыларга, аспирантларга, студентларга һәм, гомумән, татар теле һәм тарихы белән кызыксынучы киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**© Кириллова З.Н., 2015**
**© Казанский университет, 2015**

# Кереш

Җәмгыятьтә 80 нче еллар уртасыннан башланып киткән иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни үзгәрешләр, халыкларның милли үзаңы уяну милләт һәм тел сәясәтенең яңа нигезләрен барлыкка китерде. Россия халыкларының күпчелеге, үз телләренең функциональ үсеш дәрәҗәсе белән ризалашмыйча, аны максималь киңәйтергә омтылдылар. Шул омтылыш нигезендә башта элекке союздаш, аннары автономияле республикаларда телләр турындагы Законнар кабул ителеп, аларның бер өлешендә җирле халык теле генә, икенчеләрендә рус теле дә дәүләт теле булып игълан ителде: 1989 елда — Эстония (18 гыйнвар), Литва (25 гыйнвар), Латвия (5 май), Таҗикстан (22 июль), Молдавия (1 сентябрь), Казахстан (22 сентябрь), Кыргызстан (23 сентябрь), Үзбәкстан (21 октябрь), Украина (28 октябрь), Каракалпакстан (1 декабрь); 1990 елда — Беларусь һәм Төркмәнстанда һ.б. (Этническое, 1995, с. 18-19)[1].

1990 елда суверен республика дип игълан ителгән Татарстанда телләр турындагы Закон төзү эше 1989 елдан ук башланса да (Закиев, 1995, с. 451)[1], әлеге Закон 1992 елның 8 июлендә генә кабул ителде. Аның нигезендә, татар һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре булып расландылар (Суверенный Татарстан, 1998, с. 49). Шул ук елның 6 ноябрендә кабул ителгән ТР Конституциясендә дә дәүләт телләре хакындагы махсус маддә урын алды (Суверенный Татарстан, 1998, с. 60). 1994 елның 20 июлендә расланган «ТР халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы»нда (1996, б. 15-41) татар телен иҗтимагый тормышның төрле сфераларында куллану юллары билгеләнде. 1994 елның 29 июлендә ТР Министрлар Кабинеты каршында «ТР

[1] Хезмәтләрнең тулы исемлеге китап ахырында алфавит тәртибендә бирелде.

халыклары телләре турындагы» Законны гамәлгә кую Комитеты төзелеп, 1999 елның 7 октябрендә аңа кайбер үзгәрешләр кертелде, Комитет янында 6 комиссиянең: ономастика, халыкны татар теленә өйрәтү мәсьәләләре, рус һәм башка милләт (татарлардан башка) телләренә өйрәтүне камилләштерү, чит телләргә өйрәтү мәсьәләләре, татар телен куллануны тәртипкә салу, компьютер технологияләрендә тел сәясәтен гамәлгә кертү мәсьәләләре буенча комиссияләрнең нигезләмәләре һәм составлары билгеләнде.

Шулай итеп, республикада телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру буенча беренче җитди адымнар ясала башлады. Акрынлык белән булса да, татар теле мәгариф системасында, китап бастыруда, массакүләм мәгълүмат чараларында һ.б. өлкәләрдә үзенең функцияләрен сизелерлек киңәйтте. Дәүләт Советы сессияләрендә берничә мәртәбә татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре тикшерелде. Шул ук вакытта Татарстан кебек күп милләтле һәм күп телле республикада тел сәясәтенең зур авырлыклар һәм каршылыклар белән баруын да инкарь итеп булмый.

Татар телен гамәлгә кую мәсьәләсенең хәзерге чорда гаять актуальлеге, ирешелгән уңай һәм тискәре нәтиҗәләр безне үткәнгә борылып карарга мәҗбүр итә, узган тәҗрибәләрдән файдалану ихтыяҗын тудыра.

Борынгы бай язма традицияләргә ия татар теле XVII-XVIII йөзләрдә һәм XIX гасырның беренче яртысында Россиянең эчке сәясәтендә һәм Көнчыгыш илләр белән дипломатик мөнәсәбәтендә икенче дәүләт теле вазифасын башкара, һәм ул Казанда гына түгел, Россиянең бик күп шәһәрләрендәге уку йортларында өйрәтелә (Кононов, 1982, с. 129-200; Хисамова, 1981, с. 3-4; Тумашева и др., 1977, с. 54-56).

1992 елгы Законнан 71 ел элек — 1921 елда — татар теле беренче тапкыр рәсми рәвештә дәүләт теле булып игълан ителә (Сборник Декретов, 1925, с. 5-7), һәм бу карарны тормышка ашыру юнәлешендә киң эш тә җәелдерелеп җибәрелә.

Монографиядә беренче тапкыр җентекле һәм системалы рәвештә татар телен гамәлгә куюның (алга таба — ТТГК) гомуми мәсьәләләре, ТТГКның төп этаплары тасвирлана; татар телен төрле учреждение һәм Халык комиссариатларында, кантоннарда тормышка ашыру; ТТГК курс һәм түгәрәкләре эшчәнлеге тулы рәвештә яктыртыла; 20-30 нчы елларда әлеге процессның уңышка ирешә алмау сәбәпләре тикшерелә. Әлеге бай фәнни мирасны өйрәнү татар тарихы өчен дә, тел белеме өчен дә гаять әһәмиятле.

Хезмәтебезнең төп максаты итеп, Татарстан республикасының Милли архив материалларына нигезләнеп, 20-30 нчы елларда татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кертү мәсьәләләрен тикшерү куелды. Татар халкының шул чор тарихын яктырткан һәм татар тел белеме мәсьәләләренә багышланган фәнни хезмәтләр гаять күп булса да, 20-30 нчы елларны социолингвистик яктан, ягъни телнең җәмгыятьтәге урыны, аларның үзара мөнәсәбәте, тел сәясәте һ.б. мәсьәләләрне үзәккә куеп тикшергән хезмәтләр әлегә юк.

Хәзерге вакытта тел мәсьәләсенең гаять актуальлеге күп галим һәм белгечләрнең 20-30 нчы елларда барган аналогик процесска игътибарын көчәйтте. В.Хаковның «Татар әдәби теленең совет чорында үсеше» дип аталган монографиясендә (1985) татар телен гамәлгә кую процессының хөкүмәт дәрәҗәсендә оештырылуы беренче тапкыр тикшерелә башлады, шул ук вакытта төп игътибар бу чорда әдәби тел нормаларының үсешенә юнәлдерелде.

Вакытлы матбугат битләрендә һәм 1998 елның 17 ноябрендә булган «Татарстан республикасында телләрнең торышы: бүгенгесе

һәм киләчәге» фәнни-гамәли конференция материаллары тупланган җыентыкта З.Г.Гарипова (Татарстан. — 1992. — №9-10; 1997. — №6; Ватаным Татарстан. — 1994. — 20 июль; Языковая ситуация в РТ, с. 21-24), И.М.Низамов (Татарстан хәбәрләре. — 1992. — 16 май; 1998, б. 23-38), Ф.Ф.Исламов (Языковая ситуация в РТ, с. 24-28), Ф.М.Гәрәев (Гыйльми язмалар. — 1997. — №2), Г.Ә.Нәбиуллиналарның (Языковая ситуация в РТ, с. 40-43) 20-30 нчы еллардагы тел сәясәтен төрле яклап яктырткан мәкаләләре дөнья күрде.

Татарларда алфавит алмашыну кебек гаять катлаулы мәсьәлә тарихы Х.Р.Курбатовның ике монографиясендә бик җентекләп тикшерелгән (1960, 1999). Татар телен гамәлгә куюга зур өлеш керткән Г.Ибраһимов, М.Корбангалиев, Г.Шәрәф һ.б. күренекле шәхесләрнең эшчәнлеге һәм шәхес культы белән бәйле вакыйгалар монографик планда өйрәнелгән (Хасанов, 1977; Литвин, 1993; Вәлиев, 1996; Вәлиева, 1951; Рәхим, 1925; Султанбеков, 1994, 1995, 1996 һ.б.). Югарыда күрсәтелгән монографияләр булганга, әлеге мәсьәләләр хезмәтебездә махсус тикшерелмәде.

Чит илләрдә һәм Россия Федерациясендә телләрнең хәзерге торышына багышланган конференция материаллары һәм Россия Фәннәр академиясенең төрле гыйльми оешмалар тарафыннан төзелгән коллектив хезмәтләр, шулай ук күп санлы социолингвистик тикшеренүләр (Языковая ситуация в РФ, 1992; Проблемы языковой жизни, 1994; Языковые проблемы, 1994; Этническое, 1995; Аврорин, 1975; Бондалетов, 1989; Баскаков и др., 1995; Насырова, 1997 һ.б.) мәсьәләнең нигезен аңларга ярдәм итәләр.

Р.Г.Сибәгатовның дәүләт теле хакындагы җәмәгатьчелек фикере һәм фәнни карашларны Башкортостан мисалында тикшергән брошюрасы (1997), И.Низамовның дәүләт теле, социолингвистика

мәсьәләләренә багышланган күп санлы мәкаләләре (Мәгърифәт. — 1997. — 18 октябрь, 12 декабрь; Мәгариф. — 1997. — №12; 1998. — №4, 9; Татарстан. — 1999. — №1 һ.б.), Л.К.Бәйрәмованың Татарстандагы тел модельләрен тикшерү объекты итеп алган хезмәте (Научный Татарстан. — 1997. — №2) татар тел белемендә дә бүгенге чор социолингвистика проблемаларына игътибарның көчәюен күрсәтә.

Хезмәтебездә түбәндәге чыганаклар файдаланылды:

1) Татарстан республикасының Милли архив материаллары:

— Татарстан Халык комиссарлары Советы (ф. Р-128);

— Татарстан Үзәк башкарма комитеты (ф. Р-732);

— Татарстан мәгариф халык комиссариаты (ф. 3682) фондларында сакланган беркетмәләр һәм докладлар, карар һәм инструкцияләр, Татар телен гамәлгә кую Үзәк комиссиясенең айлык һәм еллык хисаплары, төрле учреждение һәм комиссариатлар белән татар телен тормышка ашыруның барышы хакында язышулары, Үзәк курслар һәм түгәрәкләр эшчәнлеген яктырткан һ.б. күп санлы документлар.

2) 20-30 нчы елларда басылып чыккан хөкүмәт карарлары, съезд һәм сессия материаллары, хисаплар, Татарстан республикасының биш еллыгы уңаеннан нәшер ителгән һәм татар телен гамәлгә кую хакындагы документларны туплаган җыентыклар.

3) Татарстанның шул чор вакытлы матбугат битләрендә урын алган аерым мәкаләләр («Красная Татария», «Известия ТатЦИКа», «ТҮБК известиеләре», «Татарстан хәбәрләре» газеталары һәм «Мәгариф» журналы).

Монографиядә файдаланылган күпчелек материаллар беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертеләләр.

Хезмәт «Татар әдәби телен дәүләт теле буларак гамәлгә куюның теориясе һәм практикасы (тарих һәм хәзерге чор)» фәнни проблемасының бер өлеше сыйфатында эшләнде (дәүләт регистрация номеры № 01970001445).

# 1 бүлек. Татар телен гамәлгә куюның гомуми мәсьәләләре

1.1. «Татар телен гамәлгә кую» (ТТГК) атамасы. 20-30 нчы елларда «татар телен гамәлгә кую», «телне тормышка үткәрү», «телне тормышка ашыру», «телне эшкә ашыру» кебек терминнар кулланылышта йөри башлый. Русчасы бер генә вариантта кулланыла: реализация татарского языка, ягъни РТЯ.

Бу терминнарның барысы да бер үк мәгънәне белдерә һәм, гомумән алганда, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү һәм шуның нәтиҗәләрен тормышка ашыру төшенчәсен бирә.

Мәгънәләре бер үк булса да, «татар телен гамәлгә кую» (кыскартып — ТТГК) атамасы башкаларына караганда күбрәк кулланыла, бары 20 нче еллар ахыры, 30 нчы еллар башында гына аларның башка вариантлары файдаланыла башлый. Шул сәбәпле бу хезмәтебездә без ТТГК атамасын нигез итеп алдык.

1.2. Татар телен гамәлгә куюның тарихи алшартлары. Татар халкының борынгы бабалары XVI гасыр уртасына кадәр үзләренең дәүләтчелегенә ия булалар, ләкин 1552 елда Казан ханлыгы көчләп Россиягә кушылдырылганнан соң, татарлар дүрт гасырга якын вакыт дәвамында изелеп, мөстәкыйль дәүләтчелек һәм татар теленең иң югары дәрәҗәдә кулланылуы хакында хыялланып яшәргә мәҗбүр булалар. Әмма шундый авыр шартларда да, галимнәр күрсәтүенчә, чыганаклары белән турыдан-туры Алтын Урда әдәби теленә барып тоташа торган (Хисамова, 1981, б. 7) иске татар теле, рәсми рәвештә булмаса да, дәүләт теле вазифасын үтәвен дәвам итә.

Татар ханлыкларының рәсми теле XV-XVI гасырларда рус-татар мөнәсәбәтләрендә функциональ тел буларак кулланыла. Казан һәм Кырым ханнары ярлыклары, татар ханнарына төрки телле

тәрҗемәләре белән җибәрелгән күп санлы дипломатик грамоталар — моңа ачык дәлил. Әлеге тәрҗемә-дубликатлар, шулай ук хан ярлыкларының рус теленә тәрҗемәләре Мәскәү канцелярияләрендәге татар тылмачлары ярдәмендә ясала (Тумашева и др., 1977, с. 52).

Иске татар теле XVII-XVIII йөзләрдә дә рус дәүләте эчендәге һәртөрле административ язышуларда актив кулланылуын дәвам итә. Татар, башкорт, мишәр старшиналарының генерал-губернаторлыкка язган донесениеләре, крестьяннар исеменнән язылган гарзнамә (челобитнаялар), күмәк хатлар, һәртөрле юридик документлар һ.б. иске татар телендә языла (Хисамова, 1981, б. 4). Шулай ук бөтен Идел һәм Урал буйларын иңләп күтәрелгән Крестьяннар сугышы (1773-1775) вакытында да Е.Пугачев исеменнән казах, башкорт һәм татарларга җибәрелгән указ һәм манифестлар, боерык һәм карарлар, өндәмә һәм мөрәҗәгатьләр, рапорт, хисап һәм башка бик күп сандагы документлар иске татар телендә язылалар яки, рус телендә төзелеп, татарчага тәрҗемә ителәләр (Тумашева и др., 1977, с. 54-56; Хисамова, 1981, б. 9-11).

Рус дәүләте эчендә генә түгел, XVII-XVIII йөзләрдә һәм XIX гасырның беренче яртысында Россиянең Көнчыгыш илләр белән дипломатик мөнәсәбәтендә дә иске татар теле зур роль уйный. Рус дәүләте исеменнән Кырымга, Төркиягә, Урта Азия ханлыкларына һәм шулай ук Иран, Һиндстан, Монголиягә җибәрелгән дипломатик документлар бу чорда башлыча иске татар телендә язылалар (Хисамова, 1981, б. 3-4), чөнки башка төрки телләр белән генетик һәм мәдәни-тарихи туганлык иске татар телен Урал буе, Казахстан һәм Урта Азиядә яшәүче күп санлы төрки телле халыкларга аңлаешлы итә (Тумашева и др., 1977, с. 54).

Россиянең эчке һәм тышкы сәясәтендә иске татар теленең икенче дәүләт теле вазифасын башкаруы әлеге телне белүче кадрлар әзерләү ихтыяҗын тудыра, гамәли тюркологиянең үсүенә китерә. Нәтиҗәдә XVIII йөзнең урталарыннан башлап Россиядә татар теле рәсми рәвештә өйрәнелә башлый. Бу вакыттан алып татар теле Казан, Мәскәү, С.-Петербург, Әстерхан, Оренбург, Тобол, Томск, Саратов, Ставрополь һәм Симферополь шәһәрләрендәге дөньяви характердагы гимназия, училище һәм университетларда укытыла (Кононов, 1982, с. 129-194). Канцелярия эшчәнлегенә нигездә шушы уку йортларында хәзерләнгән грамоталы татарлар белән бергә, иске татар язма әдәби телен үзләштергән башкорт, казах һ.б. төрки халыклар вәкилләре дә тартыла башлый (Хисамова, 1981, б. 7-8; Тумашева и др., 1977, с. 53).

Уку йортларында рәсми рәвештә татар теле өйрәтү татар теленнән грамматикалар, дәреслекләр, үзөйрәткечләр, сүзлекләр төзүгә ихтыяҗ тудыра. XIX гасыр башыннан алып руслар өчен, ә бу гасыр ахырыннан татарларның үзләре өчен гаять күп сандагы грамматикалар төзеп бастырыла (Кононов, 1982, с. 258-267), аларның беренчеләре рус һәм европа грамматикалары үрнәгендә язылса, икенчеләренә гарәп теле көчле йогынты ясый (Мифтахова, 1998, с. 3-4). XVIII йөз ахыры — XX гасыр башында руслар өчен 38 үзөйрәткеч һәм 2 сөйләүлек төзелүе мәгълүм (Юсупова, 1994, с. 6). XVII-XVIII йөзләрдә беренче чиратта сәүдә-икътисад мөнәсәбәтләре җирлегендә барлыкка килгән кульязма сүзлекләргә (Ногман, 1969. — 162 б.) алмашка С.Хәлфин, А.Троянский, Н.Остроумов, К.Насыйри, М.Юнысов, Н.Катанов һ.б. тарафыннан төзелгән күп санлы басма сүзлекләр килә (Кононов, 1982, с. 105-108; 266-267).

Тагын шунысы да игътибарга лаек: татар телен рәсми рәвештә өйрәнү чиновниклар әзерләү өчен генә түгел, ә татарларны

колонизацияләү һәм христианлаштыру максатында да алып барыла. Православие дине миссионерлары халыкларны христиан диненә күчерү эшен аларның телләрен, гореф-гадәтләрен өйрәнү аша башкаралар. XVIII гасыр ахырыннан башлап Әстерхан, Тобол, Нижегород, Сембер, Уфа, Оренбург, Самара, Томск, Вятск рухани семинарияләрендә, Казан рухани академиясендә, Нижегород, Пенза, Казан, Чистай, Оренбург, Пермь, Екатеринбург, Тобол рухани училищеларында һәм Алтай рухани миссиясендә булачак дини эшлеклеләр татар телен өйрәнәләр (Кононов, 1982, с. 194-200).

Гомумән, элек-электән башка халыкларны христиан диненә күчерү сәясәте алып барган рус хөкүмәте чит халыкларның, шул исәптән татарларның да, иҗтимагый-сәяси һәм рухи-мәдәни үсеше белән кызыксынмый, киресенчә, моңа һәрьяклап аяк чалырга тырыша. Шуңа күрәдер дә, большевикларның милли мәсьәләгә аерым игътибар юнәлтүләре бернинди хокуксыз хәлдә «инородец» булып яшәгән Россия халыкларында зур яклау таба. Барлык халыкларның һәм телләрнең тигез хокуклылыгы идеясе В.И.Ленин хезмәтләрендә һәм социал-демократлар (соңыннан — большевиклар) партиясенең программаларында 1895 елдан башлап эзлекле рәвештә дәвам итә (Ханазаров, 1982, с. 25). Шуның нәтиҗәсе буларак, 1917 елның октябрь ахырында Россиянең күп гасырлык тарихында беренче мәртәбә бу илдә яшәүче халыклар белән эш алып бару органы — Милләтләр эшләре халык комиссариаты (Наркомнац) төзелә, һәм аны Политбюро әгъзасы И.Сталин җитәкли (Солтанбәков һ.б., 1998, б. 33) (Ләкин әлеге комиссариат озын гомерле булып чыкмый: 1923 елның 7 июлендәге карар нигезендә юкка чыгарыла (Советская политика, 1928, с. 24)).

1917 елның 2(15) ноябрендә басылып чыккан һәм яшь совет хөкүмәтенең беренче документларыннан саналган «Россия

халыклары хокуклары декларациясе» буенча, Россия халыкларының тигезлеге һәм суверенлыгы; аерылып чыгып, мөстәкыйль дәүләт төзү мөмкинлеге биргән ирекле үзбилгеләнү хокукы; барлык милли һәм милли-дини өстенлекләрне һәм чикләүләрне бетерү; милли азчылык һәм этнографик группаларның ирекле үсеше тәэмин ителергә тиеш була (Советская политика, 1928, с. 1). Кызганычка каршы, моңа кадәр дә кызыл җеп булып барган барлык милләт эшчеләрен берләштерү идеясе алга таба милли мәсьәләдә дә өстенлек ала башлый. Милләтләргә үзбилгеләнү хокукы бары сыйнфый күзлектән чыгып кына бирелергә тиеш дип санап, тиздән ачыктан-ачык: бу хокук — асылда хезмәт ияләренең үзбилгеләнү хокукы ул, дип белдерелә (Солтанбәков һ.б., 1998, б. 33). Төрки-татарларның Идел-Урал штатын — милли-дәүләти автономияне — оештыру идеясе тормышка ашырыла алмый. 1920 елның 25 июнендә Татарстан автономияле республикасы төзү турындагы карарга кул куела (Советская политика, 1928, с. 95-97).

Милли мәсьәләгә күчерелгән сыйнфый көрәш идеясе гражданнар сугышы кабынып китүдә дә шактый зур роль уйный (Солтанбәков һ.б., 1998, б. 33-34). Канкойгыч гражданнар сугышында җиңүгә ирешкәннән соң, совет хөкүмәте яңадан милли мәсьәләгә әйләнеп кайта. Коммунистлар партиясенең X һәм XII съездларында, башка проблемалар белән бергә, милли мәсьәләгә дә зур урын бирелә. 1921 елның 8-16 мартларында Мәскәүдә узган X съезд карарлары аеруча игътибарга лаек, чөнки бу съездда рус булмаган халыкларның үсешен тизләтү буенча партиянең бурычлары итеп түбәндәгеләр билгеләнә (монда һәм алга таба тәрҗемә безнеке — З.К.): «...б) җирле халыкның тормыш-көнкүрешен һәм психологиясен яхшы белгән шул як кешеләреннән төзелгән һәм аларның ана телендә эш алып баручы суд,

администрация, хуҗалык органнары, хөкүмәт органнарын үстерергә һәм ныгытырга; в) ана телендәге матбугат, мәктәп, театр, клуб эше һәм, гомумән, мәдәни-агарту учреждениеләрен үстерергә; г) идарә итүнең барлык тармакларында һәм беренче чиратта мәгариф өлкәсендә эшләү өчен рус булмаган халыклар арасыннан квалификацияле эшчеләр һәм совет-партия хезмәткәрләрен әзерләүне тизләтү максатында, ана телендә эшләүче курслар, гомуми белем бирү һәм профессиональ-техник характердагы мәктәпләрнең киң челтәрен булдырырга һәм үстерергә (беренче чиратта кыргызлар, башкортлар, төркмәннәр, үзбәкләр, таҗиклар, азәрбайҗаннар, татарлар, дагстанлылар өчен)» (КПСС в резолюциях. Т. 2, 1983, с. 366).

1923 елның 17-25 апрель көннәрендә булган XII съездда әлеге нигезләмәләр кабат расланып, тагын да үстереләләр. Бу мәсьәлә буенча кабул ителгән маддәләрнең беренчесе, нигездә, X съезд карарларын кабатлау булып тора: «милли республикалар һәм өлкәләрнең органнары әлеге халыкларның телен, тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен белгән җирле кешеләрдән төзелергә тиеш». Икенчесе исә тагын да алга китеп, «җирле халыкка һәм милли азчылыкка хезмәт күрсәтүче барлык дәүләт органнарында һәм барлык учреждениеләрдә ана телен куллануны тәэмин итүче, милли хокукларны һәм аеруча милли азчылык хокукларын бозучыларны ... хөкем итүче һәм җәза бирүче махсус законнар чыгарылырга тиеш» (КПСС в резолюциях. Т. 3, 1984, с. 86).

Нәкъ шушы ике съезд карарларына нигезләнеп, 20 нче елларда союздаш һәм автономияле республикалардагы украин, грузин, үзбәк, әрмән, азәрбайҗан, мордва, татар һәм башка дистәләгән телләр үз республикалары чикләрендә дәүләт теле итеп игълан ителә. Бу процесс төрле җирдә төрлечәрәк бара. Күпчелек очракта республика

атамасында чагылыш тапкан җирле халыкның теле республиканың директив органнары карарлары нигезендә дәүләт теле итеп игълан ителә. Әлеге карарларда дәүләт теле хакындагы нигезләмәне тормышка ашыру, аны дәүләт аппаратында, суд һәм прокуратурада, җирле хакимият органнарында, халык мәгарифендә, вакытлы матбугатта һәм һәр җирдә куллану буенча конкрет чаралар билгеләнә. Мәсәлән, Урта Азия республикаларында, Татарстанда һ.б. бу процесс шул рәвешчә үтә.

Шул ук вакытта кайбер республикалар төп җирле халыкның телен дәүләт теле итеп игълан итү хакында карар чыгару һәм аны тормышка ашыру буенча эш алып бару белән генә чикләнмиләр, үзләренең конституцияләренә бу хакта аерым маддәләр дә кертәләр. Мәсәлән, өч союздаш республика — Грузия, Әрмәнстан, Азәрбайҗанның — һәм бер автономияле — Абхаз республикасының конституцияләрендә дәүләт теле хакындагы маддәләр урын ала. Башка республикаларның конституцияләрендә исә мондый маддәләр билгеләнми (Ханазаров, 1982, с. 57-58).

Күренгәнчә, җирле халык телен дәүләт теле итеп игълан итү процессы 20 нче елларда барлык республика һәм өлкәләрдә дә киң рәвештә җәелеп китә һәм Татарстан автономияле республикасы да әлеге агымнан читтә калмый.

1.3. <u>Беренче Декрет һәм эшнең башлануы</u>. Татар телен рус теле белән бер дәрәҗәдә дәүләт теле итеп игълан иткән Декрет 1921 елның 25 июнендә, ягъни Татарстан республикасының бер еллыгы көнендә кабул ителә. Ул татар халкының элек-электән хыялында яшәп килгән теләкләрен тормышка ашыру юлында гаять әһәмиятле адым була һәм дистә елдан артык вакытка сузылган бик кирәкле, ләкин зур каршылыклар белән барган процесска этәргеч бирә. Татарстан Үзәк Башкарма комитеты (ТҮБК) рәисе Б.Мансуров, аның

сәркатибе Т.Гайнуллин, Татарстан Халык комиссарлары советы рәисе Сәетгалиев имзалары куелган һәм 11 маддәдән торган Декрет түбәндәге карарларны эченә ала: 1) барлык дәүләт оешмаларында татар теле мәҗбүри итеп куела. Җәмәгать, кооператив һәм профессиональ оешмалар исә татар телен үз ихтыярлары буенча кертәләр; 2) бу нигезләмәне планлы һәм тиз арада тормышка ашыру максатында, ТҮБК карамагында аның бүлеге хокукында Татар телен гамәлгә кую Үзәк комиссиясе (ТТГК ҮК) төзелә. ...Комиссия карарлары барлык совет оешмалары өчен мәҗбүри итеп куела; 3) татар телен гамәлгә куюда Мәгариф комиссариаты тарафыннан эшләнгән яңа орфография мәҗбүри итеп санала. Мәгариф комиссариатына шулай ук ... махсус терминология комиссиясе төзү бурычы куела; 4) Мәгариф комиссариатына теләгән хезмәткәрләр өчен татар теле курслары ачу эше йөкләнә; 5) барлык 2 нче баскыч рус мәктәпләрендә теләгәннәр өчен — татар теле, ә татар мәктәпләрендә рус теле укытылырга тиеш була; 6) үз вакытында ябылган татар мәктәпләрен (дини мәктәпләрдән тыш) ачу; 7) татар театрларын үстерү бурычы куела. Шулай ук татар судлары ачу, элемтә өлкәсендә татарча телеграммалар кабул итү, барлык оешмаларның декрет һәм карарларын татар телендә нәшер итү, оешмаларда тәрҗемәчеләр бюросы төзү турында да сүз бара (ф. 732, оп. 1, д. 49, лл 3-4; Сборник Декретов, 1925, с. 5-7. Алга таба — Сб.).

Ләкин Декрет чыгу белән үк, тулы канлы эш башлана алмый, ул беренче елларда, нигездә, декларатив характерда гына булып кала. Бер яктан, дәүләт, хөкүмәт органнарында эшләүче татар хезмәткәрләренең бик аз санны тәшкил итүе, икенчедән, татар телен генә түгел, рус телен дә яхшы белгән һәм квалификацияле татарларның аз булуы Декрет карарларының тормышка ашырылуына комачаулый. Шулай ук 1921 елгы коточкыч ачлык һәм

аның нәтиҗәләре дә эшне киң җәелдерергә мөмкинлек бирми. Азрак тернәкләнгәч, тамак кайгысыннан рухи кыйммәтләргә дә игътибар итә алырлык хәлгә җиткәч, 1922 елның урталарыннан гына яңа декрет һәм карарлар чыга башлый. Татар телен дәүләт оешмаларында гына түгел, кооперативларда, профсоюзларда, кантон һәм волостьларда, авыл советларында гамәлгә кую мәсьәләләренә багышлана бу карарлар (Сб., 1925, с. 8-16). Шуннан соң гына чын мәгънәсендә зур кампания башланып китә.

1.4. ТТГКның максат һәм бурычлары. Татарстан республикасы шартларында ТТГКның төп бурычлары итеп түбәндәгеләр билгеләнә: 1) барлык дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында татар һәм рус телләренең юридик һәм практик тигез хокуклылыгын булдыру; 2) күбрәк татар халкына хезмәт күрсәтүче оешма һәм предприятиеләрдә татар телендә эш башкаруның актив формасын кертү, шул ук вакытта рус телендә пассив эш алып баруны да саклау, ягъни рус азчылыгы өчен телдән һәм язмача аңлашуларны рус телендә алып бару; 3) күбрәк рус халкына хезмәт күрсәтүче учреждениеләрдә татар телендә пассив эш алып бару; 4) милли азчылыкка (чуваш, мари, мордва һ.б.) телдән ана телендә аңлашу, ә язмача аларга уңайлырак булган дәүләт телендә эш йөртү мөмкинлеге бирү; 5) ана телендә телдән һәм язмача эш йөртүне, беренче чиратта, түбән совет аппаратында: авыл советларында, волость башкарма комитетларында, фабзавкомнарда, җирле комитетларда, беренчел кооперативларда, суд һәм тикшерү алып бару участокларында, милициядә һәм башка оешмаларда урнаштыру, шуннан соң гына югарырак органнарны тәэмин итү. Татарстан республикасының 10 еллыгына, ягъни 1930 елга, татар теле тулысынча гамәлгә куелып бетәргә тиеш дип санала (За 5 лет, 1925, с. 39-40).

Ләкин бу чараларны тормышка ашыру үз чиратында башка бурычларны үтәү белән тыгыз бәйләнгән була: 1) аппаратка татар хезмәткәрләрен күпләп җәлеп итү; 2) яңаларын төрле белгечлекләр буенча кыска сроклы курсларга, уку йортларына татарларны күпләп кабул итү юлы белән әзерләү; 3) рус хезмәткәрләренә һәм югары уку йортларында укучы русларга татар телен өйрәтү; 4) волость, район һәм аерым ведомстволар линиясе буенча участокларның чикләрен мөмкин булганча теге яки бу телнең территориаль таралышы чикләре белән туры китерү; 5) барлык мәдәни-икътисади пунктларны (мәктәп, китапханә, хастаханә, агроном һәм ветеринар пунктлары, элемтә оешмалары, кооператив берләшмәләр һ.б.) татар массаларына якынлаштыру; 6) татар телен техник яктан дәүләт теленә яраклы итү (терминология һәм эш башкару формаларын эшләп чыгару, нәшер итү эше, язу машиналарын хәзерләү һ.б.) һәм 7) татар пролетариаты үсеше өчен шартлар тудыру (За 5 лет, 1925, с. 40; Отчет ЦИК и СНК к 5-му съезду Советов, 1925, с. 20-21).

1.5. <u>ТТГК Үзәк комиссиясе эшчәнлеге</u>. Шундый күп сандагы һәм катлаулы бурычларны эченә алган ТТГК эше белән махсус төзелгән даими ТТГК ҮК җитәкчелек итә. Аның оештырылу вакыты турында төрле фикерләр яшәп килә: документларда әле 1922 ел, әле 1923 ел күрсәтелә. Ләкин ТҮБК президиумы утырышы беркетмәсеннән күренгәнчә, ТТГК ҮК 1921 елның 12 сентябрендә үк төзелә, һәм аның эшчәнлеген шул вакытта башланып киткән дип карасак, дөресрәк булыр. Яңа төзелгән комиссиянең рәисе итеп ТҮБК рәисе Р.Сабиров, әгъзалар итеп ТҮБК әгъзалары Слуцкий һәм Г.Шәрәф сайлана (ф. 732, оп. 1, д. 49, л. 48).

1.5.1. <u>Төзелеше</u>. Комиссиянең үзеген тәшкил иткән президиум гадәттә түбәндәге хезмәткәрләрне үз эченә ала: рәис, җаваплы сәркатип, эш башкаручы һәм берничә әгъза. 1921 елда президиум

һәм барлык комиссия дә 3 кешедән генә торса, 1925 елда президиумның составы 5 кешегә җиткерелә: рәис, сәркатип һәм ТҮБК президиумы тарафыннан билгеләнүче 3 әгъза (Сб., 1925, с. 28). 1926 ел башыннан комиссия президиумы тагын 2 кешегә арттырыла: мәҗбүри рәвештә аның составына Юстиция комиссариаты һәм Эшче-крестьян инспекциясеннән дә берәр әгъза керергә тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 26). 1930 елда исә ул кабат 3 кешегә генә калдырыла (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 345).

Президиум кебек үк, ҮК әгъзаларының саны да гел үзгәреп тора. Бөтен хезмәткәрләре 2-3 кешедән артмаган хәлдә эшли башлаган комиссиянең составы, 1922 елның 13 декабрендәге карар нигезендә, 9 кешегә җиткерелә (ф. 732, оп. 1, д. 117б, л. 1). 1924 елда — 13, 1927 елда исә комиссия исемлегендә хәтта 15 әгъза һәм 5 кандидат исеме теркәлгән (ф. 732, оп. 1, д. 136, л. 23).

Комиссия рәисе вазифасын һәрвакыт ТҮБК председателе башкара. Комиссия эшчәнлеге дәвамында аеруча Рәүф Сабиров, Гали Ганиев, Шәйгардан Шәймәрдановлар рәислек иткән вакытта ТТГК буенча әһәмиятле эшләр башкарыла.

Җаваплы сәркатип хезмәтен гадәттә ТҮБК секретарьлары үти. Бары күренекле галим Галимҗан Шәрәф кенә бу кагыйдәдән чыгарма булып тора. Ул комиссия эшчәнлегенең иң авыр вакытларыннан саналган оештырылу дәверендә (1921-1923) сәркатип булып тора, соңрак официаль рәвештә ҮК әгъзасы итеп кертелмәгәндә дә, аны фәнни хезмәткәр буларак файдалану һәм һәрбер хезмәте өчен аерым түләү турында карар кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 24 об.). Г.Шәрәфтән соң бер-бер артлы эшләгән ТҮБК сәркатипләре Николай Петров һәм Кариб Вәлиевләр дә ТТГК эшенә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

ҮКда әгъза булып югары органнарда эшләүчеләр: ТҮБК, Халык комиссарлары советы әгъзалары, төрле комиссариат һәм оешма җитәкчеләре билгеләнә. Аларның саны һәм составы гел алмашынып торганга күрә, 10 елдан артык вакыт дәвамында комиссиядә әгъза булып торганнарның барысын да санап китү бик зур урынны алыр иде. Шулай да кайберләрен генә булса да күрсәтеп үтү ТТГК эшенең 20-30 нчы елларда дәүләтнең барлык өлкәләренә дә үтеп кергәнлеген ачык дәлилли: Борындыков М. (ТҮБК), Чанышев Х. (НКВД), Мохтаров К. (СНК), Бронштейн (Коммунистик университет), Хәйруллин К. (РКИ), Максудов (НКПрос.), Корбангалиев М. (Гыйльми үзәк), Сәйфи Ф. («Татарстан» газетасы, НКЗем.), Измайлов (НКТруд), Палютин (НКЮст.), Еникеев С. (ВКП(б)), Рагс (ТСПС), Кетура (Вахитов исемендәге завод), Бакеев (РЛКСМ), Галанин (Совторгслуж.) һ.б.

Комиссиянең барлык әгъзалары да катнашында була торган пленар утырышлар кимендә айга ике тапкыр, чираттан тыш җыелышлар исә кичекмәстән уздырыла. Президиум ТТГК мәсьәләләрен һәр атна саен җыелып хәл итә. Комиссиянең барлык әгъзалары да һәр утырышка кичекмичә килергә һәм игътибарга алынмаслык сәбәпләр белән килми калганнарга дисциплинар тәэсир итү чаралары күрелергә тиеш була. Нинди дә булса җитди сәбәп белән килә алмаган очракта, бу турыда язма рәвештә сәркатипкә мөрәҗәгать итәргә кирәк дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 26).

Үзәк комиссиянең ТҮБК карамагында оештырылуы эшкә зур булышлык итә. Җаваплы сәркатип җитәкчелек иткән техник аппарат, нигездә, ТҮБК эш башкаручысыннан, машинисткадан тора. Татарча шрифтлы машинкада эшләүче иң беренче чиратта ТТГК ҮК эшләрен башкарырга тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 26). ТҮБК әгъзалары комиссия эшендә һәрвакыт ярдәм итеп торалар. Кирәк

булган вакытларда ҮК аларны инструкторлык эшендә дә файдалана (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 24 об.).

1.5.2. Инструкторлар эшчәнлеге. Инструкторлар күпчелек очракта комиссиянең даими штатына кертелмиләр, вакытлыча эшләүче хезмәткәрләрдән саналалар, саннары да бер яки икедән артмый. Шулай да алар ТТГК эшендә әһәмиятле урынны билиләр. ҮК тарафыннан җибәрелгән инструкторларның төп бурычлары итеп дәүләт оешмаларына, кайбер очракларда кантоннарга барып, анда ТТГК эшенең куелышы һәм барышын тикшерү куела. Аларга ҮК тарафыннан бирелгән наказга күз салыйк (текст үзгәртелмичә бирелә — З.К.):

«1. Инструктор учреждениегә баргач, эш башлаганчыга кадәр, иң элек учреждениенең юлбашчыларына һәм өчле комиссия әгъзаларына мөрәҗәгать итеп, үзенең ник килгәнен, ни эшләячәген әйтеп үтәргә, алардан рөхсәт сорарга һәм булышлык күрсәтүләрен үтенергә кирәк.

2. Инструктор үзен бик тигез тотарга, учреждениедә эшләүчеләр белән яхшы, шома мөнәсәбәттә булырга, ләкин кемгә булса да яхшылык кылу уе белән язачак нәрсәне беркетми калдырмаска, кимчелекләрне әйтми китмәскә тиешле.

3. Тикшерүне кулына бирелгән сораулар буенча ясап, һәр нәрсәне кыска гына язып барырга һәм шуларны бергә җыеп, кыскача язма доклад әзерләргә тиешле.

4. Тикшерү беткәннең соңында, эшнең нәтиҗәсен, татарчалаштыру эшендә бу учреждениедә нинди чаралар күрелергә тиешлеге турында администраторлар һәм өчле комиссия әгъзалары белән бергә киңәшмә чакырып, шунда кыскача доклад ясарга кирәк. Әгәр администратор яки өчле комиссия әгъзалары тарафыннан инструктор чыгарган нәтиҗәләргә каршылык булса, аларга

үзләренең игътиразларын (каршылык күрсәтү, протест белдерү — З.К.) Үзәк комиссиягә язып бирергә кушарга кирәк.

5. Инструктор үзенең тикшерү нәтиҗәсен һәм үзенең фикерен Үзәк комиссиягә язма хәлдә тапшырыр. Әгәр тикшерү эше шул тикшерелгән учреждениенең ҮК утырышында доклад ясаган вакытына туры килсә, инструктор, әлбәттә, өстәмә доклад ясарга тиешле булыр» (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 90). Оешмалар да үз чиратларында инструкторларга ярдәм итәргә тиеш булалар һәм бу инструкторларга бирелгән мандатларда да басым ясап күрсәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 155).

ҮКда инструктор булып түбәндәге кешеләрнең эшләве мәгълүм: 1922 ел ахырында — Гафаров Габдулла (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 173), 1923 елның 1 сентябреннән 1924 елның апреленә кадәр — Хәмзин Кәшфи (ф. 732, оп. 10, д. 25, лл. 93-95), 1924 елның 1 мартыннан 1 августына кадәр — Юнысов Нәҗип (ф. 732, оп. 10, д. 25, лл. 3-5), 1924 елда вакытлыча гына — Гайнуллин Талип (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 57), Зәйнетдинов Ибраһим (ф. 732, оп. 10, д. 25, лл. 112-113), Космин Алексей (ф. 732, оп. 10, д. 25, лл. 209-210), Ибраһимов Мирза (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 256) һ.б.

Инструкторлар арасында бу өлкәдә тәҗрибә туплаганнары да, эшкә очраклы рәвештә килеп кергәннәре дә була. Аларның кайберләренә тукталып үтик. Гафаров Габдулла — Хөсәения мәдрәсәсен бетергән, Казан университетының медицина факультеты студенты, русларга да татар теле укыта, укытучыларның Бөтенроссия съезды делегаты, Кызыл антны татар теленә тәрҗемә иткән... (ф. 732, оп. 10, д. 25, лл. 168-169); Космин Алексей — укытучылар мәктәбен, Мамадышта 3 еллык педагогик курсларны бетергән, анда татар теле укыткан, Алабуга һәм Мамадыш өяз мәгариф хезмәткәрләре конференцияләрендә һәм керәшеннәрнең

Казандагы Бөтенроссия съездында президиумда эшләгән, Казанда Мәгариф комиссариатының милли азчылык бүлеге мөдире булган, ТТГК Үзәк курсларында хуҗалык мөдире булып эшләгән, шуннан ҮКга инструктор итеп күчерелгән (ф. 732, оп. 10, д. 25, лл. 209-210); Хәмзин Кәшфи — Мөхәммәдия мәдрәсәсен бетергән, 1921 елда Украинада милли азчылык советы карамагында инструктор булып эшләгән, 1922 елда Украина Мәгариф комиссариатының татар-башкорт үзәген җитәкләгән, шул ук елның августында ТСНК үтенече буенча Татарстанга җибәрелгән, анда Ревтрибуналда, өлкә судында эшләп, 1923 елның сентябреннән, сәламәтлеге начар булуга да карамастан, инструктор булып эшли башлаган (ф. 732, оп. 10, д. 25, лл. 93-95); Юнысов Нәҗип — Галия мәдрәсәсендә укыган, моңа кадәр Җир эшләре комиссариатында эшләгән, профессиясе — «халык укытучысы» (ф. 732, оп. 10, д. 35, л. 3); Зәйнетдинов Ибраһим — революциягә кадәр Алафузов заводында буяучы булып эшләгән, 40 нчы заводта наданлыкны бетерү мәктәбендә укыткан (ф. 732, оп. 10, д. 25, лл. 112-113), русчасы бик начар.

Инструкторларның саны бик аз булганлыктан, аларга күбесенчә бер үк вакытта берничә оешма яки кантондагы ТТГК эшен тикшерергә туры килә. Тикшерү вакыты да озакка сузылырга тиеш булмый. Мәсәлән, Юнысовка 1924 елның 26 апрелендә Җир эшләре комиссариаты, Коммуналь хуҗалык идарәсе һәм алар карамагындагы оешмаларда ТТГК карарларының үтәлешен тикшерү бурычы куела (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 137). 9 майда исә ул инде Чистай, Чаллы, Алабуга һәм Минзәлә кантоннарын тикшерү өчен җибәрелә (ф. 732, оп. 1, д. 526, л.155).

ТТГК ҮКда эшләүче инструкторлар нигездә Казандагы оешмаларны гына тикшерергә тиеш булсалар да, алар еш кына кантоннарга да чыгып китәләр. Чөнки һәр кантонда

инструкторларның саны берәр генә була, ягъни барысы — 12 инструктор, һәм аларга бөтен кантондагы волость һәм авылларны тикшереп бетерү өчен бик күп вакыт таләп ителә.

ТТГК инструкторларының, аеруча кантондагыларның, эшләре бик катлаулы һәм шул ук вакытта аз түләнә торган хезмәтләрдән санала. Шулай да аларның күбесе үз эшләрен җиренә җиткереп, намуслы рәвештә башкаралар, үзәк оешмалар яки кантоннарда ТТГК эшенең ничек баруы турында тулы мәгълүмат бирәләр.

1.5.3. Үзәк комиссиянең бурыч һәм хокуклары. 1921 елның көзеннән үк бөтен Татарстан республикасындагы ТТГК эше белән җитәкчелек итеп килсә дә, ҮКның нигезләре, бурыч һәм хокуклары 1925 елның 4 мартында гына ТҮБК карары нигезендә билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 37).

ТТГК Үзәк комиссиясенең төп бурычлары итеп түбәндәгеләр күрсәтелә: 1) Татарстан республикасында ТТГКның гомуми мәсьәләләрен эшләү һәм аларны законлы тәртиптә тормышка ашыру; 2) Татарстан республикасы оешма һәм предприятиеләренең ТТГК белән бәйле эшләренә гомуми җитәкчелек итү; 3) ТТГК чараларын тормышка ашыруга, шулай ук ТРгы оешма һәм предприятиеләрнең ТТГКга турыдан-туры яки өлешчә кагылган эшчәнлегенә күзәтчелек итү; 4) татар телен яисә бер үк вакытта татар һәм рус телләрен белүче хезмәткәрләрне исәпкә алу һәм эшкә урнаштыру; 5) курслар һәм группалар оештыру, шулай ук ТРның ике дәүләт телен дә белгән хезмәткәрләр әзерләү буенча башка чаралар да күрү; 6) ТТГК белән бәйле техник мәсьәләләрне эшкәртү һәм үтәү өчен чаралар күрү (эш башкару буенча татар телендә форма һәм терминнар эшләү, язу машиналарын әзерләү, кулланмалар нәшер итү һ.б.); 7) Татарстан республикасы халык массалары арасында үзәк һәм җирле хакимиятнең гомумән милли мәсьәләгә

һәм, аерым алганда, җирле телләрне гамәлгә куюга кагылышлы чараларын популярлаштыру; 8) җирле телләрне гамәлгә кертү мәсьәләләре буенча СССРның башка милли өлкәләре һәм республикалары белән бәйләнештә булу (Сб., 1925, с. 27).

1.5.3.1. <u>ТТГК эше белән җитәкчелек итү, законнар чыгару</u>. Күренгәнчә, беренче өч бурыч ТТГКга кагылышлы законнар чыгару һәм Татарстан республикасы чикләрендә бу эш белән гомуми җитәкчелек итүгә багышланган. Чыннан да, күп еллар дәвамында ҮК дистәләгән инструкцияләр, карар һәм положениеләр чыгара, аларны ТҮБК ярдәме белән татар һәм рус телләрендә бастырып чыгаруга ирешә.

Үзәк комиссия Татарстан республикасындагы 50ләп оешмада, алар карамагындагы учреждениеләрдә һәм 12 кантонда ТТГК эшләрен оештыра, алар белән җитәкчелек итә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 37). Шундый күп сандагы оешмаларның ТТГК эшчәнлеге белән идарә итү бер комиссия өчен генә, билгеле, бик авыр булыр иде. Эшне җиңеләйтү максатыннан, һәр комиссариатта һәм үзәк оешмаларда диярлек ТТГК өчле комиссияләре, ә кантоннарда 5 кешедән торган комиссияләр төзелә (Сб., 1925, с. 28-29). Бу комиссияләр ҮК карамагында эшлиләр һәм ҮК алардан ТТГК эшенең ничек баруы турында хисаплар таләп итә, инструкторлар җибәреп, тикшерүләр үткәрә, үз инструкцияләре һәм боерыкларының ни дәрәҗәдә үтәлүен белү өчен, анкета сораулары җибәрә, оешма яки кантон җитәкчеләренең докладларын тыңлый һ.б. (Сб., 1925, с. 28).

1.5.3.2. <u>Татар хезмәткәрләрен исәпкә алу һәм эшкә урнаштыру</u>. ТТГК ҮК озак еллар буе татар хезмәткәрләрен исәпкә алу һәм эшкә урнаштыру белән шөгыльләнә. Бу эш ҮКның бик күп вакытын һәм көчен ала. Ләкин барлык хезмәткәрләрне дә эшкә урнаштыру

вазифасын үтәүче Хезмәт Биржасы татар эшчеләренә игътибар биреп җиткерә алмый. Ул коточкыч авыр шартларда эшли: иң түбән гигиена таләпләренә дә җавап бирмәүче салкын, дымлы, пычрак бинага көн саен 3-5 мең кеше кереп тула һәм Биржа хезмәткәрләренә эшләр өчен бернинди мөмкинлекләр дә булмый. Аеруча кара эшчеләр, совет хезмәткәрләре һәм транспорт эшчеләре секцияләрендә хәлләр мөшкел була (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 72). Биржа хезмәткәрләренең саны да күп булмый — барлыгы 15 кеше, һәм алар арасында татарлар я бөтенләй булмый, я бик аз санны тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 73). Хезмәт комиссариатының 1923 елгы карары нигезендә, «бер ел туктамыйча ялланып эшләгән квалификациясез эшчеләргә һәм өч еллык өзлексез стажга ия булган, хәзерге вакытта эшсез хезмәткәрләргә» льготалар һәм пособиеләр бирелергә тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 73 об.). Ләкин түбән квалификацияле, законнарны белмәүче татарлар үзләре эшләгән оешмалардан кирәкле документларны алмыйлар, аларны ничек алырга икәнен дә белмиләр. Җитмәсә, бу елларда күп кенә учреждениеләр ябылу сәбәпле, документлар алу мөмкинлеге дә калмый. Нәтиҗәдә кулларында тиешле белешмәләр булмаган татар эшсезләренең 99%ы льгота һәм пособиеләрдән мәхрүм кала (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 72).

Күпме йөреп тә эш таба алмаган, соңгы чиккә җиткән татарлар ахыр чиктә бөтен өметләрен ТТГК ҮКга юнәлтәләр. Төрле язмышлы кешеләр: эш эзли-эзли азапланып беткән казанлылар, авыллардан, башка шәһәр һәм республикалардан килгәннәр, курслар бетергәннәр, уку йортларыннан матди хәлләре бик авыр булган студентлар һ.б. комиссиягә эш сорап мөрәҗәгать итәләр. Архивта аларның гаризалары һәм анкеталар тупланган 3526 битле 7 дело саклана (ф. 732, оп. 10, дд. 43, 44, 50, 51, 55, 56, 57). Анкеталардагы сораулар

ике телдә дә язылган, эшсезләр аларга үзләре теләгән телдә җавап бирәләр. Гаризаларны да я русча, я татарча язу мөмкинлеге бирелә.

ҮК эшсез калган татарларга булдыра алганча ярдәм итәргә тырыша. Аларның анкеталарын һәм гаризаларын карап, ике телне дә белгәннәрен төрле комиссариатларга, оешмаларга һәм кантоннарга җибәрә һәм тиешле эш бирүләрен үтенә, яки, кайсы өлкәдә татарларның җитешмәвен исәпкә алып, шунда ук нинди белгечлек буенча эшкә урнашырга тиешлеген хәбәр итә. Татар телен белмәгәннәре исә Хезмәт Биржасына җибәрелә (ф. 732, оп. 10, д. 55, л. 14). ҮК үзе эшкә җибәргән кешеләрнең урнашканмы-юкмы икәнлеге турында белешеп тора (ф. 732, оп. 10, д. 55, л. 321). Берәр оешмада татар хезмәткәре эштән чыгарылса, оешма җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп, мондый эшнең булырга тиеш түгеллегенә басым ясый (ф. 732, оп. 10, д. 55, лл. 215-216). Кайбер оешмалар кирәкле белгечләрне үзләре эзләп табалар һәм ҮКның ул кешеләргә юллама бирүен үтенеп мөрәҗәгать итәләр.

ҮК тарафыннан эшкә җибәрелгән татар эшчеләренең саны хакында төгәл мәгълүматлар бик аз сакланган һәм алары да төрле чыганакларда төрлечәрәк бирелә. Мәсәлән, бер чыганакта 1923 елның 1 гыйнвареннән 30 ноябрьгә кадәр ҮК 230 кешене эшкә җибәргән дип күрсәтелсә (ф. 732, оп. 1, д. 527, лл. 1-4), икенче чыганакта тулаем 1923 елда эшкә юлланган эшчеләрнең саны 208гә генә калдырыла (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 9). Шул ук чыганакта 1924 елда үзәк оешмаларга һәм кантоннарга 326 кешенең эшкә җибәрелүе һәм 37сенең кире кайтарылуы, 1925 елда бу саннарның 356 һәм 50гә җитүе хакында мәгълүматлар бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 9). 1925 елның 1 октябренә ҮКда 177 татар эшчесе исәптә тора. Квалификацияләре һәм саннары буенча алар түбәндәгечә бүленәләр: канцелярия эшчеләре — 10, бухгалтерлар — 2, хисапчылар — 8,

статистлар — 1, машинисткалар — 2, мәктәп хезмәткәрләре — 25, тәрҗемәчеләр — 3, салым хезмәткәрләре — 1, тәрбиячеләр — 2, приказчиклар — 26, квалификацияле эшчеләр — 9, квалификациясезләр — 17, укучылар — 35 һәм квалификацияләрен билгеләп булмый торганнар — 36 (ф. 732, оп. 1, д. 766, л.8). Күренгәнчә, татар эшсезләре арасында бөтенләй квалификациясез яки аны билгеләп булмый торганнар, укучылар, приказчиклар һәм мәктәп хезмәткәрләре күпчелекне тәшкил итә.

ҮК юллаган эшчеләрне оешмаларның «эшкә сәләтсез» дип кире кайтару очраклары бик күп була. Монда, бер яктан, белемнәре анкеталар һәм әңгәмә нигезендә генә билгеләнгән, махсус тикшерү аша үтмәгән татарларның җитәрлек әзерлекле булмаулары зур сәбәп булып тора (ф. 732, оп. 1, д. 768, л. 56), икенче яктан, оешмалар да хезмәткәрләргә артык зур таләпләр куялар, тиз арада гына белемле һәм тәҗрибәле татар белгечләре әзерләнеп җитә алмавын исәпкә алмыйлар. Андый оешмаларга ҮК кат-кат мөрәҗәгать итә, хөкүмәт карарларының үтәлергә тиешлегенә басым ясый, хәтта кайбер очракларда җавапка тарту белән куркыту юлына басарга да мәҗбүр була (ф. 732, оп. 10, д. 55, л. 323).

Эшкә урнаштыру процессында килеп чыккан бәхәсле мәсьәләләрне һәм конфликтларны хәл итү ҮКның бик күп вакытын ала, үзенең төп эшен башкарырга комачаулый, ҮК күрсәтүенчә, «комиссиянең эшкә сәләтен һәм авторитетын төшерүгә сәбәп була» (ф. 732, оп. 1, д. 1367, л. 1). Нәтиҗәдә 1927 елдан ҮК гадәттән тыш очракларда гына һәм анда да югары квалификацияле һәм стажлы хезмәткәрләрне генә эшкә урнаштыру буенча эш алып бара, калганнары Хезмәт Биржасына тапшырыла. ҮКның 1929 елның 1 ноябреннән 1930 елның апреленә кадәрге эш планына исә «... хезмәткәрләрне эшкә җибәрү функциясен комиссиядән алып, аны

тулысынча Хезмәт комиссариатына тапшыру, бары махсус курс бетергәннәрне генә ҮК карамагында калдыру хакында ТҮБКга мөрәҗәгать итәргә» дигән маддә кертелә (ф. 732, оп. 1, д. 1367, л. 1).

Шулай итеп, татар хезмәткәрләрен исәпкә алу һәм эшкә урнаштыру белән озак еллар шөгыльләнгән ҮК күп кенә татарларны эшле итүгә ирешә, ләкин ахыр чиктә бу мәсьәләне тулысынча хәл итә алмый һәм моңа аның мөмкинлекләре дә булмый.

1.5.3.3. Курслар оештыру. Татарларны эшкә урнаштыруга зур киртә булып торган квалификациясез эшчеләр мәсьәләсен хәл итү, ягъни аларга төрле белгечлекләр буенча белем бирү максатында, ҮК карамагында 1922 елның июлендә ТТГК Үзәк курслары төзелә. Бу курсларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә 15ләп белгечлек буенча татар хезмәткәрләре әзерләнә.

Шулай ук русларны да татар теленә өйрәтү һәм моның белән ике дәүләт телен дә белүче хезмәткәрләр әзерләү максатында, 1921 елдан башлап төрле үзәк оешмаларда, комиссариатларда һәм кантоннарда русларга татар теле өйрәтү курс-түгәрәкләре эшли башлый. Бу түгәрәкләр үз чоры өчен гаять әһәмиятле эш башкаралар.

1.5.3.4. Татарча шрифтлы машинкалар әзерләү. Оешмалар эш алып баруны билгеле бер күләмдә татарчага күчермәсәләр, дәүләт аппаратына татар хезмәткәрләрен җәлеп итүдән бернинди мәгънә дә чыга алмас иде. Учреждениеләрдәге татар хезмәткәрләренең саны еллар үткән саен әкренлек белән булса да арта бара, ләкин аларның да күбесе рус телендә эш башкарырга мәҗбүр була, чөнки аппаратта татарча шрифтлы язу машинкаларының булмавы зур комачаулык тудыра. Бу бигрәк тә татар районнарында күзәтелә. Шулай ук күп кенә өлкәләр буенча терминологиянең эшләнеп бетмәве, татарча эш

кәгазьләре формаларының аз булуы да ТТГК эшенә аяк чала (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 11).

Гарәп шрифтындагы татарча язу машиналары җитешмәүнең төп сәбәбе — бу эш өчен акча булмау. 1923 елда ТТГК ҮК үзәккә 64 татарча язу машинасы алу өчен акча бирүләрен сорап мөрәҗәгать итә. Машиналарны яңа орфографиягә нигезләнгән реформалашкан шрифтка көйләү эше башлана (Отчет ЦИК и СНК ТССР за время с 3-го по 4-й съезд Советов, 1923, с. 44). Ләкин бу эш әле бик әкренлек белән бара.

1925 елда гына ҮК катнашы белән Казанда татарча язу машиналары әзерләүче махсус мастерской (татарча текстларда да атамасы шулай бирелә — З.К.) төзелә. Ул бик зур мәшәкатьләр белән Нәшрият комбинаты (Татгиз) карамагында оештырыла. ҮК мастерской белән 100 рус машинкасын үзгәртеп кору, ягъни һәр машинаны русча да, татарча да баса алырлык итеп ике шрифтка да көйләү турында килешү төзи. Машиналарны үзгәртеп кору 1925 елның июненә тәмамланырга тиеш була (Отчет ЦИК и СНК к 5-му съезду Советов, 1925, с. 38). Ләкин Комбинатның эшкә салкын каравы нәтиҗәсендә, 1925 елның октябрь ахырына да план үтәлми (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 1). Хәтта 1926 елга да барлыгы 55 машина гына әзерләнә (Отчет ЦИК ТССР за 1926 год, с. 35).

Татарстан республикасының барлык оешмалары һәм кантоннары өчен 55 машина гына, билгеле, бик аз була. Алдагы 2-3 елда кимендә 300 татарча шрифтлы машина таләп ителә (Отчет...за 1926 г., с. 35).

Татарчага күчерү өчен мастерской карамагында машиналар булмау сәбәпле, ҮК аларны учреждениеләрдән җыя. Мәсәлән, 1925/26 елларда оешмалар тарафыннан 48 машинка ҮКга тапшырылырга тиеш була, нәтиҗәдә 32 машинка тапшырыла,

ларның да 12се үзгәртеп коруга яраксыз булып чыга һәм 6сы гына татар шрифтына күчерү өчен мастерскойга җибәрелә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 67).

Мастерской заман таләпләренә җавап бирә алмый: матди кыенлыклар кичерү сәбәпле, тулысынча төзелеп тә бетми, машиналарны да оешмаларның заказы буенча, тар кустарчылык юлы белән генә эшли ала, шунлыктан русча шрифтлы машиналарны татарчага үзгәртеп кору белән генә чикләнә дә, лаборатория ягы эшләнеп бетми, хокуклары җитәрлек булмый һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 32).

1926 елда татарча язу машиналары мастерскоеның куелышы, барышы һәм киләчәгенә багышланган ике утырыш булып үтә. Аларның беренчесе 15 февральдә ТҮБКның утырышлар залында була. Киңәшмәдә ТТГК ҮКдан җаваплы сәркатип К.Вәлиев, ТҮБКдан Г.Измайлов, Нәшрият комбинатыннан Л.Хөснуллин, язу машиналары мастерскоеннан Шәйхегали, белгечләрдән Г.Алпаров һәм Г.Шәрәфләр катнаша (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 30).

Фикер алышулар һәм бәхәсләшүләр нигездә мастерскойның матди яктан авыр хәле, моннан чыгу өчен акционерлык җәмгыяте төзү идеясе тирәсендә бара. Фикерләр икегә аерыла: К.Вәлиев һәм Г.Измайлов акционерлык җәмгыяте ягында булалар, аларга Г.Алпаров, Г.Шәрәф һәм Л.Хөснуллиннар каршы чыга, Шәйхегалинең бу мәсьәләгә карата фикерләре китерелми. Ике яктан да берничә фикерне тыңлап карыйк. Измайлов: «...төрле урында төрле белгечләр тарафыннан татарча язу машиналары эшләргә керешүләр бар. Боларны бер җиргә тупларга, бөтен белгечләрдән көчле бер оешма ясарга, моның өчен дә язу машиналары акционерный обществосы төзергә керешергә кирәк. Моңар татар җөмһүриятеннән 100-150 мең акча җыярга мөмкин булган кебек,

гарәп хәрефләре белән эш күрә торган Кыргызыстан, Төркестан, Азәрбайҗан кебек шәрык хөкүмәтләрендә дә бер-ике йөз мең акция табарга мөмкин булачак. Шул вакытта гына татарча язу машиналары мастерскоен төзәтергә, камилләштерергә мөмкин булачак, шул вакытта гына чыгарышын күтәреп булачак, шул вакытта гына организация ныгыячак һәм машиналар арзан төшәчәк» (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 31 об.).

Г.Шәрәф: «...акцияле общество төзесәк тә, аңар язылучы булмас. Бу бары бер матур теләк булып кына калыр. Минемчә, бу мастерской — бөтен шәрык халыкларына кирәкле булган яңа бер нәрсәне эшләп чыгара торган сәнәгать урыны. Яңа төр сәнәгатькә үзәк ярдәм бирергә тиешле. Шул юл белән бер йөз мең сум акча табып булса, мастерскойны яхшы юлга салып булыр иде. Без акцияле оешмалар төзедек, ләкин күбесе дәвам итә алмады. Бу мастерской хакында шулайрак булып чыкмасын. Шәрык милли җөмһүриятләренә үзебездә эш тиешле юлга салынганчыга кадәр акциягә язылырлар дип ышанып бетеп булмый» (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 31 об.).

Л.Хөснуллин: «Акцияле общество төзү — яхшы эш. Ләкин төзеп тә, ул барып чыкмаячак. Чөнки без әле мастерскойның массовый эшен күрсәтә алмадык. Безнең мастерскойда җитешсезлекләр күп булган кебек, эшләнеп чыккан язу машиналарында да кимчелекләр юк түгел. Аннан соң бездә хәреф мәсьәләсе дә тәмам өзелеп беткән мәсьәлә түгел әле. Шунлыктан башка шәрык җөмһүриятләре белән уртак акция хакында баш вату — артык бер нәрсә. Хәзергә безгә Татарстан эчендә генә уйларга, Татарстанны машиналандыру турында кайгыртырга кирәк. Үзебездә тәмам төзәлеп, камилләтеп беткәннең соңында башка җөмһүриятләр белән мөнәсәбәткә керергә туры килә. Хәзергә ничек тә акча табып,

аны тулыландыру чарасын күрергә кирәк (ф. 732, оп. 1, д. 767, лл. 31-31 об.).

Г.Алпаров: «... мәсьәләне артык күпертергә, эшне бик киң күләмдә куярга ашыкмаска кирәк. Бездә шулкадәр шапырынырлык эш күренгәне юк әле. Башта мастерскойның эшен күрсәтә белергә кирәк, яхшы реклама ясарга тырышыйк. Хәреф мәсьәләсе чишелмәгән. Моңа тюркология съезды бик киң күләмдә тукталырга тиешле. Без шул съездга яхшы эшләнгән татарча бер язу машинасы җибәрсәк, бик урынлы реклама ясаган булыр идек» (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 31). Шулай ук Г.Алпаров үз тарафыннан берничә теләк тә күрсәтеп үтә: «1) татарлардан төрле җирләрдә язу машинасы ясарга маташып йөрүче бөтен белгечләрне таркау хәлдә яшәтмәскә, аларны Казанга тартырга, бергә тупларга, шуның өчен дә мастерскойны, әлбәттә, яхшылатырга, киңәйтергә, аңар матди һәм мәгънәви ярдәм күрсәтергә кирәк; 2) машиналарны чит илләрдән китерткәндә, җыйнаграгын, арзанрагын, мөмкин булса, хәрефсезен китертергә чараларын күрергә кирәк. Бу машиналарны арзанга төшерергә ярдәм итәр; 3) мастерскойның ремонт эшен бөтенләй чыгарып ташларга туры килмәс, бу аңар материальный яктан да ярдәм итәр...» (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 31).

Каршы якның ышандырырлык дәлилләренә дә карамастан, К.Вәлиевнең алдан ук әзерләнгән тәкъдиме кабул ителә: «... материальный һәм оешу ягыннан ныграк эзгә төшерер өчен, мастерскойны акцияле ширкәт төзеп алып баруның күп яклардан файдалы булуын игътибарга алып, шул мәсьәләне ныграк тикшерүне үзәк тел комиссиясенә (ТТГК ҮК — З.К.) тапшырырга» (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 30). Моннан тыш, мастерскойга кагылышлы түбәндәге әһәмиятлерәк карарлар кабул ителә: «1) мастерскойны тиешле юлга салыр өчен, аның механизациясендәге җитешмәгән кисәкләрне

барларга һәм аны камилләштерергә...; 2) моның өчен дә үзәкнең милли фондыннан ярдәм сорау мәсьәләсен куерту белән бәрабәр, милли фонд мәсьәләсе чишелгәнчегә кадәрле Совнаркомнан 30 мең сумлык субсидия сорап торуны тиешле органнар аркылы сорарга кирәк; 3) мастерскойны табышлы ясап, машиналарны күп чыгару, арзанга төшерү һәм Татарстанда машиналарга булган мохтаҗлыкны тутыру оборотка 60-70 мең акча табып, машиналарны читтән китергәндә генә һәм аңар тышкы сәүдә халык комиссариатыннан лицензия (рөхсәт кәгазе) алган вакытта гына мөмкин булачак. Шунлыктан акча табу юлларын эзләү белән бәрабәр лицензия алу мәсьәләсендә якын киләчәктә эшләнергә тиешле эшләрдән санап, учреждениеләрдән тиешле кәгазьләр аркылы сорау чарасына керешергә кирәк; 4) татарча язу машиналарын башка шәрык җөмһүриятләре өчен дә танышу өчен якын көннәрдә Баку шәһәрендә җыелачак тюркология съездына, комбинат выставкасының экспонатлары белән бергә, яхшы эшләнгән татарча бер язу машинасы җибәрергә һәм аның белән бергә пөхтә басылган берничә кәгазьләр җибәрергә, шул мастерскойны киңәйтү һәм аны акцияле ширкәт оештырып, шуның кулына тапшыру турында җөмһүриятләрдән килгән вәкилләр арасында фикер салуны Галимҗан иптәш Шәрәфкә тапшырырга» (ф. 732, оп. 1, д. 767, лл. 30-31 об.).

1926 елның 30 мартында булган һәм мастерскойның язмышына кагылышлы икенче утырышта тавыш бирү хокукы белән ҮК рәисе Г.Ганиев, сәркатип К.Вәлиев, Шәйхегали, киңәш бирү хокукы белән В.Шәфигуллин, Г.Измайлов, Г.Шәрәф һәм М.Мәрҗаниләр катнаша (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 32). Киңәшмәдә татарча язу машиналары эшләү турында Мөхәммәд Идрисинең яңа проекты карала, шулай ук мастерскойның хәзерге хәле һәм киләчәк язмышы яңадан алгы

планга чыга. Беренче җыелыштагы фикерләр кабатланып, «...Татарстан хөкүмәтенең чынлап катнашуы белән «татарча язу машиналары эшләп чыгаручы акцияле ширкәт» төзергә һәм бу мастерскойны 11-12 мең сумлык төзелеше (оборудованиесе) белән шул ширкәт кулына «төп мая» (нигез ташы) итеп тапшырырга кирәк» (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 32 об.) дигән карар кабул ителә. Моннан тыш, «һөнәрханәнең хәзер үк акча ярдәменә мохтаҗ булуын игътибарга алып, ТҮБК һәм Халык комиссарлары шурасының үзләренең хисабына булса да 7-8 мең сум чамасында ярдәм бирүләре тиешле» дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 32 об.).

ТҮБК президиумы 1926 елның 11 июнендә татарча язу машиналары эшләп чыгаручы акционерлык җәмгыяте төзү өчен 5 әгъзадан торган оештыру комиссиясе булдыру турында карар кабул итә (ф. 732, оп. 1, д. 768, л. 231). Оештыру комиссиясенең рәисе итеп ТҮБК рәисе Г.Ганиев билгеләнә һәм аңа комиссиянең утырышларын җыю бурычы йөкләнә. Нәшрият комбинатына исә 1 июльдән дә соңга калмый татарча язу машиналары механика мастерскоен барлык җиһазлары, бинасы, эчке канцеляриясе, эш кәгазьләре һәм хезмәт күрсәтүче штаты белән оештыру комиссиясенә тапшырырга тәкъдим ителә (ф. 732, оп. 1, д. 768, л. 232).

Ләкин бер-бер артлы үткәрелгән киңәшмәләр һәм югары органнар тарафыннан кабул ителгән карарларга да карамастан, татарча язу машиналары эшләп чыгаручы акцияле ширкәт төзү идеясе хыял гына булып кала. 1927 елның 12 мартында ТҮБКның 3 нче сессиясендә ясаган чыгышында ТҮБК һәм ТТГК ҮК рәисе Ш.Шәймәрданов үзенең фикерен түбәндәгечә белдерә: «...без акцияле ширкәт төзи алырбызмы яки юкмы — ахыр чиктә, эш анда да түгел, ә эш шунда : безнең мастерской өчен акча кирәк. Әгәр акча булса, акцияле җәмгыятьтән башка да яшәргә була, акча булса,

мастерскойны машиналар эшләрлек итеп көйләргә мөмкин, әгәр дә инде акча булмый икән, ул вакытта эшләр бөтенләй начар...» (Доклад ЦК по РТЯ на 3 сессии ЦИК ТССР 12-13 марта 1927 г., с. 17. Алга таба — Доклад).

1927 елның ахырына мастерской 85 татарча шрифтлы язу машинасы чыгара. Ул заман өчен яңалык булып торган бу эштә мастерской шактый зур уңышларга ирешә, һәм ул Татарстанда гына түгел, башка көнчыгыш республикалар тарафыннан да танылa. Ләкин, бер яктан, эчке җиһазларны яңарту өчен һаман акча булмау, икенче яктан, чит илләрдән очсыз машиналар кертү нәтиҗәсендә, мастерской учреждениеләрнең таләпләрен канәгатьләндерә алмый (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 12). Чит илләрдән кертелгән гарәп шрифтындагы машиналарны да үзгәртеп корырга туры килә һәм нәтиҗәдә бу эш өстәмә чыгымнар гына тудыра.

1928 елның 5 июлендә республикада татарча шрифтлы 144 язу машинасы кулланылышта йөри (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 15). Шул ук елда Америкадан 50 язу машинасы кертү өчен лицензия алуга ирешәләр һәм аларның бер өлеше Татарстанга килеп тә җитә. Әлеге машиналар гарәп һәм латин шрифтларына үзгәртелә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, лл. 42-43).

Язу машиналарын латин шрифтына күчерү эше 1929 елда тагын да көчәя. Бу елда барлыгы 170 татарча шрифтлы язу машинасының 60ы яңалифкә күчерелә. Мастерской тулысынча машиналарны латин шрифтына күчерүгә көйләнә. СССРда беренче мәртәбә үз көчләре тарафыннан уйлап табылган конструкцияле өр-яңа машиналар чыгара башлый. Машиналарны җитештерү техникасын яңарту һәм Америкадан китертүне туктату юлы белән машиналарның бәясен очсызландыру мөмкинлеге ачыла башлый. Беренче чорларда бер

машина 600-700 сум тәшкил итәргә тиеш булса, әкренләп аның бәясен 200-300гә төшерү уйланыла (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 34).

1930 елда да язу машиналарын яңалифкә күчерү буенча эш тулы көченә алып барыла. ТТГК ҮК һәрбер учреждение һәм предприятиегә алардагы машиналарның саны, яңалиф шрифтындагысы, русчасы, гарәпчәсе, эшкә яраксызы, нинди системада булуы турында мәгълүмат җибәрүләрен сорап, әзер формалар җибәрә (ф. 128, оп. 1, д. 1065, л. 14).

1929 елның 1 ноябреннән 1930 елның апреленә кадәрге чор өчен планында ҮК үз карамагында эшләүче мастерской эшчәнлегенә контроль ясау һәм тикшерү мөмкинлеге булмавын билгеләп үтә. ТҮБК президиумыннан мастерскойны тикшерү өчен махсус комиссия төзетү, нәтиҗәдә мастерскойны Халык хуҗалыгы советына (ТСНХ) тапшыру мәсьәләсен эшләү кирәклегенә басым ясала (ф. 732, оп. 1, д. 1367, л. 1).

Ләкин 1930 елның 26 январендә булган ТҮБК президиумы утырышы беркетмәсеннән күренгәнчә, ТТГК ҮК карамагында татарча шрифтлы язу машиналары эшләүче мастерскойны Татполиграфка бирү хакында карар кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 1367, л. 60). Беренче бишьеллыкның ахырына — 1932 елга исә тар кустарчылык юлы белән эшли торган мастерской куәтле язу машиналары фабрикасына әйләнә (Абрамов, 1933, с. 10).

Шулай итеп, 1930 елга кадәр ҮК Татарстан республикасы оешмаларын һәм кантоннарны татарча язу машиналары белән тәэмин итү бурычын кулыннан килгәнчә үтәп килә. Акча юклык озак еллар буе машиналарга кытлыкның төп сәбәбе булып тора. Бу сәбәпне юкка чыгару өчен күп санлы карарлар кабул ителсә дә, алар гамәлдә тормышка ашырылмыйлар.

1.5.3.5. Башка республикалар белән бәйләнеш. ТТГК ҮКның башка республикалар, өлкәләр белән бәйләнеше Америкадан язу машиналары китертү, үзе эшләгәннәрне төрки телле халыкларга тарату белән генә чикләнми, ул Башкорт телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе, Мари телен гамәлгә кую өлкә комиссиясе, Удмурт телен гамәлгә кую өлкә комиссиясе, Азәрбайҗандагы төрки телне гамәлгә кую үзәк комиссиясе, Кыргызыстан, Төркмәнстан, Белоруссия республикаларының аппаратка җирле халыкны тарту (коренизация) комиссияләре, Идел буе немецлары автономияле республикасының үзәк башкарма комитеты белән ана телен гамәлгә кую эшенең торышы хакында актив хәбәр алыша һәм моны тәҗрибә уртаклашу максатында башкара (ф. 732, оп. 1, д. 780, лл. 1-70). Хәбәрләшү милли республикаларда телне гамәлгә куюга кагылышлы әһәмиятлерәк декрет, инструкция, карар һәм планнарны бер-берләренә җибәрү, алмашу рәвешендә алып барыла. ТТГК ҮК эшчәнлеге дә башка республикаларда кызыксыну уята. Мәсәлән, Мари телен гамәлгә кую өлкә комиссиясе ТТГК ҮК тарафыннан Татарстан республикасының 5 еллыгына чыгарылган җыентыкка «...комиссия өчен генә түгел, барлык кантон һәм өлкә бүлекләре өчен дә идарә итү һәм мәгълүмат бирү буенча гаять кыйммәтле материал» дип бәя бирә һәм 1925 елның 8 сентябрендә бу җыентыкны 30 экземплярда соратып алдыра (ф. 732, оп. 1, д. 780, л. 2).

Шулай ук ТТГК ҮК Татарстаннан читтә яшәүче татарларның үтенечләрен дә игътибарсыз калдырмый. Мисал өчен, 1924 елда Кострома губернасы һәм өязе, Татар бистәсе авылында яшәүче Абызов Нәҗипнең татар телен өйрәтү дәреслекләре сорап язган гаризасын икенче көнне үк канәгатьләндереп, комиссия аңа 25 данә «Беренче адым» дәреслеген тапшыра (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 56).

Башка республикалардан Татарстанга күчеп килгән татарларга да ТТГК ҮК һәрвакыт ярдәм күрсәтә, эшкә урнашырга булыша.

1.6. ТТГКның төп этаплары. 20-30 нчы елларда барган ТТГК процессын этапларга бүлү ул вакытта да, аннан соң да эшләнмәгән. Бу мәсьәләне без күп санлы документлар һәм чыганаклар буенча нәтиҗәләр ясап хәл итәргә тырыштык. Ләкин кайбер чыганакларның бик үк объектив булмавы яки аларда фактларны, эшләнгән эшләрне арттырып күрсәтергә омтылыш мәсьәләне шактый катлауландыра. Шулай да аларны хронологик тәртиптә куеп, бер-берсе белән чагыштыра-чагыштыра тикшерү ниндидер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

ТТГК процессын түбәндәге этапларга бүлергә мөмкин:

I. ТТГК эшенең башлану, оештырылу һәм беренче нигезләре салыну этабы (1921-1924).

II. Эшне план нигезендә алып баруга күчү, алдагы елларга йомгак ясау этабы (1925-1926).

III. «Аппаратка җирле халыкны тарту» ягына борылыш этабы (1927-1936).

Әлеге этапларның ни өчен шулай билгеләнүен дәлилләү өчен, аларга аерым-аерым күзәтү ясыйк.

I. 1921 елда ТТГК буенча эшләнгән эшләрне гадәттә 25 июньдәге Декрет белән генә чиклиләр, бу фактны әйтү белән үк 1922 елга, яки тагын да соңрак вакытка күчәләр. Чыннан да, рәсми рәвештә татар телен дәүләт теле итеп игълан итүнең яңа күренеш булуы, бу өлкәдәге тәҗрибәсезлек, революция, сугыш, дәһшәтле ачлык нәтиҗәләре, ТТГК буенча Декрет чыгарып та, аның пунктларын тормышка ашыру өчен тиешле шартлар һәм мөмкинлекләр булмау башлангыч чорда эшне гаять дәрәҗәдә катлауландыра. Ләкин 1921 елгы бик авыр чорда да ТТГК ҮК атна

саен җыелып, татар телен дәүләт теле буларак тормышка ашыру мәсьәләләрен хәл итү белән шөгыльләнә. Мәсәлән, ТҮБК президиумының хисапларыннан күренгәнчә, 1921 елның октябреннән 1922 ел башына кадәр ҮК тарафыннан түбәндәге эшләр эшләнә: Декрет карарларын тормышка ашыру өчен чаралар күрелә башлый (ф. 732, оп. 1, д. 59, л. 28), татар халкы күпчелекне тәшкил иткән урыннар исәпкә алына, Сан алу идарәсеннән Татарстандагы халык саны турында мәгълүмат алына (ф. 732, оп. 1, д. 59, л. 30), күп кенә комиссариатлардан ТТГКны ничек үткәрүләре сораштырыла (ф. 732, оп. 1, д. 59, л. 29), уку йортларында укучыларның саны, аларның милләте турында мәгълүматлар туплана, ВУЗ студентларының исемлеге төзелеп, анкеталар ярдәмендә матди хәлләре дә тикшерелә (ф. 732, оп. 1, д. 59, лл. 37-38), декабрьдә Мәгариф комиссариатында татар телендәге административ терминнар эшләп чыгару буенча махсус комиссия төзелә, шәһәр коммуналь бүлегенә урам исемнәрен ике телдә дә язарга тәкъдим ителә (ф. 732, оп. 1, д. 59, л. 36). Болардан тыш, бу чорда шулай ук ТТГК буенча инструкцияләр, карарлар хәзерләнә, кантон комиссияләре нигезләмәсе эшләнә, татар теле буенча чыгарылган китапларның исемлеге төзелә, Декретны халык арасында популярлаштыру эше алып барыла, ҮКның составы билгеләнә һәм даими рәвештә утырышлар уздырыла һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 59, лл. 30-36). Күренгәнчә, 3-4 ай эчендә дә ТТГК процессын башлап җибәрү, билгеле бер юлга салу, оештыру ягыннан шактый зур эшләр башкарыла.

1922 елның гыйнварендә ТҮБК һәм ТТГК ҮК рәисе Р.Сабиров тарафыннан Өлкә комитетында комиссия эше хакында доклад ясала, нәтиҗәдә ҮКның эшчәнлеге канәгатьләнерлек дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 59, л. 39). Февральдә комиссиянең ике генә утырышы булуы

мәгълүм, аларның беренчесендә Татарстанның этнографик картасын төзү бурычы куела (ф. 732, оп. 1, д. 54, л. 88), икенчесендә Декрет яңадан каралып, аңа кайбер үзгәрешләр кертелә (ф. 732, оп. 1, д. 59, л. 43). Шуннан соң ике ай буе татар теленең гамәлгә куелышы хакында бернинди мәгълүмат бирелми, чөнки ачлык фаҗигасе булу сәбәпле, ничек булса да ачларга ярдәм итү турында сүз бара (ф. 732, оп. 1, д. 59, л. 43).

1922 елның маеннан гына бер-бер артлы инструкция һәм карарлар чыгарыла башлый. Бу вакыттан башлап, ел ахырына кадәр барлыгы 4 әһәмиятле карар барлыкка килә: 8 майда 1921 елгы Декретның дәвамы буларак һәм аңа өстәмә рәвешендә ТҮБК карары игълан ителә (Сб., 1925, с. 8-9), 13 майда канткомиссияләрнең (Сб., 1925, с. 9-10), ә 17 декабрьдә ТТГК Үзәк курсларының (Сб., 1925, с. 17-18) төп нигезләре басылып чыга. 21 декабрьдә исә иң әһәмиятлесе һәм соңыннан оешмаларны тикшерүдә нигез булып торган «ТАССР дәүләт учреждениеләре һәм прредприятиеләрендә ТТГК буенча инструкция» кабул ителә (Сб., 1925, с. 10-15).

1923 ел карарларга бай булмый. Бу елның 20 июнь һәм 18 августларында шәхси таныклыклар турында (Сб., 1925, с. 16), 21 сентябрьдә мөһер, штамп һәм эленмә такталарны (вывеска) ике телдә дә язу хакында (Сб., 1925, с. 15-16) кыска гына карарлар чыгарыла. Шул ук елда ТҮБК һәм Халык комиссарлары советының басма хисапларында ТТГК эше беренче тапкыр дәүләт күләмендә аерым алып һәм җентекләп яктыртыла (Отчет за время с 3 по 4 съезд Советов, 1923, с. 34-44) һәм әлеге хисаплар 1927 елга кадәр даими рәвештә басылып килә.

Татарстандагы карарлардан тыш, 1923 елның 23 ноябрендә СССР ҮБК рәисе М. Калинин, аның сәркатибе А. Енукидзе, СССР Халык комиссарлары советы рәисе урынбасары Л. Каменев

имзалары белән «1923 ел үрнәгендәге акча берәмлекләрен СССР конституциясенең 34 нче маддәсендә күрсәтелгән телләрдәге язулар белән әйләнешкә чыгару хакында» карар игълан ителә (ф. 732, оп. 1, д. 114, л. 870). Бу карар нигезендә, 1923 елда 100, 250, 500, 1000, 5000 һәм 10000 сумлык акчалар рус, украин, белорус, әрмән, грузин һәм төрки-татар телләрендәге язулар белән чыгарга һәм СССРның барлык территориясендә кулланылышта йөрергә тиеш була.

1924 ел — ТТГК эшенең аеруча җанланган вакыты. Карар һәм инструкцияләр чыгару да бу елда бик нык арта. Аларның аеруча әһәмиятлеләрен түбәндәгеләр тәшкил итә: 1) 14 апрель: «Дәүләт органнарында эш башкаруны җирле халык теленә күчерү чаралары хакында» Бөтенроссия ҮБКсы декреты (Сб., 1925, с. 47-48); 2) 30 апрель: «Дәүләт учреждениеләрендә ТТГК чаралары хакында» элек чыгарылган инструкциянең дәвамы (Сб., 1925, с. 18-20); 3) 30 апрельдәге карарга өстәмә рәвешендә «Кооперативларда ТТГК буенча» чыгарылган зур күләмле инструкция (Сб., 1925, с. 20-23); 4) 6 сентябрь: кантон башкарма комитеты рәисләре киңәшмәсе карары (Сб, 1925, 39-40); 5) 22 сентябрь һәм 6 декабрь: Халык хуҗалыгы советы (ТСНХ) һәм Профсоюзлар советының (ТСПС) мөрәҗәгатьләре (Сб., 1925, с. 41-46); 6) 23 декабрь: учреждениеләрдәге рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтүче курс-түгәрәкләрнең төп нигезләре (Сб., 1925, с. 24-26) һ.б.

1924 елда булган ике зур җыелышта: 28 апрельдәге партия өлкә комитеты пленумында (Сб., 1925, с. 37-38) һәм 15 июньдәге ТҮБКның 2 нче сессиясендә (Сб., 1925, 30-37) татар телен гамәлгә куюның торышы, нәтиҗәләре, киләчәк язмышы хакында ҮК рәисе Г.Ганиевның җентекле докладлары тыңлана һәм резолюцияләр кабул ителә.

Күренгәнчә, 1921-1924 еллардагы эшчәнлек нәтиҗәсендә ТТГКның юнәлешләре, бурыч һәм максатлары тулысынча билгеләнеп җитә. ТТГК эшләре белән җитәкчелек итү өчен махсус төзелгән ҮК үзенең эшчәнлеген җәелдерә, күп санлы карар һәм инструкцияләр әзерләп чыгара, үзәк оешмалар һәм кантоннар белән бәйләнеш булдыра, аларның докладларын һәм хисапларын тыңлый, инструкторлар җибәреп тикшерә, дәүләт оешмаларын гына түгел, кооператив һәм профсоюзларны да ТТГК эшенә җәлеп итә, татар белгечләре әзерләү эшен җайга сала, русларны татар теленә өйрәтү курсларын ачуга этәргеч бирә, татарларны эшкә урнаштыру вазифасын да үз өстенә ала һәм башка бик күп эшләр башкара. Ләкин шундый зур тырышлыклар куелса да, гомумән алганда, ТТГК эше бик акрын бара. Башта ничектер җиңел генә, булачак авырлыкларга әһәмият бирмичәрәк башланып киткән эшнең тиз һәм көч түкмичә генә бармаячагы аңлашыла башлый. Әлеге хәлне китереп чыгарган акчасызлык, кайбер җитәкче һәм хезмәткәрләрнең битарафлыгы яки тискәре мөнәсәбәте, белемле һәм квалификацияле татар белгечләре җитешмәү һәм башка бик күп сәбәпләр белән бергә, эшнең тотрыклы бер система булып, план нигезендә алып барылмавы да авырлык тудыра.

II. 1925 елның 30 январендә, ниһаять, ТТГКның перспектив планы ТҮБК президиумы тарафыннан раслана һәм басылып чыга. Зур күләмле әлеге документ авыл советларында, волостьларда, кантон һәм районнарда, үзәк оешмаларда татар теленең ничек гамәлгә куелышын, аның гомуми мәсьәләләрен тикшерүне үз эченә ала, шулай ук 1925 елдан алып 1930 елга кадәр, ягъни 5 елга, якынча календарь план тәкъдим ителә (Сб., 1925, с. 48-59). Гомумиләштереп әйткәндә, 5 ел дәвамында эзлекле рәвештә татар халкы күпчелекне тәшкил иткән авыл советлары, волость һәм кантоннарда татар

телендә эш башкаруга күчеп бетү, үзәк оешмалар һәм кантоннардагы татар хезмәткәрләренең гомуми санын 40%ка җиткерү, әкренлек белән барлык комиссариатлардагы эш башкаруда татар һәм рус телләренең тигез хокуклылыгына ирешү, оешмалардагы татар практикантларының санын 10%ка җиткерү, 5 ел эчендә Үзәк курслар аша 3200ләп татар белгече әзерләп чыгару, 3000 рус хезмәткәрен татар теленә өйрәтү бурычлары куела (Сб., 1925, с. 57-59).

Бишьеллык план белән бергә, ҮК өстәмә рәвештә 1925 елның февраль-октябрь айлары өчен дә 22 пункттан торган эш планын төзи (ф. 732, оп. 1, д. 798, лл. 11-12). Әмма 1925 елның 19 октябрендә Эшче-крестьян инспекциясе тарафыннан ТТГК ҮК эшчәнлеген һәрьяклап тикшерү нәтиҗәсендә, 9 айга исәпләнгән планның 11 пункты тулысынча яки өлешчә үтәлүе, ә 11 әһәмиятле пунктның исә бөтенләй үтәлмәве билгеләп үтелә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 71). Шулай ук ҮК тарафыннан комиссариатларга бишьеллык, кантоннарга ике еллык планнар төзү бурычы йөкләнгән була. Бу эш тә өлешчә генә үтәлә (ф. 732, оп. 1, д. 766, лл. 70-71). 1921 елдан бирле эшләп килгән ҮКның, шулай ук канткомиссияләр һәм оешмалардагы өчле комиссияләрнең төп нигезләре дә 1925 елның 4 апрелендә генә игълан ителә (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 93).

1925 елда Татарстан республикасы игълан ителүгә 5 ел тулу зурлап билгеләп үтелә. Юбилей хөрмәтенә төрле җыентыклар әзерләнә. ТТГК ҮК да бу эштән читтә калмый: 5 ел эчендә ТТГК буенча чыгарылган декрет, карарлар, әһәмиятле циркулярларны туплап, ике телдә дә аерым-аерым җыентык итеп бастыра (Сб., 1925. — 88 с.). Шулай ук ТҮБК тарафыннан чыгарылган «Биш ел эчендә» исемле рус һәм татар телләрендәге җыентыкларда да, хөкүмәт җитәкчеләренең Татарстан республикасы юбилеена багышланган

тантаналы язмаларыннан соң ук диярлек ТТГК мәсьәләсе киң яктыртыла (За 5 лет, 1925, с. 39-45). Бу ике зур җыентыктан тыш, бәйрәм хөрмәтенә үткәрелгән күп санлы съезд һәм сессияләрдә, ТҮБКның еллык хисапларында да татар теленең ничек гамәлгә куелышын тикшерү зур урын ала (Отчет ЦИК и СНК к 5 съезду Советов, 1925, с. 20-39; Вторая сессия ЦИК 5-созыва, с. 28-29; Отчет о деятельности ЦИК и СНК за 1925-26 год, 1926, с. 10-11; Отчет ЦИК и СНК 5 созыва ТССР, 1926, с. 44-54).

1925/26 еллар шулай ук татар теле укытучылары, кантинструкторлар, оешмалардагы өчле комиссияләр киңәшмәләре булу белән дә данлыклы.

Димәк, бу елларда ТТГК мәсьәләсе буенча дүрт ел эчендә үтәлгән эшләргә йомгак ясала, киләчәк өчен беренче тапкыр перспектив план төзелә, күп санлы съезд, сессия һәм киңәшмәләрдә төрле тармакларда татар телен тормышка үткәрү проблемалары һәрьяклап тикшерелә.

III. 1927 елда да дәүләт оешмаларында, волость һәм кантоннарда ТТГКның барышы, бу эштә ирешелгән уңышлар яки каршылыкларны тикшерү дәвам итә.

1927 елның 12-13 март көннәрендә булган ТҮБКның 3 нче сессиясендә ҮК эшчәнлеге карала. ТҮБК һәм ТТГК ҮК рәисе Ш.Шәймәрданов «Татар телен тормышка үткәрү эшенең куелышы һәм киләчәге турында» дигән доклад белән чыгыш ясый (Доклад, 1927. — 68 с.). «Татар телен тормышка кертү мәсьәләсен шушылай югары дәрәҗәдә — хәзергечә әйтсәк, Дәүләт Советы дәрәҗәсендә куеп тикшергән, докладны да дәүләт башлыгы сөйләгән, тикшерү барышында хөкүмәт җитәкчесе  (Х. Габидуллин) кебек югары вазифалы шәхесләр катнашып чыгыш та ясаган рәсми сессия, дәүләткүләм корылтайлар бездә шуннан соң булмаган, ул —

соңгысы» (Низамов, 1998, б. 24). Сессиядә 6 ел эчендә түбәнге оешмалардан алып югары органнарга кадәр татар теленең ничек гамәлгә куелышы, эшнең нәтиҗәләре, кимчелекләр һәм аның сәбәпләре, татар хезмәткәрләре хәзерләү, русларга татар теле өйрәтү, яңа алфавитка күчү һ.б. бик күп мәсьәләләр карала; фикер алышулар вакытында каты-каты тәнкыйть сүзләре дә әйтелә; төрле тармаклар буенча җентекле карарлар кабул ителә. Кызганыч, әлеге карарларның күбесе кабат кәгазьдә генә кала, аларның бары бер юнәлешенә — дәүләт аппаратына җирле халыкны тарту (русчасы — «коренизация аппарата») өлкәсенә генә өстенлек бирелә башлый. Бу эшнең нигезен түбәндәгеләр тәшкил итә: татарларны һәм татарча белүчеләрне эшкә күбрәк җәлеп итү һәм моны планлы нигездә башкару максатында, барлык дәүләт учреждениеләренең хезмәт урыннары исемлеге төзелеп, шул урыннарның кайсыларын ике дәүләт телен дә белүче хезмәткәрләр белән алмаштырырга кирәклеге билгеләнә. Бу процесс үзе «хезмәт урыннарын функциональ алмаштыру» («функциональное замещение должностей») дип, ә исемлекләр «хезмәт урыннарының номенклатура исемлекләре» («номенклатурные списки должностей») дип атала (ф. 732, оп. 1, д. 1138, лл. 35-36).

20 нче еллар башыннан ук оешмаларга татарларны күбрәк җәлеп итү буенча зур эш алып барыла, ә 1927 елдан исә ул иң әһәмиятле мәсьәләгә әверелә. Бу эш партия ӨКның 1926 елның 13 декабрендәге күрсәтмәсе нигезендә башлана (Климов, 1960, с. 300). Әле сессиягә кадәр үк, 1927 елның 11 январендә ТТГК ҮК ике телдә дә циркуляр игълан итә. Ш.Шәймәрданов һәм К.Вәлиев имзалары куелган әлеге циркуляр буенча, барлык комиссариатлар һәм үзәк учреждениеләр 1 февральдән дә соңга калмый үз аппаратларындагы хезмәт урыннары исемлеген җибәрергә тиеш булалар (ф. 128, оп. 1,

д. 771, лл. 5-6). Моның өчен 4 баганадан торган әзер форма да бирелә. Билгеләнгән вакыт, ягъни 1 февраль, «ныклы һәм үзгәртелә алмый» (ф. 128, оп. 1, д. 771, л. 5) диелсә дә, эшләр алай тиз генә үтәлә алмый. Үзәк комиссия үз өстенә йөкләнгән номенклатура исемлекләрен җыю юлында оешмалар вәкилләреннән «аерым план комиссиясе» төзеп, үзәк учреждениеләрнең хезмәт урыннары исемлеген 3-4 ай буенча тикшерү нәтиҗәсендә, 55 учреждениенең номенклатурасын 15 июньдә ТҮБК президиумы белән Халык комиссарлары советының берләшкән утырышында раслатып ала. Шул исемлекләрнең бер данәсе оешмаларның үзләренә, бер данәсе Хезмәт Биржасына җибәрелеп, тормышка үткәрә башларга кушыла (ф. 128, оп. 1, д. 771, л. 15). Ләкин үзәктәге хөкүмәт аппаратларында бу исемлек төзелгәннән соң, штат кыскарту, бүлек һәм бүлекчәләрне берләштерү, кайбер учреждениеләрне бергә кушу, бик күп урыннарның исемен алмаштыру кебек штатта һәм аппаратта зур үзгәрешләр булганлыктан, хезмәткәрләрне бу номенклатура буенча алмаштыру мәсьәләсе бик җайсызлана. Шуның өстенә, алмаштыру вакыты билгеләнгән чакта татар булмаган хезмәткәрләрнең татарча өйрәнүе өчен бертөрле дә вакыт калдырылмый. Шул сәбәпләр аркасында оешмаларның яңа исемлек төзүләре һәм аны администрация, ТТГК өчле комиссиясе һәм хезмәткәрләр комитеты вәкилләренең катнашы белән тикшереп чыгып, иң ашыгыч рәвештә — 20 октябрьдән дә соңга калмый — Үзәк комиссиягә тапшырулары кирәк дип табыла (ф. 128, оп. 1, д. 771, лл. 15-16). Яңа исемлек төзү өчен оешмаларга 12 баганадан торган әзер форма һәм аны ничек тутырырга икәнен аңлаткан өйрәткеч тә җибәрелә (ф. 128, оп. 1, д. 771, лл. 17-18).

1927 елның ноябрендә бирелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, бу вакытта Казандагы 134 учреждениенең номенклатура

исемлекләре төзелеп бетә. Әлеге исемлекләр буенча, 1930 елга кадәр төрле вакыт аралыгында барлыгы 3528 хезмәткәр алмаштырылырга тиеш була, бу хезмәткәрләрнең гомуми санының 48,4%ын тәшкил итә. Кантоннар буенча исә 60,9% хезмәткәрне алмаштыру күздә тотыла. Ләкин исемлекләр төзи башлаган вакытта оешмаларда 1288 татар кешесенең дә эшләвен исәпкә алганда, алмаштырылырга тиеш булган хезмәткәрләр саны кими: 3528 түгел, ә 2240ны тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 13).

Исемлекләрдә хезмәткәрләр алмаштырылырга тиеш булган вакыт чикләре дә төгәл күрсәтелә. Нәтиҗәдә еллар буенча түбәндәге саннар килеп чыга: 1) тиз арада — 74; 2) 1928 елда — 599; 3) 1929 елда — 490; 4) 1930 елда — 152; 5) татар һәм рус телләрен белгән яраклы кандидатура табылган очракта — 804 хезмәткәр алмаштырылырга тиеш дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 36).

Исемлекләрне тикшергәннән соң, татар хезмәткәрләре арасында иң кирәклеләре — урта техник персонал һәм квалификацияле белгечләр дигән нәтиҗә ясала (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 38). Беренче чиратта таләп ителгән 21 белгечлек күрсәтелә. Аларны документта бирелгәнчә түгел, ә саннары ягыннан тезеп куйсак, түбәндәге картина килеп чыга: 1) бухгалтерлар — 263; 2) хисапчылар — 221; 3) инструкторлар, инспекторлар һәм агентлар — 198; 4) завхоз, завсклад һәм завмаглар — 147; 5) врачлар — 70; 8) агрономнар — 60; 9) экономистлар — 59; 10) ветфельдшерлар — 41; 11) акушерлар — 38; 12) юрисконсультлар — 22; 13) инженер һәм техниклар — 18; 14) лесниклар — 16; 15) теш врачлары — 11; 16) лаборантлар — 6; 17) зоотехниклар — 3 (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 38).

Номенклатура исемлекләрен раслаганда, кайбер белгечлекләрне татарлар арасыннан табуы авыр булу яки бөтенләй мөмкин булмау

нәтиҗәсендә, алар исемлекләрдән сызып ташлана. Шулай итеп, тагын ташламаларга барырга туры килә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 38).

1927 елда, хезмәткәрләрне алмаштыру эшеннән тыш, ТТГКга кагылышлы тагын бер зур вакыйга була: зур тырышлыклар нәтиҗәсендә, бигрәк тә күренекле татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Ш. Усмановның күп көч куюы аркасында, Татарстанда радиотапшырулар станциясе төзелә, эфирда татарча тапшырулар барлыкка килә. Радио сөйли башлаган иң беренче атнаның икенче һәм өченче көннәрендәге тапшырулар тәртибенә күз салыйк:

12 ноябрь, шимбә.

16.20. Радиосөючеләр сөйли.

17.00. Заман радиотехникасы.

17.30. Радиогазета.

19.00. СССРны радиолаштыруның бишьеллык планы.

20.00. Татар теле.

20.30. Мәскәүдән яки чит илдән концерт трансляцияләү.

13 ноябрь, якшәмбе.

11.00. Радиопионер.

11.30. Җир буенча халык комиссары чыгышы.

12.15. Октябрь ничек бәйрәм ителде?

16.00. Татар республикасын тракторлаштыру.

17.00. Халык музыкасы концерты.

17.30. Радиогазета.

19.00. Волга-Дон каналы.

20.00. Татар теле.

20.30. Студиядән концерт.

Күренгәнчә, Татарстанда радио барлыкка килүнең иң беренче көннәрендә үк татар теленә ярты сәгать күләмендә вакыт бирелә башлый, тапшырулар татар һәм рус телләрендә алып барыла (Татарстан. — 1995. — №9-10. — Б. 67).

Хезмәткәрләрне алмаштыру мәсьәләсенә кабат әйләнеп кайтсак, 1928 елда исемлекләргә тагын үзгәрешләр кертелә. ТҮБК президиумы карары буенча, учреждение җитәкчеләре (идарә рәисләре, халык комиссарлары, директорлар, идарә әгъзалары һ.б.) һәм түбән персонал (каравылчылар, кучер һәм урам себерүчеләр) исемлекләргә кертелми, ягъни аларны ике телне дә белүчеләр белән алмаштыру таләп ителми (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 37).

Гомумән, хезмәткәрләрне алмаштыру эше бик зур авырлыклар белән бара. Алдарак күрсәтелгән каршылыклардан тыш, кайбер оешмалар: «без татар массасы белән күп аралашмыйбыз, безгә татар теленең артык әһәмияте юк»,— дип, аппаратны ике телне дә белүчеләрдән оештыруны кирәксез бер нәрсә итеп аңлатырга тырышалар. Ләкин Үзәк комиссиянең тикшерүләре нәтиҗәсендә, боларның һәммәсе Татарстан шартларында татар халкы белән азмы-күпме аралашырга мәҗбүр дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 771, л. 17).

Шулай ук ул вакытта комиссияне артык кискен чаралар күрүдә гаепләү очраклары да була. Янәсе, күреләчәк чаралар хакында рус хезмәткәрләрен алданрак кисәтергә һәм аларга татар теле өйрәнергә мөмкинлек бирергә кирәк иде. Мондый фикерләр совет сәүдә хезмәткәрләренең профсоюз әгъзалары шәһәр конференциясендәге күп кенә ораторларның чыгышларында да күзәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 2). ТТГК ҮКның аларга җавап рәвешендә биргән аңлатмасын кыскартмыйчарак тәрҗемә итеп бирергә тырышабыз: «...беренчедән, Татарстан республикасында татар булмаган хезмәткәрләр бу өлкәдә инде җитәрлек күләмдә кисәтелделәр:

ведомстволарда татар теленә өйрәтү курслары 1923 елдан бирле эшләп килә, аларга шактый зур күләмдә дәүләт акчалары сарыф ителде, ләкин эчке теләк һәм тышкы яктан басым ясау булмаганлыктан, бу эштән бернинди уңай нәтиҗәләр килеп чыкмады. Икенчедән, расланган номенклатура буенча, Татарстан республикасының 10 еллыгына үзәк аппаратлар ике официаль телне дә белүче хезмәткәрләр белән 29%ка тәэмин ителергә тиеш. Өченчедән, 11700 хезмәткәрдән 34%ының ике телне дә белүе мәҗбүри итеп саналмый, ягъни, тагын да ачыграк әйткәндә, әле күпчелеген татарлар тәшкил иткән 29%тан ике телне дә белү таләп ителә, ә 34%ка бу мәҗбүри итеп куелмый. Димәк, ризасызлык белдерү өчен урын юк» (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 3).

Бу каршылыклардан тыш, татар телен белмәү сәбәпле алмаштырылырга тиеш булган коммунистлар, запастагы командирлар мәсьәләсе, шулай ук алмаштырырга дип билгеләнгән хезмәткәрләрне кызганып, эшләрендә калдыру, оешма җитәкчеләре тарафыннан игътибарсыз мөнәсәбәтнең дәвам итүе һ.б. да эшне тоткарлый (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 1).

Хезмәткәрләрне алмаштыру эшенең ничек баруын белү максатында, комиссия тарафыннан үзәк оешмаларны тоташ тикшерү алып барыла, бу эш начар куелган кайбер органнар судка бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 2). Ләкин ул оешмаларның исемнәре аталмый.

1929 елның 31 августында бирелгән мәгълүматлар буенча, «Татарстанда беренче булып башланган хезмәткәрләрне функциональ алмаштыру тәҗрибәсе башка милли республикалар тарафыннан да файдаланыла башлады. Дәүләт аппаратына татарларны җәлеп итү эшен планлаштыру Хезмәт комиссариатына да, учреждениеләрнең үзләренә дә билгеле бер срокка кирәкле хезмәткәрләрне әзерләү яки эзләп табу мөмкинлеге бирә. Исемлек

буенча, хезмәткәрләрнең 54,3%ы алмаштырылырга тиеш. 1929 елгы планның 43,2%ы инде үтәлгән» (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 35).

Шундый зур колач алган хезмәткәрләрне ике телне дә белүчеләр белән алмаштыру кампаниясе 1930 елда төгәлләнергә тиеш булса да, бу елда ТТГК ҮК әле һаман «... номенклатура исемлекләре төзү өчен формалар эшли, билгеле бер вакытка алмаштырылырга тиеш булган хезмәт урыннарын билгели, эшнең үтәлешен тикшерә» (ф. 732, оп. 1, д. 1307, лл. 339-340). Үзенең хисабында комиссия шундый гомуми сүзләр белән генә чикләнә, ә конкрет саннар, фактлар китерелми.

Хезмәткәрләрне ике телне дә белүчеләр белән алмаштыру эшен дә, гомумән, ТТГК процессын да хәтта 1930 ел белән тәмамларга да мөмкин булыр иде. Чөнки шуннан соң Комиссиянең хисап һәм докладлары бирелми, хөкүмәтнең бер генә съезд яки сессиясендә дә ТТГК эше аерым алып тикшерелми. Ләкин, документлар буенча, Үзәк комиссия үзе 1932 елга кадәр эшли (Языковая политика, 1998, с. 8), ә архивларда саклanган ТТГК буенча соңгы чыганак 1936 ел белән билгеләнә. Бу документта инде ТТГК атамасы бөтенләй кулланылмый, «аппаратка җирле халыкны тарту һәм районнарда аларның туган телендә хезмәт күрсәтү» исеме астында берничә комиссариатка тикшерү үткәрелә (ф. 732, оп. 1, д. 2809, лл. 1-8). Тикшерү нигездә комиссариатлардагы татарларның саны, ничә хезмәткәр эштән чыгарылган, ничәсе алынган булуы турында цифрлы мәгълүматлар китерү белән чикләнә. Эшкә татарларны алудан башка бернәрсә дә эшләнмәгән дигән фикер туа. 1927 елдан аеруча киң таралыш алган бу хәрәкәт нәтиҗәсендә, оешмаларда татар хезмәткәрләренең сан ягыннан шактый артуы күзәтелә: 1936 елда үзәк оешмаларда һәм комиссариатларда эшләүче татар

хезмәткәрләре 38,5%ны алып торалар, ә җитәкчеләр арасында татарлар хәтта 47,4%ка җитә (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 13).

Комиссия 1932 елда ук яшәүдән туктаса да, шушы соңгы чыганакка таянып, ТТГК процессы 1936 елга кадәр дәвам иткән дигән фикергә килсәк, мөгаен, дөресрәк булыр.

20 нче еллар ахырыннан башланып, 30 нчы еллар буе бер-бер артлы дәвам иткән наданлыкны бетерү, яңалифкә күчү, мәҗбүри гомуми белем, «җиңүле рәвештә бишьеллык планнарны үтәү», социалистик ярыш, ударниклык, «уң һәм сул оппортунистлар», «җирле милләтчелек» белән көрәш һәм башка бик күп мәсьәләләр әкренләп ТТГК проблемасын кысрыклап, арткы планга чыгаралар, бөтен милләтләрне берләштерү идеясе дә өстәлгәч, ул бөтенләй әһәмиятсез бер эшкә әйләнә һәм томаланып юкка да чыга.

Шулай итеп, ТТГК эше 1921 елда башланып, әле көчәеп, әле бик сүлпәнләнеп, 15 ел дәвам итә. Зур авырлыклар һәм каршылыклар белән барган бу процессның төп мәсьәләләреннән саналган комиссариатларда, дәүләт оешмаларында һәм кантоннарда татар телен тормышка үткәрү, татар белгечләре әзерләү, рус хезмәткәрләренә татар теле өйрәтү кебек проблемалар аерым алып һәм киңрәк яктыртылуга лаек. Алдагы бүлекләр шул мәсьәләләргә багышланачак.

## 2 бүлек. Халык комиссариатларында һәм үзәк оешмаларда татар телен гамәлгә кую.

2.1. Дәүләт учреждениеләрендә татар телен гамәлгә кую максатында кабул ителгән карар һәм инструкцияләр.

Комиссариатларда һәм оешмаларда ТТГК мәсьәләсе баштан ук игътибар үзәгендә була: 1921 елгы Декретның беренче пунктында ук «барлык совет дәүләт учреждениеләрендә татар телен мәҗбүри итеп куярга» диелә (Сб., 1925, с. 5), ә иҗтимагый, кооператив оешмалар һәм профсоюзлар татар телен үз теләкләре буенча кертә алалар. Беренче Декретта шулай ук басылып чыгарга тиешле барлык декрет һәм карарларның татар һәм рус телләрендә булуы, дәүләт оешмалары арасындагы язышуның һәм оешмалар эчендә эш башкаруның дәүләт телләренең берсендә алып барыла алу да билгеләп үтелә (Сб., 1925, с. 6-7). Татар теленең ничек итеп гамәлгә куелырга тиешлеге тулы итеп ядтыртылмый. Бу әле төп эшкә әзерлек, нигез салу гына була.

1922 елның 8 маенда Декретка өстәмә рәвештә кабул ителгән карарларның да берничә маддәсе оешмаларга кагыла. ҮБКның әлеге карары нигезендә, ТАССРның барлык совет учреждениеләрендә татар телендә телдән яки язмача бирелгән гариза һәм үтенечләрне кабул итү мәҗбүри итеп куела. Учреждениеләр әлеге мөрәҗәгатьләрне үзләренең штатында булган хезмәткәрләр көче белән тормышка ашыру өчен барлык чараларны да күрергә тиеш булалар, бары бу эш бөтенләй мөмкин булмаганда гына, Хезмәт комиссариаты рөхсәте белән, учреждение махсус штатлы тәрҗемәче булдыра ала (Сб., 1925, с. 8). Барлык җыелыш һәм утырышларның рәсми теле итеп Татарстан чикләрендә бертигез хокукта рус һәм татар телләре саналырга тиеш була (Сб., 1925, с. 9).

8 майдагы документта шулай ук алга таба күп мәртәбәләр кабатланган, төрле съезд һәм сессияләрдә кат-кат басым ясалган карар үзенең башлангычын ала: хезмәткәрләрне эшкә алганда, башка тигез шартларда, рус һәм татар телләрен белгән кандидатларга өстенлек бирелергә тиеш дип табыла. Һәрвакыт татар халкы белән аралашырга туры килгән хезмәт урыннарына ике телне дә белүче хезмәткәрләр билгеләнергә, андый хезмәткәрләр бөтенләй булмаган очракта, алар янына тәрҗемәчеләр куелырга тиеш була (Сб., 1925, с. 9). Ике телне дә белүче хезмәткәрләрне совет эшенә тарту максатында, аларга даими рәвештә премияләр бирү күздә тотыла (Сб., 1925, с. 9). Әлеге карарлар бик изге максатлар белән кабул ителә. Эшкә алганда, татарларга өстенлек бирү маддәсе алдагы елларда күп оешмалар тарафыннан тормышка ашырыла, ләкин, кызганычка каршы, премияләр бирү дә, махсус тәрҗемәчеләр тоту да, һәрвакыт акча җитешмәү сәбәпле, нигездә, хыял гына булып кала.

1922 елның 21 декабрендә шул чор өчен аеруча әһәмиятле һәм оешмаларда татар телен тормышка үткәрү юлларын җентекләп яктырткан «ТАССР дәүләт учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә ТТГК инструкциясе» игълан ителә. 19 пункттан торган күләмле әлеге инструкциядә элеккеге карарларга тагын да ачыклык кертелә, дәүләт оешмаларында ТТГКның яңа юнәлешләре билгеләнә. Беренче кабатланган карар — эшкә алганда татарларга өстенлек бирү хакындагы маддә. Татарларны күбрәк җәлеп итүнең нигезләрен тагын да тирәнәйтеп, эшкә алганда хезмәткәрләрнең татарча белүләрен билгеле бер квалификация итеп карау, дәүләт органнарының штатларын яңадан карап чыгып, татар халкы белән тыгыз бәйләнештә эшләүче хезмәткәрләрне татар телен белүчеләр белән алмаштыру хакында өстәмәләр дә кертелә (Сб., 1925, с. 12).

Икенчедән, ТАССРның барлык үзәк, кантон, шәһәр һәм район учреждениеләрендә, шулай ук составында татар авыллары булган волостьларда татар телендәге телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрне кабул итүне мәҗбүри итеп кую хакындагы маддә тулысынча диярлек элеккеләрне кабатлый, татар телендәге язма мөрәҗәгатьләргә җаваплар да татарча бирелергә тиешлеге турындагы искәрмә генә кечкенә бер өстәмә булып тора ала (Сб., 1925, с. 11). Өченчедән, барлык оешмаларның боерыклары ике телдә дә басылып чыгарга тиешлеге хакындагы карарга өстәмә итеп, инструкцияләр, карарлар, гаризалар, плакатлар һәм башкалар да бер үк вакытта рус һәм татар телләрендә игълан ителергә, әгәр алар вакытлы матбугатта чыгарылса, ТҮБК басмаларыннан саналган «Известия ТЦИК» һәм «Татарстан» газеталарында урын алырга тиеш дип табыла (Сб., 1925, с. 11). Дүртенчедән, элек билгеләнгәнчә, барлык җыелыш һәм утырышларда гына түгел, ә съезд һәм конференцияләрдә дә рус һәм татар телләренең тигез хокуклылыгы ассызыклана. Әгәр рус телендә алып барылучы җыелышта тавыш бирү хокукына ия татарлар булып, алар, рус телен белмәү сәбәпле, доклад, фикер алышулар һәм резолюцияне татар теленә тәрҗемә итүне таләп итсәләр, бу таләпләр канәгатьләндерелергә тиеш була. Татар телендә алып барылучы җыелышларда руслар өчен дә шул ук кагыйдәләр билгеләнә (Сб., 1925, с. 12). Чыннан да, күп кенә җыелыш һәм утырышлар татар телендә уздырыла башлый. Съезд һәм сессияләрдә дә татар телендә сөйләргә мөмкинлек була, алып баручылар күбесенчә ике телдә дә чыгыш ясарга тырышалар, шулай да аларның күпчелегендә рус теле өстенлек итә, беркетмәләр дә русча язылып, татар телендә сөйләүчеләрнең чыгышлары хәтта кермичә дә кала.

Инструкциядә элек чыгарылмаган яңа гомуми нигезләр дә бар. Шуларның беренчесе, беренче маддә булып ук бирелгәне, түбәндәгеләрне үз эченә ала: дәүләт органнары яки аерым шәхесләр тарафыннан татар телендә эшләнгән барлык рәсми, эш кәгазьләре һәм документлар (таныклык, мандат, ышаныч язуы, расписка, килешү, беркетмә, акча документлары һ.б.) ТАССР чикләрендә рус телендәге шундый ук документлар белән бер үк хокукка ия булалар (Сб., 1925, с. 10-11).

Яңа документларның икенчесе: барлык учреждение һәм предприятиеләрнең мөһерләре, штамп һәм эленмә такталары, шулай ук авыл, юл, пристань, станция, шәһәр урамнары исемнәре язылган такталар татар һәм рус телләрендә булырга тиеш (Сб., 1925, с. 11). Бу маддәгә өстәмә итеп, ТҮБК 1923 елның 21 сентябрендә махсус карар чыгара. Аның буенча, дәүләт, җәмәгать оешмаларыннан гына түгел, шәхси учреждениеләрдән дә мөһер, штамп һәм эленмә такталарны ике телдә дә булдыру таләп ителә, бу эш өчен бер ай вакыт бирелә. Бер телдә генә булганнарын алмаштырган яки яңаны ясаган вакытта НКВД органнары тексттагы тәрҗемәнең дөреслеген тикшерергә, моның өчен учреждениеләр үзләре җавап бирергә тиеш булалар. Бер ай срок үткәннән соң, татар яисә рус телендә генә язылган эленмә такталарны, НКВД кушуы буенча, милиция алып ташлый ала һәм, гомумән, бу эшнең үтәлешен тикшерү НКВДга тапшырыла (Сб., 1925, с. 15-16).

Инструкциядә шулай ук барлык комиссариат һәм үзәк учреждениеләр челтәрен районнар буенча теге яки бу милләт халкы тигез урнашырлык итеп яңадан карап чыгу кирәклеге ассызыклана, комиссариатларга үзләренең карамагындагы учреждениеләр өчен ТТГК буенча инструкцияләр чыгару мөмкинлеге бирелә, үзәк оешмаларның системалы рәвештә Үзәк комиссиягә хисап биреп

торырга тиешлеге искәртелә, авыл советлары, волостьлар, Мәгариф комиссариатына да төрле бурычлар йөкләнә (Сб., 1925, с. 14). Инструкциянең үтәлү вакыты да төгәл билгеләнә: мөһер, штамп, телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр, карар һәм инструкцияләр хакындагы маддәләр 1923 елның 1 февраленә кадәр, калганнары исә шул ук елның 1 июленә кадәр үтәлергә тиеш була (Сб., 1925, с. 15).

Күренгәнчә, бу инструкциядә алдарак кабул ителгән карарлар бергә туплана, аларга өстәмәләр кертелә, яңа бурычлар куела, башкарылырга тиешле эшләрнең үтәлеш вакыты төгәл билгеләнә, мәсьәләләр профессиональ дәрәҗәдә, анык һәм төгәл итеп куела.

Моның белән генә чикләнмичә, 1924 елның 30 апрелендә, инструкциянең дәвамы буларак, ТҮБК карары игълан ителә. Ул 11 маддәне үз эченә ала. Шуларның гомумән комиссариат һәм учреждениеләргә кагылганнары түбәндәгеләр: 1) дәүләт учреждениеләре түбәнге органнардан татар телендә килә торган хисап, ведомость һәм башка материалларны рус теленә тәрҗемә итеп җибәрүне таләп итмәскә тиеш; 2) татар телен һәм язуын белүче хезмәткәрләр өчен учреждениедә аз вакыт хезмәт итүе штатларны кыскарту вакытында эштән азат итү өчен нигез була алмый; 3) ...үз аппаратында 50%тан ким татар булган оешмаларга барлык хезмәткәрләрнең 10%ы күләмендә татар практикантлары институты ачу тәкъдим ителә; 4) инструкцияне дәүләт органнарына гына түгел, кооператив һәм профессиональ оешмаларга да куллану кирәклеге ассызыклана (Сб., 1925, с. 18-19).

Оешмаларның инструкцияне ничек үтәүләрен тикшерү эше Эшче-крестьян инспекциясе халык комиссариатына тапшырыла (Сб., 1925, с. 19-20). Шулай ук Үзәк комиссия инструкторлары да әлеге эш белән шөгыльләнәләр. ҮКның киңәйтелгән

утырышларында, төрле киңәшмәләрдә комиссариат һәм учреждениеләрнең хисаплары тыңлана.

Күп санлы комиссариат һәм учреждениеләрдә татар телен тормышка үткәрү өчен төрле ведомство өчле комиссияләре төзелә. Алар ТТГК ҮК җитәкчелегендә эшлиләр. Өчле комиссияләрнең бурычлары итеп түбәндәгеләр билгеләнә: 1) әлеге ведомствода ТТГК эше белән гомуми җитәкчелек итү; 2) үзәк учреждениеләр һәм алар карамагындагы оешмаларны татарлаштыру чараларын үтәү; 3) хезмәткәрләрне татар теленә өйрәтү курс-түгәрәкләре оештырып, алар белән җитәкчелек итү; 4) ТТГК ҮК боерыкларын үтәү һәм ведомствода татар телен гамәлгә куюның торышы хакында комиссиягә әледән-әле хисап биреп тору (Сб., 1925, с. 29).

Өчле комиссия гадәттә рәис һәм ике әгъзадан тора. Комиссия рәисе итеп учреждение җитәкчесе яки аның урынбасары билгеләнә. Комиссия составына татар телен белүчеләрдән бер кеше булса да керергә тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 197, л. 85).

Өчле комиссияләрне төзү бурычы 1923 елның 1 маенда ук куелган булса да, комиссияләр бик озак һәм төрле вакытта оештырылалар. Төзелгәч тә, аларның күбесе эшләрен канәгатьләнерлек алып бармый. ҮК тарафыннан күп тапкырлар анкеталар җибәрелеп, инструкциянең ничек үтәлүен хәбәр итү таләп ителсә дә, бу таләпләрнең күбесе җавапсыз кала. ҮКның җаваплы сәркатибе К.Вәлиевнең 1926 елның 27 маендагы циркулярыннан китерелгән өзекләр бу фикерләрне тагын да ачыграк дәлилләргә ярдәм итәр (текст үзгәртелмичә бирелә — З.К.): «Үзәктәге берничә оешманы аерып алган вакытта, иң күп өлеше бу турыда бармакны бармакка да сукканнары юк дисәк, хата булмас. ...Өчле комиссияләрнең берсе дә күрсәтелгән вазифаларны җиренә җиткермиләр. Учреждениене татарлаштыру турында Үзәк

комиссиягә булышлык күрсәтмиләр. Эшләрен план буенча алып бармыйлар. Үзәк комиссиянең кәгазьләрен вакытында җиренә җиткермиләр яки бөтенләй җавапсыз калдыралар. Үзәк комиссиягә отчет бирмиләр. Инструкторлар тикшергән вакытта «ник план төземисез, ник отчет бирмисез?» дигән сөальгә «әйтүче булмады, сораучы юк» дип, бик кызык кына җавап белән канәгатьләнмәкче булалар, икенче төрле әйткәндә, «безгә положениене килеп укучы булмады, без үзебез аны укыганыбыз юк» дисәләр, тагын да дөресрәк булыр иде. ...Кайсыбер өчле комиссиянең рәисе саналган юлбашчылары «утырышлар ясыйсы иде, план төзисе иде, отчет бирергә вакыт җитте» дип мөрәҗәгать иткән аппаратның тышында (магазин яки складта) тәне белән хезмәт итүче өчле комиссия әгъзаларына «минем вакыт юк, менә сине рәис итеп куярга кирәк, син эшләрсең» дип кенә җавап бирәләр дә, «аптырап йөрмә, кирәк булса, эшлә» дигән сүзне аңлаталар. Шуның белән эшсезлекне, тынлыкны тагын бер күпме вакытка сузарга уңышлык табалар. Комиссия оештырылган җирдә дә комиссиянең бер әгъзасы китү белән өчле комиссиянең эшендә бөтенләй тукталырга тиешле була. Алты ай, хәтта бер ел тоташтан, аркылы ятканны буйга да алып салмаган, әгъзалары кемнәрдән гыйбарәт икәнне белмәүче нәзарәтләр һәм өчле комиссияләр дә байтак кына бар...» (ф. 128, оп. 1, д. 641, лл. 32-33).

Бик эмоциональ характердагы әлеге тәнкыйть сүзләре ТТГК эше белән турыдан-туры җитәкчелек итүче кеше тарафыннан язылганнар, шуңа күрә аларга ышанмыйча мөмкин түгел. Шулай да гомумиләштереп бирелгән бәя артында аерым комиссариат һәм учреждениеләрнең татар телен гамәлгә куюдагы эшчәнлеге күзалланмый. Алдарак без нәкъ шул мәсьәләгә игътибарыбызны юнәлтербез. Ләкин бу очракта шундый авырлык бар: 20 нче елларда

да учреждениеләрнең саны гаять күп була һәм алар гел үзгәреп тора. Мәсәлән, 1925 елда 13 Халык комиссариаты, 30 үзәк оешма, 14 трест, 6 фабрика, 3 завод, 5 банк, партиянең 9 оешмасы һ.б. булуы мәгълүм (ф. 732, оп. 1, д. 659, л. 154). Бу оешмаларның барысын да аерым-аерым җентекләп тикшереп бетерү мөмкин түгел. Шунлыктан ТТГК буенча күбрәк мәгълүмат табылган комиссариат, идарә һәм оешмаларның эшчәнлегенә тукталырбыз.

2.2. Элемтә идарәсендә ТТГК. Документлар шуны күрсәтә: революциягә кадәр почта-телеграф хезмәтенә татарлар я бөтенләй кабул ителмәгәннәр, я хат ташучы, җыештыручы, урам себерүче кебек ярымквалификацияле һәм квалификациясез эшләргә генә алынганнар. Моның сәбәбе аңлашыла да, чөнки татарлар арасында бу өлкәдә эшләрлек белемле хезмәткәрләр булмый (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 166). Почтада бөтен эш кәгазьләре, хезмәт күрсәтү рус телендә генә алып барыла.

Татарстан республикасының беренче көннәреннән элемтәне татарлаштыру юнәлешендә эш башлана. 1921 елгы беренче Декретта ук Идел-Кама Элемтә округының Казан идарәсендә татар телен гамәлгә куюга багышланган махсус пункт урын ала. Аның нигезен түбәндәгеләр тәшкил итә: телеграф конторaларында кичекмәстән рус шрифты белән татар телендә язылган телеграммаларны кабул итү һәм җибәрүне булдырырга; адреслары татар телендә язылган заказлы хатларны кабул итәргә; татарча адреслы гади хатларны да ирекле рәвештә кабул итү өчен ҮКга тиз арада чаралар күрергә (Сб., 1925, с. 6). Шул ук елның 31 октябрендә булган комиссия утырышында да барлык төр почта корреспонденцияләрен татар телендә булдыру турында карар кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 59, л. 28). Ләкин бары 1924 елда гына бу карарларны тормышка ашыру юнәлешендә беренче адымнар ясала башлый. 1924 елның 25

апрелендә Элемтә идарәсе тарафыннан чыгарылган циркуляр буенча, Татарстан республикасының барлык почта-телеграф бүлекләрендә адреслары татарча язылган гади хатлар кабул ителә башларга тиеш була. Шул вакыттан алып бу карар тормышка ашырыла башлый. Заказлы хатлар исә татар телен белүче квалификацияле хезмәткәрләре булган почта бүлекләрендә генә кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 8). Моннан тыш, Казан почта-телеграф конторасында рус хәрефләре белән татарча язылган телеграммалар кабул итү кертелә.

Казан шәһәре почта-телеграф предприятиеләре хезмәткәрләре арасында 1925 елда ТТГК комиссиясе төзелә. Аның рәисе итеп Элемтә округы башлыгы Игошкин Яков Федорович, комиссия әгъзалары итеп Хезмәт бүлеге башлыгы Заболоцкий Дмитрий Александрович һәм идарәдә тәрҗемәче, татар теле укытучысы булып эшләүче Иманаева Әминә Абдуловна билгеләнә. Беренче ике хезмәткәр милләтләре буенча рус булсалар да, икесе дә татар теле өйрәнәләр (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 2). Игошкин Мәскәүгә күчерелгәч, 1926 елларда Комиссия рәисе итеп Хренов Степан Григорьевич билгеләнә. Ул да рус милләтеннән була һәм татар теле өйрәнә (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 66).

1924 елдан башлап, эш кәгазьләреннән хат килгәнлеге турында хәбәр итүче чакыру кәгазьләре һәм почтаның юнәлешен күрсәтә торган юл кәгазе бланклары рус һәм татар телләрендә языла. Барлык мөһер, штемпель, эленмә такталар һәм почта тартмалары да ике телдә булдырыла (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 167). Болар белән генә чикләнмичә, Элемтә идарәсе авылларда җәяүле һәм атлы хат ташучылар хезмәтен файдалана башлый. Аларның төп максаты булып авыл халкын почта эшенә ныграк тарту, килгән хатларны крестьяннарның үз кулларына илтеп тапшыру куела. Бу эшкә

татарларны да күпләп тартырга тырышалар. Мәсәлән, 1925 елда 275 авыл хат ташучысының 109ы — татар, 7се — чуваш, 1се — мордва, 158е — рус була. Штаттан тыш та шундый хат ташучылар булдырыла. Алар барлыгы 113 булып, шуларның 33е — татарлар, 75е — руслар була. Шулай итеп, штаттагы хат ташучылар арасында татарлар һәм милли азчылык 42,54%ны, руслар 57,46%ны тәшкил итә. Ә штаттан тыш агентларның 33,62%ын татарлар һәм милли азчылык, 66,38%ын руслар алып тора (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 167).

Ләкин квалификацияне таләп итә торган хезмәтләргә татарларны җәлеп итү эше бик зур авырлыклар белән бара. Эшкә алганда татарларга өстенлек бирелсә дә, элемтә эшендә акча аз түләнү сәбәпле, белгечлеккә ия татарлар, бераз эшләгәч, башка җиргә күчүне мәгъкуль күрәләр, ә махсус белеме булмаганнары исә әзерлекле руслар белән алмаштырыла (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 166). Татар хезмәткәрләренең бик аз булуы элемтәне татарлаштыруга аяк чалучы зур сәбәпләрнең берсе була. Саннарга күз салыйк. 1924 елгы мәгълүматлар буенча, почта-телеграф эшендә 506 хезмәткәр эшли (кантоннар белән бергә). Шуларның бары 3се генә татар: берсе — җаваплы эштә, берсе — техник хезмәткәр, берсе — кара эшче (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 105). 1925 елга хезмәткәрләр саны азрак арткан: бөтен Татарстан республикасына 708 почта эшчесе. Ләкин татарлар саны бик азга гына күбәйгән: 11 кеше, ягъни барлык хезмәткәрләрнең 1,5%ы (Тезисы к докладу Ш.Шаймарданова, 1927, с. 23). Нәтиҗәдә Элемтә идарәсен татарлаштыру максатында чыгарылган аз санлы боерыклар да тулысынча тормышка ашырыла алмый. Мәсәлән, русча укый-яза белмәүче татарларны бик нык сөендергән яңалык: татарча адреслы хатларны кабул итә башлау да шул сәбәпле авырлыкка очрый. Чөнки, кагыйдә буенча, татарча адресны конвертның сул ягына язарга, ә уң ягын тәрҗемә өчен буш

калдырырга кирәк була (Красная Татария. — 1924. — 15 июль). Ә хат кабул ителгән почта бүлекчәсендә татар хезмәткәре булмаса, адресны тәрҗемә итү өчен башка җиргә җибәрергә мәҗбүр булалар. Ә бу исә, аңлашылганча, өстәмә мәшәкать тудыра, бушка күп вакыт сарыф ителә. Нәтиҗәдә хатлар адресатка соңга калып барып җитәләр (Отчет ЦИК и СНК к 5 съезду Советов, 1925, с. 31; Красная Татария. — 1924. — 25 сентябрь).

Дөрес, почта эшенә татарларны күбрәк җәлеп итү максатында, ТТГК Үзәк курслары карамагында 1924 елның 1 октябреннән почта-телеграф хезмәткәрләре хәзерләү циклы эшли башлый. Бу цикл регуляр рәвештә һәр елны почтада эшли алырлык 30-40 татар хезмәткәре әзерли. Курсларда гомуми белем фәннәре белән бергә, почта хезмәтенә караган махсус фәннәр дә укытыла. 1925 елгы беренче чыгарылышта 32 кеше курсларны бетереп чыга, шуларның 23е — татар (16 ир-ат һәм 7 хатын-кыз), 8е — керәшен (5 ир-ат һәм 3 хатын-кыз) һәм берсе — татарча яхшы белә торган рус хатыны. Аларның барысы да 1925 елның 23 июнендә хезмәткә билгеләнә: 5се — почта-телеграф бүлекчәсе мөдире; 9ы — почта-телеграф хезмәткәре; 15е — күчмә почта агенты; 2се — хат ташучы; 1се — практикант итеп җибәрелә (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 62). 1926 елның 28 апреленә шуларның 27се эшен дәвам итә, калганнарының исә 3се үз теләге белән эштән китә, 1се хезмәт урынындагы җинаять өчен чыгарыла, 1се вафат була (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 62).

Ел саен дип әйтерлек бу курслар почта хезмәткәрләрен әзерләп тора, ләкин аларның алган белемнәре Элемтә идарәсен канәгатьләндерми. Бу турыда идарә үзенең хисапларында һәм чыгышларында һәрвакыт әйтеп килә. Гомуми белем дәрәҗәсе җитәрлек булмаган, рус телен начар белгән курсантлар уку вакытында махсус предметлар буенча рус телендә уздырылган

дәресләрне аңламыйлар, тиешенчә кабул итә алмыйлар. Штаты бик нык кыскартылу сәбәпле, һәр хезмәткәре үзенең эшен төгәл һәм тиз үтәргә тиеш булган почтага эшкә килгәч, тәҗрибәсез курсантлар үзләреннән таләп ителгән хезмәтне үти алмыйлар, моның белән башкаларның ачуын чыгаралар. Нәтиҗәдә, аларны аппаратта калдыру өчен, бөтенләй квалификациясез яки ярымквалификацияле эшкә утыртырга мәҗбүр булалар (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 166 об.).

СССР почта һәм телеграф халык комиссариаты күрсәтүе буенча, алга таба курсантлар кабул иткәндә, аларның 2 нче баскыч мәктәптән дә ким булмаган белемгә ия булулары, русча яхшы белүләре, 17дән 25 яшькә кадәр булулары таләп ителә (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 166 об.).

ТТГК Үзәк курсларыннан тыш, 1925 елда авыл почта мөдирләре әзерләү максатында, Элемтә идарәсе өч айлык профтехник курслар оештыра. Аларда төрле милләт кешеләре белем ала: татарлар, чувашлар, марилар һәм удмуртлар. Барлыгы 11 татар укып бетереп, шуларның 4се — почта мөдире, 5се — квалификацияле хезмәткәр, 2се ярымквалификацияле хезмәткәр дәрәҗәсе алып чыга (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 166).

Почта-телеграф өлкәсендә ТТГК эше 1926 елда аеруча җанлана. Бу елның 20 апрелендә булган учреждениеләрдәге ТТГК өчлекләре вәкилләре киңәшмәсендә Элемтә идарәсенең доклады да тыңлана. Аны комиссия әгъзасы Заболоцкий ясый һәм Элемтә округында ТТГКдагы каршылыкларны яшермичә, бөтен барлыгы белән ачып сала. 7 кешедән торган комиссия тарафыннан төзелгән резолюциядә (комиссиягә Элемтә идарәсеннән, Үзәк комиссиядән, Татторгтан һәм Үзәк курслардан вәкилләр кертелә) түбәндәге йомшак яклар аерып күрсәтелә: 1) почта һәм телеграфның хәзерге тормыштагы әһәмиятен яктыртып, аны популярлаштыручы татар телендәге әдәбиятның

бөтенләй булмавы; 2) телефон челтәрендә эшләүчеләрдән аерым квалификация таләп ителмәсә дә, алар арасында татар телен белүче хезмәткәрләрнең булмавы; 3) хәзергә кадәр почта-телеграф аппаратын хәтта элементар дәрәҗәдә дә башка халыкларга яраклаштырмау, мәсәлән, бланк һәм башка почта кәгазьләрен рус һәм татар телләрендә бастыруның да күзәтелмәве; 4) татар халкына хезмәт күрсәтүче учреждениеләр белән татар телендә язышуның бөтенләй куелмавы (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 48).

Бу җитешсезлекләрне юкка чыгару өчен тәкъдим ителгән чаралар, кызганычка каршы, инде күп мәртәбәләр кабатланган һәм тормышка ашырылмаган боерыкларны яңадан әйтеп үтүдән гыйбарәт. Мәсәлән, почта өлкәсендәге әдәбиятны татар теленә тәрҗемә итәргә; бланкларны һәм башка кәгазьләрне татар телендә бастырырга; татар халкына хезмәт күрсәтүче почта-телеграф учреждениеләре арасындагы язышуны татар телендә тәэмин итәргә; телефон аппаратына үзәктә дә, урыннарда да татар телен белүче хезмәткәрләрне җәлеп итәргә; мөмкин булган урыннарда татар телендә һәм татар хәрефләре белән язылган телеграммаларны кабул итәргә; үзәктән акча сорарга; рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү эшен көчәйтергә һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 767, лл. 48-49).

Доклад буенча фикер алышулар вакытында Заболоцкийны «элемтә аппаратында татарлар эшли алмый һәм киләчәктә дә эшли алмаячак» дигән фикер тудыруда гаепләүчеләр күп була. Бары чынбарлыкны ничек бар, шулай яктыртудан гыйбарәт булган чыгыш турында хәтта «бу череп беткән үткәннең калдыгы түгел микән?» дигән фикер әйтүчеләр дә табыла (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 51). Ахырда Элемтә идарәсендә ТТГК эше канәгатьләнерлек түгел дигән нәтиҗәгә киләләр, Элемтә округына татар хезмәткәрләрен алу мәсьәләсе кабат сорау астында кала.

Чыннан да, 1926 елгы мәгълүматлардан күренгәнчә, Элемтә идарәсе татар халкының 55%тан артыгына хезмәт күрсәтә, ә үзенең барлык эшләре дә диярлек рус телендә генә алып барыла (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 51). 1926 елның 8 июненә Татарстандагы почта, телеграф һәм телефон хезмәткәрләренең гомуми саны 1092гә җитә, аларның бары 42се генә татар милләтеннән була (3,84%), шулар арасында да җаваплы хезмәткәрләр: руслар — 65, татарлар — 1; канцелярия эшчеләре: руслар — 150, татарлар — 2 (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 74). Бары авыллардагы хат ташучылар (105 татар, 273 рус) һәм штаттан тыш агентлар (33 татар, 104 рус) исәбенә генә татарларның саны аз булса да арта: 4%тан 11%ка җитә (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 51). Казандагы идарәнең үзендә дә татарларның саны буенча хәлләр бик авыр була: 93 хезмәткәрнең бары 1се генә татар! (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 74)

1926 елның 16 июнендә Округ башлыгы Хренов имзасы белән ике телдә дә боерык игълан ителә. Анда элемтә өлкәсендә татар теленең бик аз гамәлгә куелуына басым ясала, рус хезмәткәрләре дә татар телен начар өйрәнәләр, татар телендәге әдәбият та юк һ.б. Шуңа күрә түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

«1) Ярымквалификацияле яки квалификациясез урыннар бушаганда, Связьнең үз союзында эшсезләр булмаса, ике телне дә белә торган эшче сорап, урындагы ТТГК комиссиясенә мөрәҗәгать кылырга. Комиссия яраклы кеше юк дип язу җибәргәндә, русча гына белүчене куярга;

2) берәр гаепле эш белән булмыйча, штатны кыскартып яки башка берәр сәбәп белән татар эшчеләрен урыннан чыгарганда, урындагы ТТГК комиссиясе белән берлектә эшне йөртергә;

3) совет, кантон, волость һәм авыл учреждениеләре белән язышмаларны ике телдә: русча һәм татарча, йөртү турындагы почта-

телеграф идарәсенең 27 апрель, 1926 елда чыккан циркулярын тормышка үткәрергә;

4) эшче һәм крестьян халкына файдалы эшчеләр хәзерләү өчен, татар эшче һәм практикантларының квалификацияләрен күтәрергә төрле чаралар күрергә;

5) шушы елның көзеннән үк башка предприятиеләрдәге эшчеләр белән бергә, Связьдә эшләүче русларның татарча укуларын арттырырга, шуның өчен урындагы ТТГК комиссиясе белән берләшергә;

6) ике атна эчендә почта-телеграф идарәсенә 1925 елның 1 октябреннән бирле ТТГК юлында эшләгән эшләрегез турында һәм 1926/27 ел өчен төзелгән эш планын тапшырырга. ...Аппаратны татарлаштыру эшенә каршы килү сизелсә, андый мөдирләрне алыштыру турында сүз кузгалачак» (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 52).

1925/26 еллар өчен бирелгән хисаптан күренгәнчә, бу боерыкларның күбесе тормышка ашырылган (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 58). Моннан тыш, 1926/27 елларда тәҗрибә рәвешендә элемтә оешмаларына 25-30 татар кешесен өйрәнчек итеп алу күздә тотыла, шулай ук телефон челтәренә дә өйрәнчекләр аша хезмәткәрләр әзерләү турында сүз бара (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 58). Төрле игъланнар ике телдә дә бастырыла башлый. 6 татар яшүсмерен предприятиеләр штатына кертү хакында карар кылына. Мәгариф комиссариатына, мәктәп укучылары һәм олыларны элемтә өлкәсендә белемлерәк итү максатында, татар телендә язылган 370 экземпляр кыскача почта кагыйдәләре тапшырыла. Татарстаннан читтә яшәүче татар почта эше белгечләрен республикага тарту максатында, Чувашия белән хезмәткәрләр алмашу үткәрелә, ә Округтан читтә булган урыннардан почта эшчеләрен кайтарту өчен исә, акча булмау

сәбәпле, ул хезмәткәрләр үз акчаларына күчсәләр генә ризалык бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 74а).

Күренгәнчә, квалификацияле татар хезмәткәрләре булмау, акча бүлеп бирелмәү Элемтә идарәсендә ТТГКда иң зур каршылыкларны тәшкил итәләр. Бу өлкәдә күп санлы карарлар кат-кат чыгарылуга да карамастан, аларның бик азы гына тормышка ашырыла. Бишьеллык ТТГК планының элемтә өлкәсендә үтәлә алмаячагы көн кебек ачык була һәм моны идарә җитәкчеләре үзләре дә инкяр итмиләр (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 75).

Кызганычка каршы, 1926 елдан соң Элемтә идарәсендә ТТГК турында тулы мәгълүматлар юк, булганнары да анда эшләүче хезмәткәрләр саны хакында гына. 30 нчы елларда почта эшендә татар телен файдалану мәсьәләсе һаман чишелмичә калган булырга тиеш. Хәтта күпме еллар буе барган татар хезмәткәрләрен арттыру омтылышы да ахыр чиктә көтелгән нәтиҗәләргә китерми: 1936 елгы мәгълүматлар буенча, Элемтә идарәсендә эшләүче татарлар 19%ны гына тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 26). Шулай да хәзерге чор белән чагыштырганда, әле 20 нче елларда почта-телеграф эшендә азмы-күпме уңышларга ирешкәннәр. Кызганычка каршы, бүгенге көндә элемтә өлкәсендә татар теле бөтенләй диярлек файдаланылмый: татарча язылган бланклар, эш кәгазьләре юк, хезмәт күрсәтү рус телендә генә алып барыла, хатларга адреслар рус телендә генә языла һ.б. Күренгәнчә, 20 нче еллардан үрнәк яки сабак аласы эшләр әле бу өлкәдә дә җитәрлек.

2.3. <u>Сәламәтлек саклау халык комиссариатында ТТГК</u>. Сәламәтлек саклау халык комиссариаты һәм аның карамагындагы учреждениеләрдә татар телен тормышка үткәрү беренче елларда җитәрлек дәрәҗәдә җайга салына алмый. Бары 1924 елдан гына азрак күтәрелеш башлана һәм моңа бу елның 25 октябрендә

комиссариат карамагында ТТГК өчле комиссиясе төзелү дә уңай йогынты ясаган булырга тиеш.

Өчле комиссиянең рәисе итеп Коллегия әгъзасы, Администрация-финанс бүлеге мөдире Бикчурин Шәфигулла Вәлиуллович, комиссия әгъзалары итеп Ана һәм балаларны саклау бүлекчәсе рәисе Фәйзуллина Мәчтүрә Гыйльмановна һәм Аптека секциясе бюросы сәркатибе Лейзеровский (икенче чыганакта — Майзаровский) Абрам Моисеевич билгеләнә. Беренче икесе — милләтләре буенча татарлар һәм татарча укый-яза беләләр, соңгысы исә яһүд һәм татарча бик начар белә (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 15 об.). Бу өч кешедән тыш, практик эшләрне Администрация-финанс бүлеге сәркатибе Мусин башкара.

Комиссия Сәламәтлек саклау комиссариаты һәм Медторгка кергән барлык учреждениеләрдә ТТГК эше белән житәкчелек итә. Казан шәһәренең үзенең генә дә бу тармактагы 70 учреждение һәм аларда эшли торган 2456 хезмәткәр исәптә була. Шуларның бары 223ен генә, ягъни 9,08%ны татарлар тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 41 об.).

Комиссариат карамагындагы оешмаларның бик күп булуы сәбәпле, ТТГК өчле комиссиясе аларның барысын да тикшереп бетерә алмый. Урыннарда татар телен гамәлгә кую һәм өчле комиссия белән бәйләнештә тору өчен, махсус вәкилләр булдыру кирәклегенә басым ясала (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 42 об.). Мондый вәкилләр кайбер учреждениеләрдә булдырыла, ләкин ТТГК эше белән генә шөгыльләнүче аерым штатны тоту өчен акча булмау сәбәпле, алар берьюлы берничә эшне алып баралар (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 94).

Казандагы барлык медицина учреждениеләрендә һәм комиссариат аппаратында эш башкару рус телендә генә алып

барыла. Татарча гаризалар комиссариатта Мусин тарафыннан тәрҗемә ителәләр һәм җаваплар да татарча бирелә. Комиссариатта да, учреждениеләрдә дә махсус тәрҗемәче булмый (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 42 об.).

Комиссариатның нәшрият бүлегендә киң таралыш алырга тиешле барлык карарлар татар теленә тәрҗемә ителә. Әдәбияттан исә 1925 ел ахырына 6 брошюра татарчага тәрҗемәдә басылып чыга : 1) «Трахома»; 2) «Венерик авырулар»; 3) «Себер язвасы»; 4) «Скарлатина»; 5) «Малярия»; 6) «Пионер, үзеңнең саулыгыңны сакла!» (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 42 об.).

Комиссариатта техник җайланмалар: штамплар, эленмә такталар һәм мөһерләр ике телдә дә булдырыла. Бүлмәләрнең урнашу тәртибен күрсәтүче такталар да ике телдә әзерләнә.

Комиссариатның үз аппаратында практикантлар булмаса да, Медторг исәбенә бу күрсәткеч тулылана. Һәр ел саен диярлек 10-15 татар студенты Медторг ярдәме белән фармацевтика техникумында яки мәктәбендә укый, аларга ай саен стипендия түләнә. Нәтиҗәдә Медторг үзе өчен аптека хезмәткәрләре әзерләп чыгара (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 42). Гомумән, ТТГК өчен Медторгта, комиссариат белән чагыштырганда, шартлар яхшырак була, чөнки склад яки кибетләрдә эшләү өчен татарларны алу һәм эш башыннан түләү хакына эшчеләр җәлеп итү Медторгка авырлык тудырмый, бары азрак тырышлык кына таләп ителә. Шуңа күрә ТТГК Үзәк комиссиясе 1925 елның февралендә Медторгка татарларның санын арттыру, ТТГКны көчәйтү хакында мөрәҗәгать итү белән үк, шул ук елның августына татар эшчеләренең саны 50%ка арта, ягъни 4,2%тан 9,81%ка җиткерелә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 42). Ә комиссариат һәм хастаханәләрдә исә хәл авыррак була. Хәтта иң түбән эшчеләрдән саналган санитар булып эшләү өчен дә махсус санитарлар курсын

бетерү таләп ителә, ә югарырак квалификацияле белгечләр турында инде әйтеп тә торасы юк. Шунлыктан бу өлкәгә татарларны җәлеп итү эше бик акрынлык белән бара. 1925 елда 7 ай эчендә Медторгта эшләүче татар хезмәткәрләренең саны ике тапкыр артса, комиссариат һәм аның карамагындагы учреждениеләрдә исә 10,3%тан 8,74%ка кими (ф. 732, оп. 1, д. 768, л. 56). Казан университетының медицина һәм физика-математика факультетларына татарлар бик аз санда кабул ителә: мәсәлән, 1925 елда алар барлык студентларның 5%ын тәшкил итәләр (Отчет ЦИК и СНК к 5-му съезду Советов, 1925, с. 30). Махсус әзерлеге булмаган татарларны, ике телне дә белүләре өчен генә эшкә алу, билгеле, мәсьәләне хәл итү юлы була алмый. Мондый чара кешеләрне дәвалау кебек әһәмиятле эшне үтәүгә комачаулык кына итәр иде. Бу юлдан чыгу өчен, 1925 елдан башлап, татарларны медицина вузларына күбрәк җәлеп итү, фармацевтика һәм медицина техникумнарында татарлар өчен әзерлек группалары булдыру кебек эшләр башкарыла.

Хастаханә, клиника, диспансер, амбулатория һәм башка медицина учреждениеләрен тикшерү барышында рус телен белмәүче авыруларның бик авыр хәлдә калуына басым ясала. Мәсәлән, 1924 елның 19 мартында ТТГК инструкторы Н.Юнысов икенче номерлы хастаханәне тикшергәннән соң, барлык авыруларның 30%ын тәшкил итүче татарларның үтенечләре канәгатьләндерелмәвен күрсәтә. Хастаханәдә эшләүче хезмәткәрләрнең гомуми саны — 133, һәм шуларның бары 5се генә — татар. Аларның 2се врач, 3се исә гади эшче, ә фельдшер, палата карауычысы, хуҗалык-администрация персоналы, канцелярия эшчесе, санитарлардан бер генә татар да булмый. Сиделкалар да, «...әллә ялкаулыктан, әллә татар телен аңламаганлыктан, авыруларның

үтенечләренә колак салмыйлар» (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 94). Хезмәткәрләр «дәваланучыларның телдән берәр нәрсә сорауларына иңбашларын сикертү белән генә җавап бирәләр» (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 94). Эленмә такталар, игъланнар да русча гына язылган. Китапханәдә татар телендәге әдәбият булса да, татарча белүче хезмәткәрләр булмау сәбәпле, татар авыруларына китаплар бирелми. Рус телендәге газета алдырсалар да, татарча газетага язылу булдырылмаган һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 94). Әлеге хәл барлык хастаханә һәм клиникалар өчен дә диярлек табигый була.

Бу юлдан чыгу өчен, 1925 елның 28 октябрендә махсус әзерлек таләп ителмәгән, ләкин авырулар белән еш аралаша торган хезмәт урыннарын, мәсәлән, кабул итү бүлмәләрендәге хезмәткәрләрне, сиделка, санитар, регистратор кебек хезмәт күрсәтүче персоналны ике телне дә белүчеләр белән алмаштыру турында карар кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 7) һәм ул тиз арада тормышка да ашырыла башлый.

Татарларны эшкә алудан тыш, ике телне дә белүче хезмәткәрләрне кыска сроклы курсларда укытып әзерләү эше дә башланып китә. 1924 елда ук 42 татар кешесе 6 айлык санитарлар курсын тәмамлап чыгалар. Алар Казанның төрле дәвалау-санитар учреждениеләренә һәм кантоннарга җибәрелә, бер өлеше малярия, трахома һ.б. отрядлар белән китә, бер өлеше медтехникумга укырга керә (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 98). Әлеге тәҗрибәне дәвам итеп һәм ТҮБК тарафыннан 1925 елның 16 октябрендә чыгарылган карар нигезендә, Сәламәтлек саклау комиссариаты 1925 елда да 1 еллык санитарлар курсы оештыра. Әлеге курсларга 50 татар хатын-кызы кабул ителә. Укыту татар телендә алып барыла. 12 ай дәвамында курсантлар 840 сәгать теория узалар, 400 сәгать семинарлар үткәрәләр, һәм 140 сәгать практик эшләргә китә. Беренче 10 айда

кирәк булган 21 предметтан иң күп сәгатьләр рус һәм татар телләренә бирелә: 144шәр сәгать (чагыштыру өчен: табигать белеме — 56 сәгать, гомуми биология — 32 сәгать, дезинфекция — 10 сәгать, гигиена һәм санитария нигезләре — 40 сәгать, авыруларны карау — 32 сәгать, тире-венерик авырулар — 20 сәгать һ.б.) (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 100). Курсантлар Хезмәт Биржасындагы эшсезләр арасыннан белемнәрен махсус тикшерү нәтиҗәсендә кабул ителәләр. Барысының да белем дәрәҗәләре мөмкин булганча бертөрле булырга тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 101 об.). Санитарлар курсын тәмамлаучыларның ничек эшләп китүләре хакында тулы мәгълүматлар юк. Бары Клиник институттан гына доктор Эпштейн бу курсларны тәмамлап килгән 6 кешенең бик авыр эштән куркып китеп баруларын әйтеп үтә (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 3). Бу, бәлки, санитарларның чын больница хәлен белеп, анда эшләп түгел, ә очраклы рәвештә «урамнан» килүләре белән аңлатыладыр.

Санитарлар курсларыннан тыш, татар хатын-кызлары өчен «Әниләр һәм балаларны саклау» һәм акушерлар курслары оештырыла. «Әниләр һәм балаларны саклау» курслары 1925 елның 24 октябрендәге ТТГК ҮК президиумы карары нигезендә 4 айлык итеп оештырыла. Алдан ук кантон сәламәтлек саклау бүлекләренә хәбәр ителеп (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 42), һәр кантоннан 1-2 хатын-кыз Казанга укырга җибәрелә һәм алар, укып бетергәннән соң, авылларына кайтып, кечкенә балаларны дәвалау хезмәтен үти башлыйлар (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 22).

Татар акушерлык курслары 1925 елның декабрендә ачыла. Медицина техникумы карамагындагы әлеге курслар 2 ел ярымлык итеп оештырыла, керүчеләрдән 7 еллык белем таләп ителә, шулай да беренче тапкырында кантоннардан килгәннәр өчен ташламалар да ясала. Курсларга барлыгы 48 кеше кабул ителә: 46 татар, 1 башкорт

һәм 1 рус. Кантоннардан килгән 20 кешегә тулай торактан урын бирелә. Ләкин дәресләр медтехникумдагы клубта, уку өчен җайлаштырылмаган, хәтта парталары да булмаган бүлмәдә үткәрелә. Шулай ук медицина буенча дәреслекләр булмау, акчаның җирле бюджеттан бик аз бирелүе дә эштә зур тоткарлык тудыра. Дәресләр татар телендә алып барыла, медицина фәннәреннән тыш, татар, рус телләренә дә урын бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 29).

Татарлар арасыннан хезмәткәрләр әзерләгәндә, медицина буенча татарча дәреслекләрнең аз булуы авырлык тудыра. Врачларның үзләреннән кала, медицина дәреслекләрен төзү яки русчадан тәрҗемә итү эшен беркем дә төгәл һәм дөрес башкара алмаячагын аңлаган медицина белгечләре җыелып, бу мәсьәлә буенча киңәшмәләр дә үткәрәләр. Әбүбәкер Терегуловның «Гигиена», Габдулла Шнасиның «Физика», Салих Корбангалиевнең «Химия» дәреслекләре медицина техникумнары өчен яраклы дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 27 об.). 1926 елга кадәр чыккан медицина буенча татарча дәреслекләрне карап чыгу, кирәк булган дәреслекләрнең планын төзү һәм аны Гыйльми үзәктән раслату максатында, махсус комиссия төзелә. Аның составына татар табиплары: Ә.Терегулов, С.Корбангалиев, Х.Еникеев, Н.Максудов, Г.Шәрәфетдинов, Кугушев, Йосыпов, Акушерлык курслары мөдире Б.Биккенин керә. Татарча дәреслекләр медицина техникумында укучы 300 студент, медицина хезмәткәрләре һәм, гомумән, кызыксынучыларның ихтыяҗын канәгатьләндерергә тиеш була, шулай ук вузларның кайбер өлгермәүче студентлары да алардан файдалана алалар (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 28).

Дәреслекләрнең төп нигезен тәшкил иткән фәнни терминология мәсьәләсе дә татар табипларын борчый. Медицина техникумында оештырылган татар медицина түгәрәгендә махсус терминология

комиссиясе эшли. Корбангалиев әлеге түгәрәк эшенә барлык татар табипларының да актив катнашуларын үтенә (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 28). Беренче чиратта кирәк булган татарча дәреслекләр исемлеге түбәндәге тәртиптә бирелә: 1) анатомия, физиология һәм гистология; 2) бактериология һәм гомуми патология; 3) акушерлык һәм гинекология; 4) тире-венерик авырулар; 5) хирургия; 6) фармация һәм фармакология; 7) балалар авырулары; 8) терапия; 9) социаль гигиена (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 28).

1925 елның 26-28 октябрь көннәрендә ТТГК инструкторларының Казанда булып узган киңәшмәсендә Сәламәтлек саклау комиссариаты докладı да тыңлана. Өчле комиссия рәисе Бикчурин чыгышы һәм фикер алышулардан соң, комиссиянең эшчәнлеге канәгатьләнерлек дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 7). Чыннан да, ТТГК юлында Өчле комиссия зур тырышлыклар күрсәтә. Шулай ук Сәламәтлек саклау халык комиссарының (Мөхәммәдьяров) һәм югары урыннарда эшләүче җитәкчеләрнең күбесенең татар булуы да эшкә уңай тәэсир ясамый калмагандыр, мөгаен. Өчле комиссиянең киңәйтелгән утырышлары еш уздырыла, ел саен дип әйтерлек перспектив планнар төзелә. Утырыш беркетмәләреннән күренгәнчә, Клиник институт, Округ психиатрия дәвалау йорты, Медторг, Медсантруд һ.б. бик күп медицина учреждениеләре катнашында үткәрелгән киңәйтелгән җыелышларда татарлар гына түгел, башка милләт зыялылары да татар телен тормышка үткәрү эшен яклап, аңа ничек булса да ярдәм итәргә тырышуларын белдерәләр, авырлыкларны бетерү юллары хакында киңәшәләр. Башка милләт белгечләре тарафыннан татар теленә карата шундый теләктәшлек күрсәтү Сәламәтлек саклау комиссариатында, башка комиссариатлар белән чагыштырганда, күбрәк күзәтелә. 1925 елның 11 сентябрендә комиссариатның 40лап

учреждениесе катнашында уздырылган җыелышта Медсантруд вәкиле Михайлов хәтта шундый теләкләр белән чыгыш ясый: «...медицина-санитарлык хезмәткәрләре һәм киңәшмәдә катнашучылар, татар телен шундый дәрәҗәдә өйрәник, киләсе елда ТТГК ҮК вәкиленә: «Докладыгызны татар телендә ясагыз» дип әйтерлек булсын!» (ф. 732, оп. 1, д. 782, л. 2). Кызганычка каршы, әлеге изге теләк ул дәрәҗәдә үк тормышка ашырыла алмый, рус хезмәткәрләре арасында татар теле өйрәнүчеләр күп булса да, иркен рәвештә татарча аңлый һәм сөйләшә алучылары бармак белән генә санарлык була.

Күп еллар буе татарларны медицина учреждениеләренә күбрәк җәлеп итәргә тырышу, штат кыскарту вакытында да татарларга өстенлек бирү кебек эшләр нәтиҗәсендә, сәламәтлек саклау оешмаларында эшләүче татарларның саны арткannan арта бара. 1936 елгы мәгълүматлар буенча, бу елда Сәламәтлек саклау комиссариатында эшләүчеләрнең 42,5%ын татарлар тәшкил иткән (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 26). Комиссариаттагы «аппаратка җирле халыкны тарту» эшенең торышын тикшергәннән соң, инструктор Крелина татар хезмәткәрләрен җәлеп итүдән башка эшләрнең начар куелуына басым ясый. Моны дәлилләү өчен, татар районнары белән язышуның рус телендә генә алып барылуын күрсәтә. Хәтта шундый фактлар да күзәтелә: районнардагы татар хезмәткәрләре комиссариатка татарча язалар, ә аларга рус хезмәткәрләре генә түгел, татарлар да рус телендә генә җавап бирәләр (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 3). Татар авыруларын кабул иткәндә исә алар белән аралашу татарча алып барыла (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 4). Шулай ук районнарда да татар теленең начар гамәлгә куелуына басым ясала: елына 5-6 район сәламәтлек саклау бүлеге мөдирләре алмашына. Мөслим районы башкарма комитеты сәламәтлек саклау мөдире итеп

бөтенләй надан санитарканы билгеләп куйган, нәтиҗәдә врачлар да, район оешмалары да аның белән исәпләшергә теләмиләр (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 4).

Сәламәтлек саклау халык комиссариатының татар телен гамәлгә куюдагы эшчәнлегенә йомгак ясап, шуны әйтергә мөмкин: күп еллар дәвамында комиссариат татарларны медицина учреждениеләренә күбрәк җәлеп итү юнәлешендә эш алып бара һәм бу өлкәдә сизелерлек нәтиҗәләргә ирешә: медицина уку йортларына татарларны кабул итү арта, татарлар өчен әзерлек группалары булдырыла, төрле курслар оештырыла, татар телендәге дәреслекләр языла, татарча медицина терминнары эшләнә, рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү эше алып барыла, татарча брошюралар әзерләнә, карарлар татарчага тәрҗемә ителә һ.б. Кантоннар белән язышуның рус телендә алып барылуы гына үзгәрешсез кала. Гомумән әйткәндә, Сәламәтлек саклау комиссариатында ТТГК эше авырлыклар белән барса да, башка кайбер комиссариат һәм оешмалар белән чагыштырганда, яхшырак җайга салына.

2.4. Эчке эшләр халык комиссариатында ТТГК. Эчке эшләр комиссариатында (НКВД) ТТГК эше белән җитәкчелек итүче өчле комиссия 1925 елның 22 февралендә төзелә. Аның составына зур урыннарда эшләүче 3 татар кешесе кертелә: комиссия рәисе вазифасын ТАССР милиция башлыгы һәм ТНКВД комиссиясе әгъзасы Дәҗҗал Терегулов башкара, әгъзалар итеп Казан шәһәре милиция башлыгы Әхмәдиев Кирам һәм НКВДның «секретная часть» мөдире Сәлимов Кәрим билгеләнәләр (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 7).

Эчке эшләр комиссариаты үзе 5 бүлектән тора: Административ (ЗАГС белән бергә), Милиция, Җинаятьчеләрне эзләү бүлеге (Уголовный розыск), ГиМЗ (гаупвахты и места заключения) һәм

Финанс-хуҗалык бүлеге (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 9). Аларның барысы да, соңгысыннан кала, татар халкы белән тыгыз бәйләнештә эшли, шунлыктан эшкә татарларны күбрәк җәлеп итү, татар халкы өчен тиешле шартлар тудыруга игътибар бирелә.

1925 елга кадәр Эчке эшләр комиссариатының ТТГК өлкәсендәге эшчәнлеге тәнкыйть күзлегеннән чыгып кына бәяләнә. Мәсәлән, Үзәк комиссия инструкторы Н.Юнысов 1924 елда комиссариатларны тикшереп чыгып, НКВД буенча түбәндәге нәтиҗәләргә килә: «Эчке эшләр халык комиссариатында ТТГК эшләре акрын һәм начар бара. Кантоннарда татар эшчеләре бөтенләй юк. Мәркәздә заявлениеләр кабул ителсә дә, кантоннарда кабул да ителми, җавап та бирелми. Руслар өчен ТТГК курслары булмаган. Реорганизация вакытында татарлар бик күп чыгарылган» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 106). Юнысовның хисабында шулай ук НКВДда эшләүчеләрнең саны турында да мәгълүматлар бар. Аннан күренгәнчә, комиссариатта барлыгы 69 хезмәткәр эшли, шуларның 21е — татар, аларның да 1се генә җаваплы хезмәткәр, 9ы — техник хезмәткәр, ә 11е — кара эшчеләр (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 106). Бу мәгълүматлар буенча, татарларның саны (кара эшчеләрдән тыш) 14,5%ны тәшкил итә, ә икенче чыганакта исә ул 15,4% дип күрсәтелә (барысы 65 хезмәткәр, 10сы — татар) (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 32). 1925 елның 1 октябренә татарларның саны бөтен штат буенча 35%ка җитә (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 9).

Комиссариат аппаратында ТТГК эше канәгатьләнерлек җайга салына: ведомство бланклары, таныклыклар һәм башка документлар ике телдә дә эшләнә, татар телендә телдән һәм язмача мөрәҗәгатьләр кабул ителә, үтенеч белән килгән татарлар белән сөйләшүләр татарча алып барыла, аларга аңлатмалар да ана телләрендә бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 9).

Татарларны эшкә күбрәк җәлеп итү комиссариатның төрле бүлекләрендә төрлечәрәк тора. Бу яктан бигрәк тә Милиция бүлеге алда бара. 1922 елга кадәр милиционерлар арасында татарлар 2-3%ны гына тәшкил иткән булса, еллар үткән саен, бу сан арта бара: 1922 елда — 10-12%, 1924 елда — 33% була, ә 1925 елда исә татарлар һәм татарча белә торган милиция хезмәткәрләре саны 50%ка җитә (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 10).

Казан шәһәрендә барлыгы 6 милиция районы булып, шуларның бишенчесендә бөтен эш татарча алып барыла, хезмәткәрләрнең дә барлык составы татарлардан гына тора. Икенче һәм алтынчы районнарда исә татар телендә пассив эш йөртелә, ягъни татарча гаризалар кабул ителә, аларга татар телендә җавап бирелә, татарлардан сорау алу, сөйләшүләр дә татарча алып барыла (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 10).

Милициядә җитәкче урыннарга татарларны җәлеп итү ягыннан да зур кампания башланып китә. Башкаладагы 6 район идарәсеннән 4сендә милиция башлыклары һәм аларның ярдәмчеләре итеп татарлар билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 92). Эшкә алганда, беренче чиратта милләтенә әһәмият итәләр, аннары гына — партиялелегенә (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 10).

Кантоннарда да милиция аппаратын татарлаштыру буенча эш алып барыла: 12 кантонның 7сендә милиция башлыклары итеп татарлар куела (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 92), татар халкы күпчелекне тәшкил иткән 80 волостьның 60ында волость милиция башлыклары да татарлардан билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 10). Татар телендә эш йөртү 46 волостьта гына тулысынча кертелә, алга таба 80 волостьның барысында да татарча эш башкаруга күчү хакында карарлар кабул ителә һәм бу юнәлештә актив эш башлана (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 11).

Милиция өчен татар хезмәткәрләре әзерләү максатында, Главмилиция карамагында 1922 елдан ук махсус курслар эшләп килә (ф. 732, оп. 1, д. 154, л. 17). Кантоннарда татар канцелярия эшчеләренең җитешмәве ТТГК эшенә зур тоткарлык тудыра һәм нәтиҗәдә 1922 елда НКВД акчасына татар волость сәркатипләре курслары эшли башлый, курсантлар азык-төлек һәм тулай торак белән тәэмин ителәләр (ф. 732, оп. 1, д. 117, л. 162).

НКВДның Җинаятьчеләрне эзләү бүлегендә татар хезмәткәрләренең саны 23%ка җитә. Татарларны тагын да күбрәк җәлеп итүгә квалификацияле белгечләрнең булмавы тоткарлык ясый. Бу бүлектә руслар өчен татар теле түгәрәге эшли (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 11).

ЗАГС бүлеге дә шактый дәрәҗәдә татарлаштырыла. Эчке эшләр комиссариаты тарафыннан ике телдә дә ЗАГС өчен бланклар һәм китаплар әзерләнә (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 29), татар телендә язылган гаризалар кабул ителә. Казан шәһәрендә дә, кантоннарда да ЗАГС ике телдә хезмәт күрсәтүгә корыла. Башкаладагы ЗАГС бүлегенең башлыгы итеп татар кешесе билгеләнә, башка татар эшчеләре дә татар телендә хезмәт күрсәтүгә әзер торалар (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 21).

НКВДда эшләүче татар хезмәткәрләренең санын билгеләүдә төрлелек хөкем сөрә. Моңа бер чыганакта кара эшчеләрне дә кертеп санау, икенчеләрендә исә бары җаваплы һәм техник хезмәткәрләрне генә исәпкә алу йогынты ясаган булырга тиеш. Мәсәлән, әле 1925 елның 1 октябренә үк татар хезмәткәрләренең саны 35%ка җитте диеп күрсәтелсә (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 9), икенче чыганакта 1926 елның 1 январенә бу сан 24,7%ка гына кала (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 25). Ә 1929 елның 1 январенә тагын арта: 39,8%ны тәшкил итә (барлык хезмәткәрләр — 93, татарлар — 37) (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л.

25). Шулай да 1921 елгы 2-3% белән чагыштырганда, татар хезмәткәрләренең санын 40%ка җиткерү шактый зур уңышлардан санала ала.

Күренгәнчә, Эчке эшләр халык комиссариатында татар хезмәткәрләрен күбрәк җәлеп итүгә зур әһәмият бирелә, бу максат белән махсус курслар оештырыла, бигрәк тә Милиция һәм ЗАГС бүлекләрендә татар телендә хезмәт күрсәтүгә зур урын бирелә. Тик шунысы кызганыч: 30 нчы елларда бөтен халыкны куркытып торган НКВД составында татар хезмәткәрләренең күплеге дә күренекле татар шәхесләрен юкка чыгаруга киртә булып тормаган.

2.5. Юстиция халык комиссариатында ТТГК. ТТГК эшләре яхшырак куелган комиссариатларның тагын берсе — Юстиция комиссариаты. Бу юнәлештә эш алып барганда, ике бурычны үтәү күз алдында тотыла: 1) үзәк һәм җирле хөкүмәтнең кодекслары, законнары һәм карарлары белән халыкны үз ана телендә таныштыру мөмкинлеге тудыру; 2) татар районнарында суд эшләрен алып баруны һәм судлашучы якларның сөйләвен татар телендә булдыру (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 28). Беренче бурычны үтәү йөзеннән, үзәк хөкүмәтнең киң халык массаларына юнәлтелгән барлык карарлары «ТССР законнар җыентыгы»нда ике телдә дә бастырыла башлый. Баштарак татар телендәге карарлар рус телендәгеләргә караганда шактый соңга калып чыгарыла. 1925 елдан бу эш җайга салына: рус һәм татар телләрендәге закон текстлары бер китапта һәм бер үк вакытта чыга башлый, ТР законнар җыентыгының 27 августта чыккан 32 нче номерыннан алып бу эш шул юнәлештә дәвам иттерелә (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 94).

Законнардан тыш, рус телендәге кодексларны татар теленә тәрҗемә итү эше дә киң җәелеп китә. Әлеге эш 1924 елның 15 февраленә тәмамланырга тиеш булса да (Отчет за время с 3 по 4

съезд Советов, 1923, с. 265), 1925 елга гына нигездә төгәлләнә ала. Бу вакытка түбәндәге кодекслар татар теленә тәрҗемә ителеп бастырып чыгарыла: Җинаять кодексы, Җинаять-процессуаль, Гражданлык, Гражданлык-процессуаль, Җир кодекслары һәм ЗАГС буенча кодекс (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 94).

Икенче өлкә, ягъни суд процессын татарча алып бару буенча да эш башлана. 1923 елның октябренә Татарстанның барлык суд участоклары челтәрендә 14 махсус татар участогы булса, 1924 елның октябренә бу сан 19га (Отчет к 5-му съезду Советов, 1923, с. 29), ә 1925 елның мартына 21гә җитә һәм бу барлык суд участокларының 37%ын тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 92). Алга таба да татар суд участокларының санын 30га җиткерү буенча эш алып барыла (ф. 732, оп. 1, д. 262, л. 22). Моңа кадәр бөтенләй булмаган татар тикшерү участоклары да барлыкка килә башлый: 1924 елның октябренә беренче тапкыр 5 татар тикшерү участогы төзелә (15%), ә 1925 елның мартына бу сан хәтта 13кә җитә (36%) (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 92). Татар участокларындагы суд органнарында судьялар да, тикшерүчеләр дә татарлардан туплана. Кантоннарда һәм татар халкы күпчелекне тәшкил иткән волостьларда да татар участоклары барлыкка килеп, аларга татар судьялары җибәрү хакында проект төзелеп, бу эш тормышка да ашырыла (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 105). Тик аларның төгәл саннары һәм кайсы кантон һәм волостьларга җибәрелүе хакында тулы мәгълүматлар юк.

Юстиция комиссариаты аппаратының үзендә дә ТТГК эшләре яхшы гына аякка бастырыла: татар телендә язылган гаризалар кабул ителә, мөрәҗәгатьләргә татарча җавап бирелә, һәртөрле кәгазьләрнең формалары, халык массалары өчен игъланнар һәм башка язулар татарча һәм русча эшләнә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 105).

Комиссариатта эшләүче татар хезмәткәрләренең саны елдан-ел арта баруы барлык чыганакларда да раслана, ләкин аларда мәгълүматлар төрлелеге хөкем сөрә. Мәсәлән, бер чыганакта 1922 елда татар җаваплы хезмәткәрләре саны 11%ны, ә 1923 елда 36%ны тәшкил итә диеп күрсәтелсә (Отчет за время с 3 по 4 съезд, 1923, с. 265), икенче чыганакта 1924 елның 1 апреленә җаваплы хезмәткәрләр саны ни өчендер 26,6%ка гына кала (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 32), өченче чыганакта да 1924 елның 1 октябренә 27% диеп күрсәтелә (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 29). Барлык татар хезмәткәрләренең саны буенча да мәгълүматлар төрлечә бирелә. 1924 елның 1 октябренә бу сан 21,4%ны тәшкил итә (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 29), 1926 елның 1 гыйнварына ул 13,5%ка кала, ә 1929 елның 1 гыйнварына хәтта 50%ка җитә (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 25). 1936 елгы мәгълүматлар буенча, Юстиция комиссариаты һәм аның карамагындагы учреждениеләрдә татар хезмәткәрләре 45,7%ны тәшкил итә (барлыгы 212 хезмәткәр, шуларның 97се — татар). Җитәкче урыннарда эшләүчеләр арасында татарларның саны 50%ка, җаваплы хезмәткәрләр арасында — 49,4%ка, техник хезмәткәрләр арасында — 42,6%ка җитә (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 26). Күренгәнчә, дистә еллар дәвамында Юстиция комиссариатында эшләүче татар хезмәткәрләренең саны бик нык арта. Моңа Үзәк курслар карамагында махсус юридик цикл оештырылу да уңай йогынты ясый. Нәтиҗәдә бигрәк тә кантоннар техник хезмәткәрләр белән тәэмин ителә. Дөрес, курсларны бетерүчеләрнең юридик яктан йомшак әзерлекле һәм практик стажсыз булулары аларны җаваплы эшләргә куярга мөмкинлек бирми (Отчет за время, 1923, с. 265).

Юстиция комиссариаты аппаратының үзендә дә, Баш мәхкәмәдә (Главсуд) дә рус хезмәткәрләре өчен татар теле курслары эшли һәм

аларга йөрү җаваплы хезмәткәрләр өчен дә, техник хезмәткәрләр өчен дә мәҗбүри итеп куела (ф. 732, оп. 1, д. 262, л. 22).

Юстиция комиссариаты халык комиссары һәм ТР прокуроры үзе дә милләте буенча татар була — Баһаветдинов Гыймаз. Ул Үзәк комиссиянең киңәйтелгән утырышларында берничә тапкыр комиссариатта ТТГК эшләренең торышы хакында доклад ясый (ф. 732, оп. 1, д. 262, л. 22). Комиссариат карамагындагы өчле комиссия эшчәнлеге кайчагында тәнкыйть утына да эләгә (ф. 732, оп. 1, д. 771, л. 92). Аның кайчан оешуы да билгеле түгел, бары 1923 елда инде эшләгәнлеге мәгълүм (Отчет за время, 1923, с. 265). 1925 елда аның составына 3 татар кешесе керә: рәисе — Юстиция комиссариаты халык комиссары урынбасары Дивеев Усман, комиссия әгъзалары — Баш мәхкәмә коллегиясе әгъзалары Нәбиуллин Әхәт һәм Хәсәнов Борис (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 14). Аларның эшчәнлеге хакында тулырак мәгълүматлар юк.

Шулай итеп, Юстиция комиссариаты да ТТГК буенча шактый зур эшләр башкара: татар районнарында барлык хезмәткәрләре татарлардан гына торган суд һәм тикшерү участоклары ачыла, барлык кодекслар татар теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгарыла, татар хезмәткәрләренең саны бик нык арта.

2.6. Финанс халык комиссариатында ТТГК. Финанс комиссариатында татар теленең ни рәвешле гамәлгә куелышы хакындагы мәгълүматлар 1924 ел белән генә башлана. Бу елның 8 маенда Үзәк комиссия инструкторы К.Хәмзин комиссариат һәм аның карамагындагы оешмаларда ТТГК эшләренең барышын тикшереп, комиссиягә хисап бирә. Тикшерү нигездә 1922 елның 21 декабрендәге инструкция маддәләренең ничек тормышка ашырылуын күзәтүдән гыйбарәт була.

1924 елның 1 маена Наркомфин һәм аның идарәләрендәге эшчеләр составы түбәндәгечә билгеләнә: шәһәрдә — 477 рус, 47 татар, татарларның 5се — җаваплы хезмәткәр; кантоннарда — 766 рус, 100 татар, татарларның 16сы — җаваплы хезмәткәр (527, л. 62). Күренгәнчә, комиссариат карамагында эшләүче татар хезмәткәрләренең саны чагыштырмача күп булмый: Казанда — 9,8%, кантоннарда — 13,5%, барлык учреждениеләрне берләштереп санасак, 11,6% килеп чыга. Комиссариатта татар эшчеләрен алырга омтылыш сизелә. Мәсәлән, салым идарәсе 15 татар эшчесе сорап, Өлкә комитетына мөрәҗәгать итә, ләкин комитет фәкать 5 кеше генә җибәрә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 62). Хезмәткәрләрне кабул иткәндә, аларга артык зур таләпләр кую, эшли башлагач төшенүен игътибарга алмыйча, иң югары белгечлек таләп итү нәтиҗәсендә, татар эшчеләрен җәлеп итә алмыйлар (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 62).

Үзәк комиссия инструкторы комиссариатта татар телен гамәлгә кую эшләрен тикшерү, аның барышы хакында киң мәгълүмат алу өчен яраклы кеше таба алмыйча аптырап бетә, аның сүзләре буенча күпчелек оешмалардагы хәл күз алдына килеп баса: «...наркомнар яки коллегия әгъзалары «эш» белән күмелеп беткәнгә, әлбәттә, алар ТТГК эшенә юлбашчылык кыла алмыйлар. Башка бер эшчегә юлбашчылык тапшырылмаган. Наркомфинда нарком үзе, табигый, бу хакта бернәрсә дә белми, эшләр идарәсенә җибәрә, ул да бернәрсә белми, ниһаять, эшләр мөдире наркоматтагы татарча тел курслары мөдиренә җибәреп, кирәк мәгълүматның 40%ын аннан гына алырга мөмкин була. Болардан күренә ки, наркоматта мәсьәләгә тиешенчә әһәмият бирелми икән» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 62).

Шулай да комиссариатта хәлләр бөтенләй үк өметсез булмый, инструкциянең күп кенә маддәләре тормышка ашырыла яки моңа омтылыш булса да ясала. Мәсәлән, татарча мөрәҗәгатьләр, соңга

калыбрак булса да, эшкә ашырылмый калмыйлар. Соңга калуның сәбәбе итеп күп бүлекләрнең башларында татар телен белүче кеше булмауны, регистраторларның да татарча белмәүләрен санарга мөмкин. Нәтиҗәдә мөрәҗәгатьләрнең кайберләре я бөтенләй югала, я бик соң үтәлә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 62). Татарча кәгазьләргә татар телендә җавап бирү эше дә тормышка ашырылмый. Бу эш белән шөгыльләнүче махсус тәрҗемәчеләр дә булмый. Авыр хәлдән чыгу, ягъни татарча язуларның эчтәлеген аңлау өчен, комиссариатта эшләүче татар хезмәткәрләренең бушрак вакытын көтәргә туры килә. Шулай да ахыр чиктә «бер дә русча укый, яза, сөйли белми торган бер татар крәстиәне яки эшчесе Наркомфинга бер эш белән килеп керсә, авырлык белән булса да максудын үтмичә, эшен эшләмичә чыгып китми» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 63).

Комиссариатта шулай ук барлык мөһер, штамп һәм эленмә такталар ике телдә дә эшләнә, гомуми характерда булган бөтен игъланнар, хисаплар, карарлар, кулланмалар, плакатлар, бланклар — һәммәсе дә һәр ике телдә таратылалар (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 63). Хезмәткәрләрнең таныклыклары һәм мандатлар татар телендә дә язылырга тиешлеге хакында боерык бирелә һәм бу эш үтәлү юлында була (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 63).

Татар белгечләрен арттыру максатында, Финанс комиссариаты карамагында 1923 елның сентябрендә, татарлардан бухгалтер, хисапчылар әзерләү өчен, 50 кешелек курс ачыла һәм ул 1924 елның 5 апрелендә тәмамлана. Ләкин «курсның составы бик чуар булганлыктан», 50 кешегә дәвам иттерү мөмкин булмый, нәтиҗәдә даими курсант булып бары 18 кеше кала. Шуларның 12се диплом алып, төрле комиссариатларга җибәрелә, ә 6сы белемнәре буенча диплом бирерлек булмый, аларга курс тыңлау хакында таныклык кына бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 527, лл. 62-63).

Шул вакыттан алып, финанс курслары даими рәвештә бухгалтер һәм хисапчылар әзерләп чыгара. Үзәк комиссия карары буенча, әлеге курсларда укучыларның 75%ын татарлар яки татарча белә торганнар тәшкил итәргә тиеш булса да, гамәлдә бу эш тормышка ашырыла алмый. Чөнки, беренчедән, кантоннардан аз кеше җибәрелә, икенчедән, татар халкын әлеге курслар аз кызыксындыра һәм Финанс комиссариаты тарафыннан җитәрлек дәрәҗәдә популярлаштырылмый. Нәтиҗәдә 1925 елгы курсларда укучыларның 40%ын татарлар тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 104).

Комиссариатның үз курсларыннан тыш, ТТГК Үзәк курслары карамагындагы хисапчылар, салым хезмәткәрләре, бухгалтерлар әзерли торган циклларда да татар белгечләре әзерләнә. Мәсәлән, 1925 елда гына да 113 татар финанс хезмәткәре әзерләп чыгарыла (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 30).

Комиссариатта рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү курслары да эшли. 1923 елның августыннан бирле техник хезмәткәрләр курсларга даими рәвештә йөреп, аз булса да укый-яза белерлек дәрәҗәгә җитәләр. Ә җаваплы хезмәткәрләр исә, эшләре бик күп булып, вакытлары җитмәү сәбәпле, татарча өйрәнү белән шөгыльләнмиләр (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 63). Комиссариат тарафыннан татар теле курсларына һәрвакыт кредит бүлеп бирелә, укучылар дәреслекләр белән тәэмин ителәләр (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 104). Шулай да татар теле өйрәнү бик зур авырлык белән бара һәм 2-3 ел курсларга йөргәннәрнең дә эш нәтиҗәләре аз булуга басым ясала (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 104).

Комиссариат карамагындагы ТТГК өчле комиссиясе 1925 елның 19 августында оештырыла. Аның составына түбәндәге кешеләр кертелә: финанс халык комиссары урынбасары һәм салым

идарәсе башлыгы Бикбулатов Гомәр (рәис), Үзәк касса мөдире Кузьмичев Василий һәм Гомуми идарә башлыгы Богданов Миңнегәрәй (әгъзалар). Әгъзаларның берсе — В.Кузьмичев — милләте буенча рус һәм татар телен бөтенләй белми (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 4).

ТТГК Үзәк комиссиясе президиумының 1926 елның 21 январендә булган утырышында Финанс комиссариатының татар телен тормышка ашыру буенча эшчәнлеге йомшак дип табыла. Комиссариат администрациясе һәм өчле комиссиясе арасында ТТГК буенча килешеп эшләү күзәтелми, эш планнары юк, түбән аппаратларга ТТГКның кирәклеге хакында күрсәтмәләр бирелмәгән һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 105).

Аппаратка татар хезмәткәрләрен җәлеп итү буенча да 1924 ел белән чагыштырганда зур уңышларга ирешә алмаганлыклары күренә. Мәсәлән, 1925 елның 1 январенә штаттагы 400 хезмәткәрнең 43е — татар һәм бу 10,75%ны тәшкил итә, ягъни 1924 елгы күрсәткечләрдән дә азрак сан килеп чыга. 1926 елның 1 январенә аз булса да үсеш күзәтелә: барлыгы 436 хезмәткәрнең 55е татарлардан була һәм бу 12,62%ны тәшкил итә. Бер ел эчендә 22 татар хезмәткәре үз теләкләре буенча эштән китә, алар урынына 34 кеше алына (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 104).

Татарларны җәлеп итүгә тоткарлык ясаучы зур сәбәп итеп өчле комиссия әгъзасы Богданов бик түбән эш хакын күрсәтә (беренче разрядка — 7 сум 75 тиен). Шунлыктан квалификацияле татар хезмәткәрләре эштән китәләр, ә яңадан алынучылар исә я яхшы түләнә торган эш таба алмаган квалификацияле хезмәткәрләр, я бөтенләй квалификациясез эшчеләр була. Икенчеләре практикант булып яки иң түбән эшләрдән саналган регистратор, канторщик кебек хезмәтләргә алыналар һәм, күпмедер эшләп, тәҗрибә

туплаганнан соң гына югарырак урыннарга билгеләнәләр (ф. 732, оп. 1, д. 769, лл. 104-105).

Комиссариаттагы өчле комиссия татар яки татарча белүче хезмәткәрләрнең санын 25%ка җиткерү хакында гына план кабул итә, аннан да арттыра алуны шик астына ала (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 105). Ләкин 1929 елгы мәгълүматлар буенча, бу елның 1 январенә татар хезмәткәрләренең саны 34,7%ка җиткән. Шул ук вакытта, 1926 ел белән чагыштырганда, барлык хезмәткәрләрнең яртысы кыскартылу күренеше күзәтелә. Мәсәлән, 1926 елда 436 хезмәткәр булса, 1929 елда Финанс комиссариаты һәм аның карамагындагы оешмаларда 213 хезмәткәр эшли (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 26). Шуларның 74е татар булып, бу сан 34,7%ны тәшкил итү исәбенә генә татарлар күбрәк җәлеп ителгән дигән алдавыч фикер туарга мөмкин.

1936 елгы мәгълүматлар, мөгаен, комиссариат аппараты хакында гына булырга тиеш, чөнки бу вакытка барлык хезмәткәрләрнең саны 109 дип бирелә, шуларның 42се татар һәм бу 40%ны тәшкил итә дип күрсәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 26) (дөресрәге — 38,5%). Җитәкче урыннарны биләүчеләрнең 60%ын, җаваплы хезмәткәрләрнең 40%ын, техник хезмәткәрләрнең 30%ын татарлар алып тора дигән мәгълүматлар да 1936 елга карый (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 26). Татар хезмәткәрләренең саннарыннан кала, татар теленең ничек гамәлгә куелуы хакында бернинди мәгълүмат та юк.

Шулай итеп, Финанс комиссариаты һәм аның карамагындагы учреждениеләрдә татар хезмәткәрләренең санын арттыру буенча зур эш алып барыла, моның өчен хисапчылар, бухгалтерлар, салым хезмәткәрләре әзерләү курслары эшли, руслар өчен татар теле

түгәрәкләре үзләренең эшчәнлеген җәелдерә, аппаратта татар телендә пассив эш йөртү кертелә.

2.7. Татар статистика идарәсендә (ТСУ) ТТГК. ТСУның Татар халкы статистикасы бүлеге мөдире вазифасын күренекле галим Галимҗан Шәрәф башкара (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 8). Ул этнографик статистика буенча фәнни тикшеренүләр алып бара, башлыча Татарстан җөмһүриятендә яшәүче халыкларның этнографик составын өйрәнә, аны күрше республикалардагы мәгълүматлар белән чагыштыра. 1923 елда ук Татарстанның этнографик картасын төзи (Вәлиев, 1996, б. 27-28). ТТГК Үзәк комиссиясендә зур эшчәнлек күрсәтүе белән бергә, танылган галим ТСУдагы өчле комиссия әгъзасы булып та тора. Комиссиянең рәисе (ТСУ управляющие урынбасары Колесников Илья) һәм әгъзасы (Комслуж рәисе Курдесов Яков) вазифаларын татар телен бөтенләй белмәгән кешеләр башкаруын (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 8) исәпкә алсак, ТСУда ТТГК эшләре башлыча Г.Шәрәф өстендә булуы аңлашыладыр. Комиссия 1923 елның 23 октябрендә оештырыла һәм шул вакыттан алып үзенең эшчәнлеген җәелдерә (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 4).

ТСУның үз аппаратында татар хезмәткәрләренең саны бик аз була: 1925 елга ул 2-3%тан да артмый (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 31). Алар арасында җаваплы хезмәткәрләр — 1, техник хезмәткәрләр 2 генә була (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 177). 1926 елның сентябренә бу сан аз булса да арта — 6,42%ка җитә (барлыгы 109 хезмәткәр, шуларның 7се — татар) (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 11). Кантон статистика бүлекләрендә эшләүчеләр арасында да татарлар зур урынны алып тормый: 40 хезмәткәрнең 7се — татар (17,5%) (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 11). Бары түбән аппарат исәбенә генә ТСУдагы татар эшчеләренең саны күбрәк күренә. Татарлар арасыннан волость статистларын һәм үз теләкләре буенча эшләүче

авыл корреспондентларын җәлеп итү статистика өлкәсен татарлаштыруга зур ярдәм итә. Мәсәлән, 1926 елга волстатистларның саны 127 кеше булып, шуларның 41ен татарлар тәшкил итә (33,06%), үз теләге буенча эшләүче корреспондентларның исә 42,06%ын татарлар алып тора (барлыгы 1978 кеше, шуларның 832се — татар) (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 11).

Күренгәнчә, ТСУ түбән статистика аппаратына татарларны җәлеп итүгә зур әһәмият бирә. Бу юлда төп каршылыклар итеп, ТСУ управляющие Ермолаев сүзләре буенча, урыннарда статистиканың популяр булмавы, бу өлкә белән начар таныш булу һәм, күп эшләп тә, аз хезмәт хакы алуны санарга мөмкин (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 11). Кантон статистика бүлекләренең һәрберсенә берәр татар хезмәткәре алу турында боерык бирелә, ләкин кантоннарда әзерлекле татар статистлары булмау һәм кантон бүлекләренең акча белән начар тәэмин ителүе нәтиҗәсендә, бу фәрман өлешчә генә үтәлә: 1925 елга 8 кантонда берәр татар статисты булдырыла (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 5). ТСУ эшенә татар практикантларын җәлеп итү эше дә тулысынча тормышка ашырыла алмый, бары вакытлы эшләрдә генә практикантлардан файдаланалар (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 177). 1923 елда ТСУ тарафыннан даими эшләү өчен тәрҗемәче чакыртыла (Татреспублика в цифрах. — 1923. — №12. — С. 51). 1925 елда исә махсус тәрҗемәче штаты инде булмый, кирәк булган очракта, бу эш белән Татар халкы статистикасы бүлеге шөгыльләнә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 1).

Белемле статистлар әзерләү максатында, 1925 елның апрелендә ТСУ тарафыннан махсус 4 айлык өлкә статистика курслары оештырыла. Курсларга укучылар кабул иткәндә, татарларга өстенлек бирелә. Укырга теләк белдергән татарларның барысы да, ягъни 11 кеше, курсларга кабул ителә. Әлеге курсларда, Татарстаннан тыш,

Чувашия, Удмуртия һәм Мари республикаларыннан да килеп укыйлар (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 176). 1926 елгы курсларга исә бары 2 татар гына кабул ителә, алары да тәмамлый алмый, чөнки икесе дә 1 нче баскыч мәктәпне генә бетергән булалар, ә курсларда укыр өчен урта белемгә ия булырга кирәк була (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 11).

ТСУның үзеннән тыш, Үзәк курсларда да статистика циклы эшләп килә һәм аларны бетергән курсантлар төрле статистика бүлекләренә эшкә җибәрелә (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 11).

1923 елдан алып, ТСУдагы рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү курслары эшли. Аларда күбрәк техник хезмәткәрләр (статистлар, инструкторлар) шөгыльләнә. Хисапларда хезмәткәрләрнең шактый зур уңышларга ирешүе билгеләнеп үтелә. Мәсәлән, 1925 елда курсларда укучы кайбер хезмәткәрләр татар телендә журнал чыгаралар (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 177).

ТСУ тарафыннан нәшер ителә торган басмалар — җыентыклар, еллык журналлар, белешмә китаплар, сорау үткәрү өчен формулярлар, карточкалар, анкеталар һәм статистик тикшерү үткәрү өчен башка документлар — барысы да ике телдә чыгарыла (ф. 732, оп. 1, д. 776, л. 5). Статистика буенча формулярларның күбесе үзәктән әзер килеш рус телендә кабул ителгәнгә күрә, ТСУ Татарстан өчен бу формулярларның рус һәм татар телләрендә басылуын сорап, Үзәк статистика идарәсенә (ЦСУ) мөрәҗәгать итә, ләкин бу үтенеч үзәк тарафыннан җавапсыз кала. ТСУның үзендә дә, кантон бүлекләрендә дә татар телендәге телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр кабул ителә, аларга татар телендә җавап та бирелә (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 177). Мөһер, штамп, эленмә такталар, игъланнар һ.б. рус һәм татар телләрендә эшләнә. Татар

районнарына җибәрелүчеләргә мандатлар ике телдә дә бирелә. Барлык хезмәткәрләрнең дә таныклыклары ике телдә эшләнә (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 178).

Кыскасы, Татар статистика идарәсендә ТТГК инструкциясенең күпчелек маддәләре тормышка ашырыла, бу эшкә зур әһәмият бирелә. Татар хезмәткәрләре әзерләү курслары да, рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү түгәрәкләре дә уңышлы рәвештә эшләп килә. ТСУның үз аппаратына һәм кантоннарга татар хезмәткәрләрен күбрәк җәлеп итүгә квалификацияле татар статистларының булмавы һәм акча аз бирелү зур тоткарлык ясый.

2.8. Иҗтимагый тәэминат халык комиссариатында (НКСО) ТТГК. Иҗтимагый тәэминат комиссариатының ТТГК буенча эшчәнлеге һәрвакыт тискәре яктан гына искә алына. Комиссариат карамагындагы өчле комиссиянең кайчан төзелүе билгеле түгел, 1924 елда рәис булып бер авыз сүз татарча белмәгән рус кешесе эшләве, әгъзаларның берсе керәшен татары (Павлов), берсе татар (Гафиятуллин) булуы мәгълүм (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 66), ләкин аларның нинди эштә эшләве күрсәтелми. 1925 елгы мәгълүматлар буенча, комиссия рәисе итеп инструктор Ф.Мөхәммәтшин билгеләнгән, әгъзалар булып ике рус кешесе — Куликов Степан һәм Андреев Леонидлар эшли (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 14).

1924 елның 1 маена Иҗтимагый тәэминат комиссариаты һәм аңа караган 3 гарипләр йортындагы хезмәткәрләрнең саны: руслар — 95, татарлар — 14 кеше (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 66). Әгәр аларны аерым-аерым карасак, наркоматның үзендә җаваплы хезмәткәрләр: руслар — 10, татарлар — 2; техник хезмәткәрләр: руслар — 18, татарлар — 2; түбән эшчеләр: руслар — 6, татарлар — 4 (4се дә укый-яза белми). Гарипләр йортларында административ эшчеләр: руслар — 10, татарлар юк; түбән эшчеләр: руслар — 43, татарлар —

6 кеше. 6 татарның 3се — җыештыручы хатын-кыз, 3се — урам себерүче ирләр, 6сы да укый-яза белмиләр (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 66).

Шулай итеп, комиссариат һәм аның карамагындагы оешмаларда татар хезмәткәрләренең саны 14,7%ны тәшкил итә, 14 хезмәткәрнең 10сы — кара эшчеләр һәм бөтенләй наданнар.

Комиссариатта алдагы елларда бик нык кыскарту процессы барган булырга тиеш, чөнки 1926 елның 1 январенә комиссариат аппаратында эшләүчеләрнең гомуми саны 26га гына кала (1924 елда — 42), шуларның 5се — татар (19,2%), ә 1929 елның 1 январенә хезмәткәрләрнең саны, гомумән, 13 дип кенә күрсәтелә һәм шуларның 7се — татар (53,8%) (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 26). Шулай итеп, татар хезмәткәрләренең саны бу комиссариатта да гомуми штатны кыскарту исәбенә генә арта. 1936 елда да комиссариатның үзендә генә түгел, ә бөтен оешмаларны да кертеп, хезмәткәрләр саны 59дан артмый, шуларның 26сы — татар (44%) (ф. 732, оп. 1, д. 2809, л. 26).

Дәүләт учреждениеләрендә ТТГК буенча чыгарылган инструкциянең үтәлеше ягыннан карасак, Иҗтимагый тәэминат комиссариатында ул өлешчә генә тормышка ашырыла. Язма һәм телдән татарча мөрәҗәгатьләр кабул ителеп, вакытында үтәләләр, ләкин язма мөрәҗәгатьләргә җаваплар татарча бирелми. Гарипләр йортларындагы канцелярияләрдә дә ни язма, ни телдән татарча мөрәҗәгатьләр кабул ителми, чөнки аларда татарча белә торган эшчеләр булмый (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 66).

Мөһер, штамп һәм эленмә такталар ике телдә дә эшләнә. Таныклыкларның формалары һәр ике телдә басылган булса да, бирелгәндә русча гына язылып биреләләр. Плакат, эш бланклары, шулай ук гомуми урыннарга ябыштырыла торган игъланнар фәкать

русча гына язылa. Шулай да матбугат аркылы таратыла торган игъланнар ике телдә дә таратыла (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 66).

Эшкә алганда татарларга өстенлек бирелми, кыскартуга татар эшчеләре дә эләгә. Вазифалары түбән булганга, шулай ук татарча язу-сызу белүчелекне квалификациягә санамаганга, татар эшчеләре үз ихтыярлары белән дә эштән китkәлиләр (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 66).

Татар хезмәткәрләре хәзерләү өчен бернинди курс та ачылмый, бары 1924 елның гыйнвареннән башлап, рус эшчеләре өчен татар теле курслары эшләп килә. Ләкин курсларга йөрү бик начар, нәтиҗә дә бик зәгыйфь була. Комиссариат тарафыннан һичбер ярдәм күрсәтелми, хәтта китаплар, кулланмалар өчен смета төзеп, 10 сум акча сорап, шуны да ала алмыйлар (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 66).

Югарыда язылганнардан күренгәнчә, Иҗтимагый тәэминат комиссариатында ТТГК эшләре бик начар куела, комиссариат бу эшкә әһәмият бирми, күп хезмәткәрләр ТТГК инструкциясенең бар икәнен дә белмиләр.

2.9. <u>Коммуналь хуҗалык идарәсендә (УКХ) ТТГК</u>. Коммуналь хуҗалык идарәсендә ТТГК эшләре белән шөгыльләнүче өчле комиссия 1924 елның 19 ноябрендә оештырыла. Аның составына 3 татар хезмәткәре кертелә: рәисе — УКХ башлыгы урынбасары Беганский Измаил (польша татары), әгъзалар — Административ-финанс бүлеге мөдире Максудов Шакир һәм УКХ союзы сәркатибе Зәетов Исмәгыйль (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 15). Комиссиянең бурычы итеп УКХ һәм аның карамагындагы 34 учреждениедә ТТГК мәсьәләләрен хәл итү куела. Моннан тыш, кантоннардагы УКХга караган предприятиеләр дә аның карамагында була. Шулай да бу комиссия беренче чиратта халкының 25%тан артыгын татар халкы тәшкил иткән Казан шәһәрендәге коммуналь хуҗалык

учреждениеләрендә (торак йортлар идарәләре, транспорт конторалары, базарлар, кунакханәләр, төзү конторалары, пожар командалары һ.б.) ТТГК мәсьәләләре белән шөгыльләнә.

1924 елның маендагы тикшерү вакытында инструктор Хәмзин Коммуналь хуҗалык идарәсенең ТТГК буенча эшчәнлеген тискәре яктан бәяли: «Татар районнары, бүтән идарәләрдән килгән татарча доклад, отчет шикелле нәрсәләрне ачыктан-ачык кабул итмиләр. Инструкциянең икенче маддәсеннән үтмәгәннәр. Татар эшчеләре ифрат аз (барысы — 1862, татарлар: җаваплы хезмәткәрләр — 10, техник — 7, кара эшчеләр — 116). 1924 елның әүвәлендәге яртысында кыскартылу булып узган, аз гына татар эшчеләре тагын да азайтылганнар. 1924 елда курслар ачылган булса да, берәү дә йөрмәгәнлектән, киредән япканнар» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 108). Күренгәнчә, 1924 елның маена татар хезмәткәрләренең саны 7,14%ны тәшкил итә, анысы да кара эшчеләр исәбенә генә тула.

Үзәк комиссиянең 1924 елның 20 августында булган утырышында УКХ доклады тыңлана һәм 1925 елның башына татар хезмәткәрләренең санын 25%ка җиткерү бурычы куела (ф. 732, оп. 1, д. 521, л. 12). Ләкин бу бурыч үтәлми: хәтта 1925 елның октябренә дә УКХның барлык хезмәткәрләре арасында татарлар 11,6%ны гына тәшкил итәләр (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 37).

Идарәдәге барлык эш башкару рус телендә генә алып барыла. Татар телендә кергән кәгазьләр булган татар хезмәткәрләре тарафыннан тәрҗемә ителәләр. Штамп, эленмә такталар һәм пичәтләр ике телдә дә булдырыла. Бүлмәләрне күрсәтә торган такталар һәр җирдә дә ике телдә булмый.

УКХ әдәбиятны татар теленә тәрҗемә итү белән шөгыльләнми: барлык боерык һәм карарлар рус телендә генә чыгарыла. Шулай да коллектив договорлар ике телдә дә төзелә, йорт мәсьәләсе һәм башка

проблемалар буенча игъланнар бер үк вакытта «Красная Татария» һәм «Татарстан» газеталарына җибәрелә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 37 об.).

Шулай итеп, Коммуналь хуҗалык идарәсе дә татар теле начар гамәлгә куелган оешмалардан санала ала: татар хезмәткәрләре аз санны тәшкил итә, булганнары да кара эшчеләр исәбенә тутырыла, төп эш башкару рус телендә алып барыла, татар теле курслары оештырылып та, бернинди нәтиҗә бирми.

2.10. Кооператив оешмаларда ТТГК. 1924 елга кадәр кооператив оешмалар ТТГК эшеннән читтә калып киләләр, чөнки төп игътибар дәүләт учреждениеләренә юнәлтелә. Бары 1924 елның 30 апрелендә генә ТТГК инструкциясен кооператив оешмаларның да кулланырга тиешлеге хакында карар чыгарыла (Сб., 1925, с. 18). Шул ук елда Татарстанның кооператив учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә ТТГКга багышланган махсус инструкция дә дөнья күрә. Аның гомуми нигезләре буенча, барлык өлкә, кантон һәм район кооператив оешмаларында штамп, пичәт, эленмә такталар, мандат һәм таныклыклар, карар, инструкция, игълан, плакат, аншлаглар һ.б. ике телдә дә булырга, татар телендәге язма һәм телдән мөрәҗәгатьләр кабул ителергә, җыелыш, съезд һәм конференцияләр рус һәм татар телләрендә алып барылырга тиеш була (Сб., 1925, с. 20-21), ягъни дәүләт оешмалары өчен 1922 елда чыгарылган инструкциянең төп нигезләре кабатлана. Моннан тыш, әгъзаларының күпчелеген татарлар тәшкил иткән беренчел кооперативларда эчке эш алып бару, икенче төрле әйткәндә, барлык китаплар, беркетмәләр, исемлекләр, ведомостьлар, исәп-хисап эшләре, башка оешмалар белән язышу татар телендә алып барылырга тиеш була (Сб., 1925, с. 21). Ә күпчелеген татар булмаганнар тәшкил иткән беренчел кооперативларда исә барлык эш

башкару рус телендә калдырыла (Сб., 1925, с. 22). Дәүләт оешмаларындагы кебек үк, кооператив учреждениеләргә дә эшкә алганда татарларга өстенлек бирү; кирәкле күләмдә җаваплы һәм техник татар хезмәткәрләрен булдыру; хезмәткәрләрне татар теленә өйрәтү курслары ачу; квалификацияле татар белгечләре әзерләү өчен, түләүле практикантлар институты булдыру; кооперация буенча уставлар, хисап кенәгәләре, беренчел татар кооперативлары өчен бланклар эшләү, татар телендә популяр характердагы брошюралар һәм кулланмалар чыгару бурычлары куела (Сб., 1925, с. 22-23).

Чыннан да, шушы инструкция чыгу белән, 1924 елдан ук, беренчел татар кооперативларында актив эш башкару татар телендә алып барыла башлый; уставлар һәм кайбер кулланмалар татар телендә чыгарыла; Үзәк курслар карамагында кооператив органнардан саналган Татсоюз һәм Селькредпромсоюз булышлыгы белән махсус кооператорлар циклы эшли башлый; кооперация өлкәсенә татар хезмәткәрләрен җәлеп итү арта бара (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 32).

Кулланучылар кооперациясенең ТТГК буенча эшчәнлеге аеруча уңай яктан бәяләнә. Бу вакытта кулланучылар җәмгыятьләрен Татсоюз дип аталган оешма берләштерә. Татсоюзга кергән 42002 әгъзаның 22230ын, ягъни 52,9%ны татарлар тәшкил итә (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 32). Татарлар саны буенча хәлләр ярыйсы булса да, Татсоюзда ТТГК хакында махсус чыгарылган инструкция нигезендә, Татарстан республикасыннан читтәге оешмалар белән дә эш алып баруын, квалификацияле татар хезмәткәрләренең җитешмәвен исәпкә алып, татар телен Татсоюзның барлык органнарында да тулы күләмдә һәм тиз арада тормышка ашырырга мөмкин дип табылмый. Бары татар халкы

күпчелекне тәшкил иткән беренчел кооперативларда гына татар теле тулы күләмдә гамәлгә кертелергә, ә үзәк идарә һәм кантон бүлекләрендә исә өлешчә үтәлергә тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 70).

Татсоюз аппаратында ТТГК өчле комиссиясе 1924 елның 19 декабрендә төзелә һәм аны Татсоюз идарәсе рәисе Тихомиров җитәкли. Ләкин 1925 елның апрелендә комиссия составы тулысынча үзгәрә һәм аңа Татсоюз идарәсенең өч әгъзасы кертелә: рәисе — Г.Стекольщиков, әгъзалары — Булгаков Гомәр һәм Н.Камалетдинов. Алар өчесе дә татар милләтеннән дип бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 38).

Татсоюз идарәсе Казан шәһәрендә 378 хезмәткәре булган 26 җәмгыятьне, ә кантоннарда 298 җәмгыятьне берләштерә һәм өчле комиссия шуларда ТТГК мәсьәләләре белән шөгыльләнә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 38).

Татсоюзның үзәк конторасында эш башкару рус телендә алып барыла, ләкин татар телендәге мөрәҗәгатьләргә Оештыру бүлеге тарафыннан татарча җавап бирелә.

Татсоюзда татар телендәге әдәбиятны, шулай ук әһәмиятлерәк циркулярларны татар теленә тәрҗемә итү эше белән шөгыльләнүче махсус тәрҗемәче эшли. Аның тарафыннан түбәндәге әдәбият тәрҗемә ителә: 1) кулланучылар җәмгыяте уставы; 2) хисапчылык буенча инструкцияләр, бланклар, формалар һәм хисап кенәгәләре; 3) Островскийның «Крестьян хатын-кызларга кооперация ни өчен кирәк?» исемле брошюрасы; 4) Бакеевның «Кооперация орлыклары» китапчыгы; 5) Тихомировның «Кооперация эшен ничек яхшыртырга?» брошюрасы; 6) кулланучылар җәмгыятендә эш башкару буенча кулланма һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 39).

Аппаратка ике татар практиканты һәм бер өйрәнчек эшкә алына. Татсоюзда эшләүче татар хезмәткәрләрен саклау һәм аларның санын арттыру максатында, өчле комиссия хезмәткәрләрне эшкә алганда яки кыскартканда татарларга яки татар телен белүче башка милләт кешеләренә өстенлек бирү хакында карар кабул итә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 40).

Татсоюз башка милләттән булган хезмәткәрләрне татар теленә өйрәтү эшенә дә әһәмият бирә. Бу эш өчен үзәк аппаратка ай саен 95 сум күләмендә акча бүлеп бирелә. Мәсәлән, 1924 елда 14 хезмәткәр 5 ай дәвамында курста укып, 1925 елга аларның дүртесе «яхшы» билгесе ала, калган унысының татар теле буенча белемнәре «канәгатьләнерлек» дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 40 об.).

Татсоюзның кантоннардагы контораларында да төп эш башкару рус телендә алып барыла, ләкин татарлар өчен пассив эш алып бару кертелә. Өчле комиссия карары буенча, контораларның мөдирләре яки урынбасарлары итеп татар хезмәткәрләрен билгеләү күздә тотыла, 1925 ел ахырына бу эш 40%ка үтәлә. Балык Бистәсе, Кукмара һәм Арча контораларында татарлаштыру эше начар алып барыла (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 41).

Кооперациянең башка өлкәсе — авыл хуҗалыгы, кредит һәм промысел кооперациясе — органын тәшкил иткән Селькредпромсоюз да татарларны үз эшенә җәлеп итүгә зур әһәмият бирә. Мәсәлән, 1924 елның 1 октябренә бу өлкә буенча кооператорлаштырылган 30 мең кешенең 44,8%ын татарлар тәшкил итә. Селькредпромсоюзның үз аппаратында да татар хезмәткәрләренең саны эзлекле рәвештә арта бара. Мәсәлән, 1924-1925 елларда ул 6,5%тан 14%ка җитә. Кантоннарда да аппаратны татарлаштыру буенча киң эш җәелә (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 33).

Селькредпромсоюз учреждениеләрендә ТТГК буенча инструкция идарәнең 1924 елның 14 февралендәге карары нигезендә кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 53). 10 маддәдән торган әлеге инструкция нигездә кооператив оешмаларда ТТГК буенча чыгарылган инструкциянең гомуми пунктларын кабатлый, ә беренчел кооперативлар турында ни өчендер бер сүз дә әйтелми.

Шулай итеп, кооператив оешмалар да ТТГК эшенә тартылалар һәм бу хәрәкәт 1924 елда башланып китә. Бу елдан алып, кооперациядә ТТГК буенча түбәндәге эшләр башкарыла: беренчел татар кооперативларында бөтен эш татар телендә алып барыла башлый, ә үзәк аппарат һәм кантон бүлекләрендә исә татар теле пассив формада гына кулланылышта була; Татсоюз һәм Селькредпромсоюз үз аппаратларында ТТГК буенча инструкцияләр чыгаралар, татар хезмәткәрләренең санын арттыралар, Үзәк курслардагы кооператорлар циклын финанслыйлар; кооперациягә багышланган әдәбият, уставлар, кулланмалар рус теленнән татарчага тәрҗемә ителә, бланклар, формалар татар телендә дә эшләнә һ.б.

2.11. <u>Кредит органнарында ТТГК</u>. 20-30 нчы елларда Казанда 5 банк эшли: Дәүләт банкы, Авыл хуҗалыгы банкы, Промбанк, Всекобанк һәм Татбанк (ф. 732, оп. 1, д. 659, л. 154). Аларда ТТГК буенча азмы-күпме эшчәнлек алып барыла, барысында да диярлек өчле комиссияләр төзелә, ләкин Үзәк комиссиянең кредит органнарына аз әһәмият бирүе аларның үзләре тарафыннан ук ассызыклана. Банкларда татар теле тулысынча гамәлгә куелырга тиешме, әллә татарлаштыру, ягъни татар хезмәткәрләрен күбәйтү юлына гына игътибар итәргәме? — бу сорау Казан шәһәренең кредит учреждениеләрендәге ТТГК өчле комиссияләренең 1926 елның 28 маенда булган берләштерелгән утырышында еш кабатлана. Утырышны алып баручы, Дәүләт банкы өчле комиссиясе рәисе

Х.Тарпищев банкларда татар телен гамәлгә кертү үткәрелергә тиешлегенә басым ясый, моның өчен беренче чиратта татарларга татар телен сеңдерергә, телгә гадәтләндерергә, шул юл аркылы татар хезмәткәрләрен эшнең куелышы белән яхшылап таныштырырга тәкъдим итә (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100). Татбанк өчле комиссиясе вәкиле И.Мозаффаров исә «беренче чиратта — аппаратны татарлаштыру, аннары — ТТГК, һәм өченчедән, татарларны татар телен куллануга китерү» дип аталган өч нигез белән чыга. «Кәгазьләрне татар телендә язуга скептик рәвештә караучы, татарча язылганнарны «сукно астына» тыгып куярга мөмкиннәр, нәтиҗәдә алар җавапсыз калачак» дип санаучы татарларның булуын кызгану хисе белән билгеләп үтә (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100).

Утырышта катнашучы Үзәк комиссия сәркатибе К.Вәлиев Дәүләт банкының татар телен начар гамәлгә куюын тәнкыйтьли (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100). Чыннан да, 1925 елгы мәгълүматлар буенча, Дәүләт банкы аппаратының 3%ын гына татарлар тәшкил итә (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 33). 1926 елның маена исә бу сан 7,6%ка җитә: барлык хезмәткәрләр — 171; татарлар — 13, шуларның берсе — җаваплы хезмәткәр, берсе — канцелярия хезмәткәре, дүртесе — хисапчы, берсе — кассир һәм алтысы — түбән техник персонал (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100). Ләкин аз татарлаштырылуның сәбәпләрен дә аңларга мөмкин, чөнки банк конторасы СССРның бөтен территориясендәге клиентлар белән эш итә. Үзәкләштерелгән учреждение буларак, аңа барлык язу эшләрен русча яки чит телләрдә алып барырга туры килә. Банктагы өчле комиссиянең Үзәк комиссиягә хисабыннан күренгәнчә, татар телен тормышка үткәрергә берничә авырлык тоткарлык ясый: 1) средстволар булмау; 2) квалификацияле һәм тәҗрибәле, банк техникасының нигезләрен булса да белгән хезмәткәрләрне алырга

кирәк булу; 3) хезмәткәрләрнең татар телен өйрәнүдә инертлык күрсәтүләре; 4) штат тарлыгы сәбәпле, практикантлар тоту мөмкинлеге булмау (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 158). Алдагы максатлар итеп банкта эшләүче татарларның квалификацияләрен күтәрү, эшкә алганда бер үк квалификациягә ия татар һәм рус кандидатлары арасыннан татарларга өстенлек бирү һәм рус хезмәткәрләренең татар телен өйрәнүләрен агитацияләү куела (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 158). Әлеге максатларга ирешүнең гамәли адымы буларак, татар хезмәткәрләре контора хисабына конторгуч мәктәбендә белем алалар. Татарларны эшкә алу мәсьәләсе исә берьюлы берничә каршылыкка очрый: беренчедән, банкта буш урыннар булмый, икенчедән, банк идарәсе 1926-1927 елларда Мәскәүдән вузлар бетергән 5 кешене җибәрергә уйлый (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 158), өченчедән, билгеле инде, югары финанс белемле татар хезмәткәрләрен табуы бик кыен була.

Дәүләт банкының ТТГКдагы уңай хәрәкәте итеп шуны күрсәтергә мөмкин: ул Татарстан территориясендә татар телендәге эш кәгазьләре һәм документларның кулланылуын тәэмин итә (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100). Казандагы Бурыч алышу ширкәте (Общество взаимного кредита) өчле комиссиясе хәбәр итүенчә, 1925 елның 5 мартында Дәүләт банкы конторасы Татарстанда кулланылырга тиешле татар телендә язылган вексельләрне русчага тәрҗемә итмичә дә кабул итәчәген белдерә (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 58).

Бурыч алышу ширкәтенең татарча вексельләр чыгару эшен Үзәк комиссия шатланып каршы ала һәм бу турыда вакытлы матбугат битләрендә игълан итүне кирәкле дип саный (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 58). Ширкәттәге хезмәткәрләрнең (40) 40%ын татарлар алып тора

(16), нәтиҗәдә татар телендәге документ һәм корреспонденцияләрне кабул итүнең тулы мөмкинлеге була (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100).

Татбанк иң яхшы татарлаштырылган банклардан санала ала: 1925 елда татар хезмәткәрләре 52%ны (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 33), ә 1926 елда исә хәтта 68%ны тәшкил итә (66 хезмәткәр, татарлар — 45). Өчле комиссия урынына, банкта ике кеше ТТГК эшләре белән шөгыльләнә. Комиссия әгъзасы Мозаффаров күрсәтүе буенча, рус хезмәткәрләре генә татар телен теләмичә өйрәнәләр (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100).

Авыл хуҗалыгы банкында татарларның саны 1925 елга 20%ны (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 33), 1926 елга 24,6%ны тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100). Эш башкару, рус теле белән беррәттән, татар телендә дә алып барыла. Облигацияләрнең бер төрен — обязательстволарны — татар телендә кабул итү тәртибе кертелә. Татар телендәге кооператив әдәбиятны таратуга зур игътибар бирелә. Өч машинканың берсен татарча шрифтка көйләү, эшләп килүче ике татар практиканты өстенә тагын икене алу, үзәк аппаратны 50%ка татарлардан төзү һ.б. эшләр проектлана (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 100).

Промбанктагы хезмәткәрләрнең 14%ын татарлар алып тору, Всекобанкта исә татар хезмәткәрләренең бөтенләй булмавы (Отчет к 5-му съезду Советов, 1925, с. 33), ике банкта да ТТГК өчле комиссияләре эшләве һәм аларның составы хакында гына мәгълүматлар бар, ә татар теленең ни рәвешле гамәлгә куелуы тулырак итеп яктыртылмый.

Шулай итеп, банклар да ТТГК эшеннән читтә калмый. Бу өлкәдә бигрәк тә Татбанк һәм Авыл хуҗалыгы банклары алгы урында тора, аларда эш башкару ике телдә дә алып барыла. Дәүләт банкында эш башкару рус телендә генә алып барылса да, Татарстан

территориясендә кулланылышта йөрүче татар телендәге акча документларын кабул итү кертелә, татар хезмәткәрләрен арттыру буенча аз булса да хәрәкәт сизелә. Промбанкта ТТГК буенча мәгълүматлар юк, ә Всекобанк исә бөтенләй татарлаштырылмый.

2.12. Нәтиҗәләр.

1) Халык комиссариатларында һәм үзәк учреждениеләрдә татар телен гамәлгә кертүгә баштан ук зур игътибар юнәлдерелә: 1921 елгы Декретның беренче маддәсе үк әлеге мәсьәләгә багышлана.

2) Комиссариатларда һәм дәүләт оешмаларында ТТГК хакында чыгарылган күп санлы карарларның нигезен түбәндәгеләр тәшкил итә:

а) барлык учреждениеләрдә дә татар телендәге телдән һәм язмача мөрәҗәгатьләрне кабул итү һәм аларга татарча җавап бирү мәҗбүри итеп куела;

ә) барлык җыелыш, утырыш, съезд һәм конференцияләрнең рәсми теле итеп бертигез хокукта рус һәм татар телләре санала;

б) хезмәткәрләрне эшкә алганда, башка тигез шартларда, ике дәүләт телен дә белгәннәргә өстенлек бирелә;

в) һәрвакыт татар халкы белән аралашырга туры килгән хезмәт урыннарына ике телне дә белүче хезмәткәрләр билгеләнә;

г) барлык оешмаларның да боерыклары, инструкцияләр, карарлар, гаризалар, плакатлар һ.б. бер үк вакытта рус һәм татар телләрендә игълан ителергә тиеш дип табыла;

д) татар телендәге эш кәгазьләре һәм документлар (таныклык, мандат, ышаныч язуы, расписка, килешү, беркетмә, акча документлары һ.б.) ТАССР чикләрендә рус телендәге шундый ук документлар белән бер үк хокукка ия булалар;

е) барлык учреждение һәм предприятиеләрнең мөһер, штамп һәм эленмә такталары татар һәм рус телләрендә булдырыла;

ж) дәүләт оешмалары түбәнге органнардан татар телендә килә торган хисап, ведомость һ.б. материалларны рус теленә тәрҗемә итеп җибәрүне таләп итмәскә тиеш булалар һ.б.

3) Барлык комиссариат һәм учреждениеләрдә дә диярлек ТТГК өчле комиссияләре төзелә. Комиссия рәисе итеп оешма җитәкчесе яки аның урынбасары билгеләнә. Өчле комиссияләр ТТГК ҮК җитәкчелегендә эшлиләр һәм әледән-әле аңа хисап биреп торырга тиеш булалар. Ләкин комиссияләрнең күпчелеге үз эшләрен җиренә җиткереп үтәмиләр һәм ҮК тарафыннан каты тәнкыйть утына эләгәләр.

4) Тикшерү объекты итеп алынган комиссариат һәм оешмалар арасында Сәламәтлек саклау, Эчке эшләр, Юстиция халык комиссариатлары, Татар статистика идарәсе, кайбер кооператив оешмалар һәм кредит органнарында ТТГК эше чагыштырмача яхшырак җайга салына. Элемтә идарәсе, Финанс, Иҗтимагый тәэминат комиссариатлары, Коммуналь хуҗалык идарәсенең ТТГК буенча эшчәнлекләре канәгатьләнерлек булмый.

5) Сәламәтлек саклау халык комиссариатында бу эш бигрәк тә 1924 елдан соң көчәеп китә. Махсус медицина белеменә ия татарларның аз булуы гаять зур авырлык тудыру сәбәпле, комиссариатта күп еллар дәвамында татарларны күбрәк җәлеп итү юнәлешендә эш алып барыла, бу максат белән медицина уку йортларына татарларны кабул итү арта, татарлар өчен әзерлек группалары булдырыла, санитарлар, акушерлар, «Әниләр һәм балаларны саклау» курслары оештырыла. Моннан тыш, татар табиплары тарафыннан татар телендәге дәреслекләр языла, татарча медицина терминнары эшләнә, брошюралар әзерләнә.

6) Эчке эшләр халык комиссариатында татар хезмәткәрләрен җәлеп итүгә зур әһәмият бирелә, бу максат белән махсус курслар оештырыла. Бигрәк тә комиссариатның милиция һәм ЗАГС бүлекләрендә татар телендә хезмәт күрсәтүгә зур урын бирелә.

7) Юстиция комиссариаты кул астында барлык кодекслар татар теленә тәрҗемә ителеп бастырып чыгарыла, татар районнарында барлык хезмәткәрләре татарлардан гына торган суд һәм тикшерү участоклары ачыла, татар хезмәткәрләренең саны бик нык арта.

8) Финанс халык комиссариаты нигездә татар хезмәткәрләренең санын арттыру буенча эш алып бара, моның өчен хисапчылар, бухгалтерлар, салым хезмәткәрләре әзерләү курслары эшләп килә.

9) Татар статистика идарәсендә ТТГК инструкциясенең күпчелек маддәләре тормышка ашырыла. Татар хезмәткәрләрен күбрәк җәлеп итүгә квалификацияле татар статистларының булмавы һәм хезмәт хакы аз түләнү зур тоткарлык ясый.

10) Иҗтимагый тәэминат халык комиссариаты һәм Коммуналь хуҗалык идарәсендә татар теле бик начар гамәлгә кертелә: төп эш башкару рус телендә генә алып барыла, татар хезмәткәрләре бик аз санны тәшкил итә, оешма җитәкчеләре ТТГКга бернинди әһәмият бирмиләр.

11) Кооператив оешмаларда ТТГК 1924 елдан башланып китә. Беренчел татар кооперативларында бөтен эш татар телендә алып барыла, ә үзәк аппарат һәм кантон бүлекләрендә исә татар теле пассив формада гына кулланыла. Кооперациягә кагылышлы әдәбият, уставлар, кулланмалар татар теленә тәрҗемә ителә, формалар татар телендә дә эшләнә.

12) Кредит органнары да ТТГК эшеннән читтә калмый. Казандагы 5 банк арасыннан бигрәк тә Татбанк һәм Авыл хуҗалыгы банклары алгы урында торалар, аларда эш башкару ике телдә дә алып барыла.

13) Халык комиссариатлары һәм оешмаларда ТТГКга киртә тудыручы сәбәпләр башка тармаклардагы кебек үк: акча юклык, белемле татар хезмәткәрләренең җитешмәве, учреждение җитәкчеләренең әлеге эшкә салкын каравы, оешмалар карамагында махсус төзелгән өчле комиссияләрнең ТТГК эше белән тиешле дәрәҗәдә җитәкчелек итә алмаулары һ.б.

## 3 бүлек. Мәгариф өлкәсендә татар телен гамәлгә кую.

1920 елга кадәр Татарстан территориясендәге халык мәгарифе эшләре белән Казан губернасы мәгариф бүлеге (Губоно) җитәкчелек итә, 1920 елның сентябрендә бу оешма Татарстан Мәгариф халык комиссариатына үзгәртелә. 1930 елга кадәр ул, халык мәгарифе мәсьәләләре белән бергә, профессиональ-техник белем, фәнни-тикшеренү һәм туган якны өйрәнү эшләре белән дә җитәкчелек итә, җирле нәшриятларның эшчәнлегенә юнәлеш бирә, 1945 елга кадәр сәяси-агарту эшен дә (наданлыкны бетерү, кинотеатрлар, клублар, китапханәләр) үз кул астында тота (Центральный гос. архив ТАССР, 1967, с. 176).

Мәгариф комиссариаты татар телен гамәлгә куюдагы урыны буенча башка комиссариат һәм оешмалардан бик нык аерылып тора, чөнки аның эшчәнлеге татар телен киң кулланылышка кертүгә турыдан-туры йогынты ясый, ул бу эшләрне гамәли яктан тормышка ашыручы ролен үти: башлангыч, урта һәм югары уку йортларына татарларны күбрәк җәлеп итеп, республиканы төрле белгечлекләр буенча квалификацияле татар хезмәткәрләре белән тәэмин итү; төрле уку йортларында һәм курсларда русларны татар теленә өйрәтеп, ике дәүләт телен дә белгәннәрнең санын арттыру; уку йортлары өчен гаять кирәкле татар теле дәреслекләре, уку планнары һәм программалары әзерләү; татар халкы тарихын, телен, мәдәниятен һ.б. өйрәнү — боларның барысы да Мәгариф комиссариаты кул астында эшләнә.

Комиссариат үзе 8 бүлек, идарә һәм үзәккә бүленгән була: 1) Социаль тәрбия бирү баш идарәсе (Главсоцвос); 2) Профессиональ белем бирү баш идарәсе (Главпрофобр); 3) сәяси-агарту эшчәнлеге

белән идарә итүче Главполитпросвет; 4) Гыйльми үзәк (Академцентр); 5) нәшрият эшләре белән җитәкчелек итүче Главлит; 6) милли азчылык мәгарифе эшләре белән шөгыльләнүче Совнацмен; 7) оештыру-инструкторлык бүлеге; һәм 8) финанс-хуҗалык бүлеге (За 5 лет, 1925, с. 102). Гомумән алганда, Татарстанда 20-30 нчы еллардагы мәгариф системасы бөтен РСФСР системасы белән тәңгәл килә, аның төзелеш нигезләрен түбәндәге принциплар тәшкил итә: база хезмәтен бердәм хезмәт мәктәбе үти, аңа профессиональ белем өстәлә, иң соңыннан боларга мәктәптән тыш белем, сәяси-агарту эшләре килеп тоташа (За 5 лет, 1925, с. 102). Мәгариф комиссариатындагы 8 бүлекнең бары өчесе: Главсоцвос, Главпрофобр һәм Гыйльми үзәк кенә безнең өчен әһәмиятле булып тора, шунлыктан аларга аерым-аерым тукталабыз.

3.1. <u>Социаль тәрбия бирү баш идарәсендә ТТГК</u>. Главсоцвос мәктәпләр эшчәнлеге белән идарә итә. Бу елларда мәктәпләр иң элек ике төргә бүленә: 1 нче баскыч һәм 2 нче баскыч мәктәпләр. 1 нче баскыч мәктәпләрдә уку вакыты 4 елга сузыла (Отчет 6-го созыва, 1927, с. 88), шул ук вакытта Татарстан өчен өч еллык мәктәпләрнең күпчелекне тәшкил итүе хас була (ф. 3682, оп. 1, д. 997, л. 770). Моннан тыш, мәсәлән, 1925 елда татар авылларындагы барлык 1 нче баскыч мәктәпләрнең яртысын бер комплектлы, ягъни бер генә еллык мәктәпләр алып торуы мәгълүм (За 5 лет, 1925, с. 105). 1 нче баскыч мәктәпләр сан ягыннан күтәренке тип мәктәпләрне тәшкил иткән һәм чагыштырмача яңа күренеш булган 2 нче баскыч мәктәпләргә караганда бик күпкә артыграк була. 2 нче баскыч мәктәпләр үзләре ике төргә аерыла: 7 еллык, ягъни 1 нче баскыч мәктәптән соң 3 ел уку күләме белән, һәм 9 еллык, ягъни 5 ел уку вакыты белән (Отчет 6-го созыва, 1927, с. 88). 2 нче баскыч мәктәпләр арасында 7 еллыклары күбрәк урынны алып тора, бу төр

мәктәпләр бигрәк тә кантоннарда күп төзелә, ә 9 еллык мәктәпләр исә шәһәрләр һәм аеруча Казан өчен хас була (За 5 лет, 1925, с. 105). 2 нче баскыч мәктәпләрнең төп максаты итеп укучыларны техникумнарга яки югары уку йортларына әзерләү куела. Ләкин 1924/25 уку елында 2 нче баскыч мәктәпләрне бетергәннәрнең язмышына күз салсак, 800 укучының бары 20се генә вузларга һәм 176сы техникумнарга укырга керә ала, ә калганнары бернинди гамәли әзерлексез кала. Нәтиҗәдә 2 нче баскыч мәктәпләрнең соңгы ике елына (8-9 сыйныфларга) профессиональ юнәлеш бирергә карар ителә (ф. 3682, оп. 1, д. 1148, лл. 14-15). Мәгариф комиссариаты бу бурычны 1925/26 уку елында хәл итәргә тиеш була (Отчет к 5-му съезду, 1925, с. 97). Чыннан да, Мәгариф комиссариатының хисапларыннан күренгәнчә, 1925/26 уку елында күпчелек 9 еллык мәктәпләр төрле уклон буенча: педагогик, кооператив, сәяси-агарту (ф. 3682, оп. 1, д. 997, л. 778), шулай ук почта-телеграф, муниципаль юнәлешләрдә эшли башлыйлар (Отчет 6-го созыва, 1927, с. 89).

Дәүләт челтәреннән тыш, Татарстанда ата-аналар һәм крестьян җәмгыятьләре акчасына эшли торган мәктәпләр дә була. Мәсәлән, 1925 елда аларның саны 200 дип күрсәтелә (За 5 лет, 1925, с. 105).

Шулай ук бу елларда авылларда крестьян яшьләре мәктәпләре (ШКМ) ачыла башлый. 1925 елда аларның саны әле бөтен Татарстанга 3 кенә булса (За 5 лет, 1925, с. 105), 1926 елга — 12 (Отчет 6-го созыва, 1927, с. 88; ф. 3682, оп. 1, д. 997, л. 778), ә 1930 елга хәтта 45кә җитә (Материалы к отчету, 1931, с. 20).

Совет мәктәпләре татар халкының куйган өметләрен бик үк аклап бетермәгәнлек нәтиҗәсендә, 1922 елларда һәм бигрәк тә зур дулкын булып 1925-1926 елларда татар авылларында яңадан дини мәктәпләр күпләп ачыла башлый (Отчет 6-го созыва, 1927, с. 86). Татар муллалары йөзендә зур куркыныч күргән хөкүмәт һәм

Мәгариф комиссариаты ничек булса да совет мәктәпләрен саклап калу чараларына керешә, моның өчен дини мәктәпләрнең эшчәнлеген тыя, гаять зур көч белән дингә каршы пропаганданы җәелдерә.

Революциягә кадәр Россиядә мәгариф өлкәсендәге дәүләт монополиясе руслар кулында гына була, патша хөкүмәте бары рус мәктәпләрен һәм рус укытучысын гына танып, аларны дәүләт хисабына яшәтә, ә башка халыклар игътибардан читтә кала (ф. 3682, оп. 1, д. 288а, л. 103). Ләкин, татар мәктәпләре ачу өчен патша хөкүмәте тарафыннан бернинди матди ярдәм булмаса да, татар авылларының һәрберсендә диярлек мәктәп-мәдрәсәләр эшләп килә. Гадәттә 20 нче еллардагы хисапларда революциягә кадәр 35 кенә татар мәктәбе булган дигән фикер үткәрелә (За 5 лет, 1925, с. 103; ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 52; Доклад, 1927, с. 4), ләкин әлеге мәгълүмат дөреслеккә туры килми, бу күренеш тарихта татар мәдрәсәләренең исәбе алынмау һәм аларны мәктәпкә санамау, икенчедән, 1917 елга кадәр булганнарны фәкать кире яктан гына сурәтләргә омтылу нигезендә барлыкка килә. «Совет власте вакытында да мәгариф аппараты һәм аның җитәкчеләре татарларга караганда русларны мәгърифәтле итүгә күбрәк әһәмият бирәләр», — дип ачыктан-ачык күрсәтәләр 1922 елгы Татнаркомпрос докладында (ф. 3682, оп. 1, д. 288 а, л. 103). Дөрес, совет хөкүмәтенең ярдәмен, яклавын сизгән татарлар, башка халыклар кебек үк, революциядән соң зур күтәренкелек белән мәктәпләр ачу эшенә керешә, бу хәл 1921 елга кадәр гаять зур көч белән, ләкин стихияле рәвештә дәвам итә. Мәсәлән, Татарстан республикасында 1920 елга 1 нче баскыч мәктәпләрнең гомуми саны хәтта 2996ны, ә дәүләт хисабындагы татар мәктәпләренең саны шуларның яртысын диярлек — 1215не тәшкил итә. 2 нче баскыч мәктәпләрнең гомуми саны 125 булып,

шуларның 26сын татар мәктәпләре алып тора. Олылар өчен мәктәпләр: русларныкы — 50, татарларныкы — 27 (ф. 732, оп. 1, д. 120, л. 197).

1921 ел мәктәпләр өчен дә авыр сынау елы була, алар, ничек барлыкка килгән булсалар, шундый ук тизлек белән ябыла да башлыйлар. Мәсәлән, 1922 елга Татарстандагы барлык 1 нче баскыч мәктәпләр 2996дан 1741гә, ә 2 нче баскыч мәктәпләр 125тән 63кә кала (ф. 732, оп. 1, д. 120, л. 198). Бу кимү 1924 елга кадәр дәвам итә: 1924/25 уку елына 1 нче баскыч мәктәпләрнең саны 1698гә кала, шуларның 818е — татар, 602се — рус, 259ы — милли азчылык һәм 18е — катнаш мәктәпләр (Отчет о деятельности... за 1923-24 г., 1924, с. 18). 1921 елда булган 9 еллык 556 мәктәпнең 1924 елга 12се генә кала (За 5 лет, 1925, с. 104).

1924 елга кадәр мәктәпләрнең саны кискен кыскару — табигый күренеш, чөнки бюджетның коточкыч ярлылыгы, укытучыларның җитешмәве, булганнарына да хезмәт хакы түләп булмау, дәреслекләрнең, кулланмаларның булмавы — болар барысы да гаять күп сандагы мәктәпләрне тотуның реаль чынбарлыкка туры килмәвен дәлилли. ТҮБКның 2 нче сессиясендә ясаган чыгышында Мәгариф халык комиссары Солтанов мәгариф хезмәткәрләренең коточкыч авыр хәлен тасвирлый. Аның тарафыннан әйтелгән бер җөмлә генә дә күп нәрсәне аңларга ярдәм итәр: «Мы работали в такое время, когда работать было нельзя» (ф. 732, оп. 1, д. 8, л. 91). Авыр хәлгә түзә алмыйча, күп укытучылар акча күбрәк түләнә торган эшкә күчәргә мәҗбүр булалар (ф. 3682, оп. 1, д. 501, л. 9). Чагыштыру өчен мисал: укытучылар гражданнар сугышына кадәр алган хезмәт хакының 1922 елда уннан бер өлешен генә алганнар (ф. 732, оп. 1, д. 200, л. 327). Хисаплардан күренгәнчә, укытучыларның хезмәтенә түләү елдан-ел аз булса да арта бара. Мәсәлән, 1923-1924

елларда ул уртача 8-10 сумны тәшкил итсә, 1924 елның язына — 12-15 сум, 1924/25 уку елында — 24 сум, 1925 елда — 27-28 сум һәм 1926 елда — 32 сумга күтәрелә (Третья сессия, 1926, с. 35). Бәлки, хезмәт хакының артуы да йогынты ясагандыр, 20 нче еллар урталарындагы хисапларда инде татар укытучыларының бик аз булуыннан түгел, ә әзерлекле, тиешле белгечлеккә ия хезмәткәрләрнең бармак белән генә санарлык булуыннан зарланалар. Мәсәлән, 1924 елга кантоннардагы мәктәп хезмәткәрләренең гомуми саны — 4456, шуларның 2049ы — татар, 1931е — рус. Ләкин 4456 кеше арасыннан югары белемле укытучылар — татарлардан 1 генә кеше, руслардан — 4, милли азчылыктан — 9. Калганнары — урта һәм башлангыч белемле (Красная Татария. — 1924. — 18 июнь). Казан шәһәре өчен шул ук 1924 ел хакында китерелгән мәгълүматлардан да югары белемле татар укытучыларының 1 генә булуы, русларның исә, киресенчә, 100дән артып китүе аңлашыла (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 101). Хәтта урта белемле дип саналган татар укытучыларының да күпчелеге белемнәре буенча шөбһә тудыра, чөнки татар мәдрәсәләрен бетергәннәр дә үзләрен урта белемле итеп яздыралар, ә моның дөрес булмавын җитәкчеләр дә, татар галимнәре үзләре дә басым ясап күрсәтәләр (Третья сессия, 1926, с. 42, 67). Шунлыктан, бу елларда татар укытучыларының зур күпчелеген башлангыч белемлеләр тәшкил иткән дисәк, хата булмастыр.

Укытучыларның квалификацияләрен күтәрү максатында, Наркомпрос тарафыннан күп санлы курслар оештырыла. Мәсәлән, 1925 елга үзәктәге һәм кантоннардагы курсларны 917 кеше тәмамлап, бу барлык укытучыларның 45%ын алып тора, аларның да зур өлешен татарлар һәм милли азчылык вәкилләре тәшкил итә

(Третья сессия, 1926, с. 42). Моннан тыш, укытучылар өчен конференцияләр, түгәрәкләр, методик бюролар оештырыла.

20 нче еллар укытучылары эшләре азлыктан һич тә зарлана алмыйлар. Бигрәк тә авылларда гадәттә бер мәктәптә бер укытучы гына эшли. Ул елларда бер укытучыга иң кимендә — 40 укучы, ә күпчелек очракта хәтта 70 укучы туры килә (За 5 лет, 1925, с. 105). Мондый хәл, билгеле, укытуның нәтиҗәлелеген бик нык киметә, укытучыга бөтен булган белемен эшкә җигәргә мөмкинлек бирми. Ул көненә 10ар сәгать эшләргә мәҗбүр була (ф. 3682, оп. 1, д. 628, л. 82). Җитмәсә, бу вакыттагы мәктәп биналарын да хәзерге берничә катлы, бөтен уңайлыклары булган мәктәпләр белән һич тә чагыштырып булмый. Бигрәк тә татар мәктәпләре бик кечкенә йортларда, хәтта мунчаларда урнаша (Третья сессия, 1926, с. 38). 1925 елның февраль-март айларында 17 инспектор катнашында барлык мәктәпләрне тикшереп чыгу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, татарлар һәм милли азчылыкның мәктәпләр белән тәэмин ителеше бары 10% белән генә билгеләнә ала (ф. 3682, оп. 1, д. 628, л. 83). Тәтеш кантоны буенча бирелгән мәгълүматларда хәтта мәйданы 5кә 5 аршынлы, ягъни 12,64 кв. метрлы, ә биеклеге бары 2 аршынлы (1,42 м.) мәктәпләрнең очравы күрсәтелә (ф. 3682, оп. 1, д. 628, л. 85). Башка кантоннарда да татар мәктәпләренең гаять начар хәлдә булуы ассызыклана.

Әлеге тикшерүдә шулай ук Бөгелмә кантоны хакындагы мәгълүматлар кызыклы. Чагыштыру өчен рус һәм татар волостьлары алына. Рус волостенда мәгариф эшләре артта сөйрәлә. Бер еллык һәм ике еллык мәктәпләр күпчелекне тәшкил итә. Мәктәп балалары арасында корчаңгы, трахома һәм сифилис авырулары киң таралган һәм алар әйләнә-тирә өчен куркыныч тудыралар. Татар

волостендагы мәктәпләрдә исә хәлләр күпкә яхшырак куелган була (ф. 3682, оп. 1, д. 628, л. 84).

Татарстандагы 1 нче баскыч татар мәктәпләрендә укыту татарча алып барыла, һәм балаларны үз ана телләрендә укыту өчен кирәк булган дәреслекләр, уку кирәк-яраклары, мәктәп биналарыннан башка проблемалар булырга тиеш түгел кебек. Ләкин шул вакытта ук безнең өчен бик тә таныш булган мәсьәлә бөтен ачылыгы белән көн үзәгенә килеп баса: 2 нче баскыч, профессиональ-техник уку йортларында укыту рус телендә алып барыла, вузларга кергәндә русча белергә кирәк — нәтиҗәдә татар балалары белемнәрен дәвам итә алмыйлар. Бу авыр хәлдән чыгу юллары хакында мәгариф эшчеләре, укучылар арасында һәм, гомумән, матбугатта фикер алышулар һәм бәхәсләр дә булып ала. Бигрәк тә «Мәгариф» журналы 1924-1925 елларда әлеге бәхәсләрнең үзәгендә тора. Фикерләр нигездә икегә аерыла. Беренче фикер буенча, Татарстанның 1 нче баскыч мәктәпләрендә, татар теленнән башка, икенче сыйныфтан ук рус теле бик нык укытылсын. 2 нче баскыч мәктәпләрнең беренче сыйныфыннан рус теле укыту теле булып, татар теле исә фән булып кына калсын (Мәгариф. — 1925. — №9. — Б. 3). Шулай итеп, беренче фикер нигезендә, нәтиҗәдә рус теле генә чын дәүләт теле хокукына ия булып кала. Тарихтан билгеле булганча, кызганычка каршы, нәкъ шул юл соңрак зур күтәрелеш алып, татар телен мәктәпләрдән кысрыклап чыгара да инде.

Бәхәстә катнашучы икенче якның фикере тормышка ашкан булса, бәлки, күп дистә еллар буе татар теле бары урам теле генә булып калу язмышына дучар булмас иде. Татар телен чын дәүләт теле итеп күрергә теләүчеләр арасында мәсьәләгә артык җиңел генә караучылар да була. Аларның уйлавынча, Татарстанда татар мәктәпләре башка милләт мәктәпләренә караганда йомшак

куелмаган. Шәһәрләрдә һәм авылларда бик яхшы эшләүче мәктәпләр бар һәм алар үсәләр. Бөтен татар мәктәпләрен бик яхшы итеп кую өчен, мәктәп бинalары, яхшы укытучылар хәзерләргә кирәк. Һәм бер вакыт килер: берәү русча биш югары мәктәп бетерсә дә, әгәр татарча яхшы хәзерләнгән булмаса, татар дигән паспорты белән аны бер җиргә дә эшкә алмаслар, һәм ул кеше файдалы да булмас. Мәсьәлә шуңа таба бара бит, диләр (Мәгариф. — 1925. — №9. — б. 4). Кайберәүләр, мондый оптимистик хыяллар белән генә чикләнмичә, татар теле Татарстанның барлык 1 нче һәм 2 нче баскыч мәктәпләрендә һәм югары уку йортларында булырга тиеш дигән конкрет тәкъдим белән чыгалар. Аларның фикеренчә, барлык мәктәпләрне дә саф татарча куярга мөмкин. Әгәр кайсыбер аерым дәресләр өчен башка телдә укытучылар таләп ителсә, аларны чакырырга кирәк. Ләкин хәзерге көндә әле 2 нче баскыч мәктәпләр һәм техникумнар өчен татар укытучылары арасыннан җитәрлек көч җыеп булмый. Әгәр бөтен уку йортлары, ашыгып, кирәк булган гыйльми көчләрне чыгара-хәзерли алмасалар, Татарстан хөкүмәтендә татар телен гамәлгә кую планы аксарга мөмкин, дип чаң сугалар (Мәгариф. — 1925. — №9. — б. 8).

1921 елның 25 июнендәге ТТГК буенча беренче декретта «барлык 2 нче баскыч мәктәпләрдә теләгәннәр өчен татар теле кертергә» дигән кечкенә генә пункт та урын алган (Сб., 1925, с. 6). Ләкин татар телен өйрәнергә атлыгып торучылар булмаганын күреп, хөкүмәт башка юлга күчәргә мәҗбүр була. 1922 елның 8 маендагы ТҮБК карарында Мәгариф комиссариатына 1922/23 уку елыннан башлап, Татарстанның барлык урта, югары һәм профессиональ-техник уку йортларына татар теле укытуны кертергә тәкъдим итела (Сб., 1925, с. 9). Ә 1922 елның 21 декабрендәге инструкциядә инде, алдагы карарны кабатлап һәм тагын да тирәнәйтеп, барлык 2 нче

баскыч, профтехник уку йортларында, партия мәктәпләрендә, эшче факультетларында һәм вузларда, ә шәһәрләрдә шулай ук 1 нче баскыч мәктәпләрнең соңгы сыйныфларында да барлык укучылар өчен татар теле өйрәнү мәҗбүри итеп куела (Сб., 1925, с. 13).

Әлеге карарларның, кабул ителеп кенә калмыйча, үтәлә дә башлаулары күп чыганакларда раслана (ф. 732, оп. 1, д. 154, лл. 15-17; Известия ТЦИКа. — 1923. — №131; Доклад, 1927, с. 38). Мәсәлән, 1922/23 уку елында барлык кантоннарда да диярлек 2 нче баскыч мәктәпләрнең уку планына татар теленең махсус предмет итеп кертелүе һәм, татарлар белән бергә, аны рус һәм башка милләт балаларының да өйрәнүе билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 154, л. 16). 1927 елгы мәгълүматларда да татар теленең карарда саналган мәктәпләрнең төрле уку елларына бер-бер артлы кертелеп баруы, якын елларда күрсәтелгән уку йортларының һәр сыйныфына кереп бетеп, татар теленең чын мәгънәсендә гражданлык алачагына ышаныч белдерелә (Икенче баскыч рус мәктәпләре өчен татар теле программасы, 1927, б. 3).

Рәсми рәвештә уку йортларында татар теле укытылса да, эшнең нәтиҗәләре гаять начар була. «Татар телен уку йортларында дәрес итеп укытуда тәҗрибәләрнең юк дәрәҗәсендә аз булуы, укытучыларның хәзерлекләре җитмәү, белгечлекләре ягыннан чуар булулары» (Икенче баскыч, 1927, б. 3), дәреслекләр, программалар булмау кебек һаман шул бер үк проблемалар күрсәтелә. Бигрәк тә рус балаларына татар теле укыту эше иң артта сөйрәлә. Хәтта 1929 ел ахыры — 1930 ел башында комиссия тарафыннан үткәрелгән тикшерүләрдә татар булмаганнарга татар теле өйрәтүнең һаман башлангыч этаптан уза алмавы билгеләнә. 1 нче баскыч мәктәпләргә татар теле ары 1930/31 уку елыннан гына кертелергә уйлана (Харисов, 1995, с. 30). 2 нче баскыч мәктәпләрдә татар теле 1922/23

уку елыннан ук укытыла башласа да, рус мәктәпләре өчен татар теле программасы бары 1927 елда гына басылып чыга. Ул 5 сыйныфлы (9 еллык) 2 нче баскыч рус мәктәпләренең һәр сыйныфында үткәрү өчен 5 еллык итеп төзелә. Беренче 3 сыйныфта татар теле атнасына 4әр сәгать, 4 нче сыйныфта 3әр сәгать һәм соңгы сыйныфта 2шәр сәгатьлек итеп, барлыгы 544 сәгатькә исәпләнә (Икенче баскыч, 1927, б. 7).

Мәктәпләрдә татар теле гадәттә иң соңгы дәрес булып куела, моңардан исә дәресләрнең сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге дә кими, укучыларның кызыксынучанлыгы да азая (Харисов, 1995, с. 30-31). Рус балаларына татар теленең ни өчен укытылуы хакында аңлату эшләре дә начар алып барыла. Мәсәлән, ТҮБКның 3 нче сессиясендә ясаган чыгышында М.Борындыков (Үзәк мөселман хәрби коллегиясе җитәкчесе, Мәгариф халык комиссары булып эшли, 1930 елда репрессияләнә) китергән мисал чәчләрне үрә тордырырлык: «2 нче баскыч мәктәптә укучы бер җиткән кыздан татар телен ни өчен өйрәнүләрен сорагач, ул, бераз икеләнеп торганнан соң: «Татарлар арасында яшибез; берәр кантонга барып, татар йортына туктарсың, синең тирәңдә ни сөйләшкәннәрен белергә кирәк бит, бәлки: «Бу кешене суярга кирәк!» — дип сөйләшәләрдер», — дип җавап биргән» (Доклад, 1927, с. 25).

Рус мәктәпләрендә генә түгел, Татарстандагы милли азчылык мәктәпләрендә дә татар теле укытыла башлый. 1923 елның 19 мартында Мәгариф комиссариатының Милли азчылык бүлеге коллегиясе утырышында татар теле өйрәтүне 1 нче баскыч мәктәпләрнең өченче уку елыннан башлап, ике ел дәвамында укыту, моңа атнасына 2-4 сәгать вакыт бирү, ә 2 нче баскыч мәктәпләрдә исә татар телен гамәлгә кертүне башка мәктәпләрдәге кебек үк уздыру хакында карар кабул ителә. Татар теле укыту ике юнәлештә:

җанлы сөйләм теленә һәм татар грамотасына өйрәтү рәвешендә алып барылырга тиеш була. Шулай ук халык арасында бу карарны татарлаштыру дип аңлап, каршы чыгу очраклары да булу мөмкинлеге искәртелә, сак булырга чакырыла (ф. 3682, оп. 1, д. 410, л. 35). Шул ук утырышта милли азчылыкны тәшкил итүче халыкларның телләрен гамәлгә кую мәсьәләсе дә каралып, коллегия әгъзаларының үз мәктәпләрен руслаштыру юнәлешенәрәк авышулары күренә. Чөнки алар 1 нче баскыч мәктәпләрнең 1-2 нче сыйныфларында гына фәннәрне ана телендә укытып, рус телен предмет итеп бирү, ә 3-4 нче уку елларында исә рус телен укыту теленә әйләндерү хакында карар кабул итәләр. Ләкин ул вакыттагы Соцвос идарәсе мөдире Максудов 1 нче баскыч милли азчылык мәктәпләрендә укыту ана телләрендә генә алып барылырга тиешлеккә басым ясап, бу карарны кире кага (ф. 3682, оп. 1, д. 410, л. 36).

Шулай итеп, татарлар арасында иң киң таралган мәктәп төрен тәшкил иткән 1 нче баскыч мәктәпләрдә укыту татар телендә алып барыла, ләкин 1924 елдан ук инде аларда рус телен укытуга зуррак әһәмият бирергә кирәклеге хакындагы фикерләр күзәтелә башлый. 2 нче баскыч мәктәпләрнең исә күбесендә укулар рус телендә алып барыла. Хөкүмәтнең 1922 елгы карарлары нигезендә, аларда татар теле укыту мәҗбүри итеп куелса да, әлеге эш, бигрәк тә рус балаларына татар теле өйрәтү, көткән нәтиҗәләрне бирми.

3.2. Профессиональ белем бирү баш идарәсе (Главпрофобр) профтехник уку йортлары, курслар, ФЗӨ (фабрика-завод өйрәнчекләре) мәктәпләре, техникумнар, эшче факультетлары һәм югары уку йортлары эшчәнлеге белән җитәкчелек итә. 1925 елга әлеге идарә кул астында 5 вуз, 2 эшче факультеты, 23 техникум, 8 ФЗӨ мәктәбе, 8 профтехник мәктәп һәм 5 профтехник курс эшли (За

5 лет, 1925, с. 106). Татарстандагы профессиональ белем челтәре дә РСФСРныкыннан артык аерылмый: техникумнар укучыларны 7 еллык һәм 9 еллык мәктәпләрдән соң, профессиональ мәктәпләр һәм ФЗӨләр — 4 еллык мәктәпләрдән соң кабул итәләр (ф. 3682, оп. 1, д. 1147, л. 57). Ләкин, бер яктан, 2 нче баскыч мәктәпләрнең күпчелегендә укулар рус телендә алып барылу нәтиҗәсендә, татар балаларына бу мәктәпләрдә белемнәрен дәвам итү авырлык тудыра, икенче яктан, профтехник уку йортлары һәм вузларда да бары рус теле генә таләп ителә. Шулай итеп, гаять кирәкле татар белгечләре хәзерләү юлында икеләтә авырлык барлыкка килә. Главпрофга кергән уку йортларына татарларны күпләп кабул итәргә кирәк дигән фикер барлык хисапларда, съезд һәм сессияләрдә дә диярлек ассызыклана, моңа ирешү өчен кулдан килгән кадәр чаралар да күрелә. Мәсәлән, 1920-1925 еллар аралыгында татарлар өчен түбәндәге уку йортлары ачыла: Казанда — татар педагогия техникумы, авыл хуҗалыгы техникумы, махсус культуралар техникумы, татар театр техникумы, татар сәнәгать-икътисад техникумы, Көнчыгыш педагогия институты каршында махсус татар эшче факультеты, Алабугада — татар педагогия техникумы. Моннан тыш, Чистай һәм Тәтештә катнаш рус-татар педагогия техникумнары, Казанда керәшен педагогия техникумы эшли (За 5 лет, 1925, с. 106-107). Күренгәнчә, элек чыннан да күпчелеге урта һәм югары белем алудан мәхрүм ителгән татарлар өчен 5 ел эчендә генә дә гаять зур эш башкарылган. Татарларны уку йортларына җәлеп итү буенча да азмы-күпме алга китеш күзәтелә, бигрәк тә профтехник мәктәпләр һәм техникумнар бу мәсьәләдә сизелерлек уңышка ирешәләр. Мәсәлән, 1922/23 уку елында профтехник мәктәпләрдә укучылар 19%ны тәшкил иткән булса, 1924/25 елларда — 43,3%ны, ә 1925/26 елларда 52,6%ны алып тора (Третья сессия,

1926, с. 44). Техникумнарда да татарларның саны елдан-ел арта барып, 1927 елда 48,5%ка җитә (Доклад, 1927, с. 39).

Татарларның профессиональ-техник уку йортларына керүләрен җиңеләйтү максатында, аларда әзерлек курслары төзелә. Ләкин бу елларда хәтта татарлар күпчелекне тәшкил иткән уку йортларында да укытуны татар теленә күчерә алмыйлар. Техникум һәм профтехник мәктәпләрдә укыту өчен татар белгечләрен хәзерләү, булганнарының белемен күтәрү мәсьәләсе көн үзәгенә килеп баса. 1925 елның декабрендәге ТҮБК сессиясендә Мәгариф халык комиссары урынбасары Таһиров кайбер профтехник уку йортларында, әзерлек группаларыннан башлап, әкренләп татар телендә укытуны кертү каралганлыгын билгели (Третья сессия, 1926, с. 45). Бу исәпкә укыту рус телендә генә алып барылган Казан медицина һәм фармацевтика техникумнары да кертелә. Ләкин 1925/26 уку елына күз салсак, бу елда кабул ителүчеләрнең хәтта 70%ын татарлар тәшкил итсә дә, татар телен аңламаучы берничә милли азчылык вәкиле булуны сәбәп итеп, дәресләр рус телендә генә уздырыла башлый (Третья сессия, 1926, с. 45). Башка уку йортларын да ахыр чиктә нәкъ шундый ук язмыш көтә.

Татарларны җәлеп итү һәм татар телен өйрәтү буенча иң авыр хәл югары уку йортларында күзәтелә. Бу елларда Казанда 5 югары уку йорты исәпләнә. Аларның икесе — элеккеге вузлар: Казан дәүләт университеты — 1804 елдан, ветеринария институты 1874 елдан бирле эшли (За 5 лет, 1925, с. 112). Берсе — Көнчыгыш педагогия институты (ВПИ) — 1922 елда элеккеге пединститут, университетның иҗтимагый фәннәр факультеты һәм Көнчыгыш Академиясе нигезләреннән үсеп чыга (За 5 лет, 1925, с. 111). Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты шулай ук 1922 елда университет факультетыннан институт булып аерылып чыга. Совет

чоры күренеше һәм яңа нигезләрдә төзелгән бер генә уку йорты кала — Татар коммунистик университеты. Ул башка оешма — РСФСР Главполитпросветы карамагында эшли һәм 1925 елга студентларның саны түбәндәгечә билгеләнә: 211 студентның 128е — татар, 54е — рус һәм 29ы — милли азчылыктан. Калган вузлар шулай ук РСФСР карамагында, ләкин аның Главпрофобр идарәсе кул астында эшлиләр һәм үзәктән финансланалар. Татарстан Мәгариф комиссариаты да вузларга кулыннан килгән кадәр ярдәм итәргә тырыша (За 5 лет, 1925, с. 112). Ләкин үзәкнең Татарстан югары уку йортларында татар телен гамәлгә кертү өчен акчаны кирәкле күләмдә бирә алмавы, шунлыктан җирле бюджеттан бу максатка җитәрлек кадәр акча бүлеп бирергә кирәк дигән фикер дә мәгариф хезмәткәрләре арасында еш күзәтелә (Доклад, 1927, с. 42). Хәтта 1922 елда ук Борындыков Мәгариф комиссариаты хакында ясаган чыгышында вузларны Татарстан Мәгариф комиссариаты карамагына бирергә кирәк дигән мәсьәләне күтәрә, мондый хәл автономияле республиканы канәгатьләндерә алмый, дип күрсәтә. Аның чагыштырулары бик кызык: «Барлык мәгариф эше иң гарип «чукмарбаш» («головастик») формасында күренә, аның башы безнең йогынты астында түгел, ә койрыгы — элементар тәрбия — Татнаркомпрос кул астында. Баш бер юнәлештә хәрәкәт итә, ә койрык болытларга омтыла» (ф. 732, оп. 1, д. 120, л. 223).

Турыдан-туры үзәккә буйсынган Казан югары уку йортлары татар студентларын җәлеп итү буенча барлык уку йортлары арасында иң соңгы урыннарда бара. Шулай да элек төп масса татарларга тормышка ашмаслык хыял гына булып күренгән вуз студенты булу бәхете, бик акрынлык белән булса да, елдан-ел күбрәк татарлар өчен чынбарлыкка әверелә бара. Кайбер уку елында татарларны кабул итүнең кимүе әзерлекле укучыларның булмавы

белән аңлатыла (Тезисы к докладу, 1927, с. 18). Барлык вузларда укучы татар студентларының саны ничек үзгәреш кичергәнне белер өчен, статистик мәгълүматларга күз салыйк: 1922/23 еллар — 5,17%; 1923/24 — 9,7%; 1924/25 — 11,7% (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 146) (башка чыганакларда — 11% (Отчет 5 созыва, 1926, с. 95), 11,2% (За 5 лет, 1925, с. 108), 11,9% (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 53)); 1925/26 — 14% (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 146), икенче чыганакта — 11,1% (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 147); 1926/27 — 8,2% (Тезисы к докладу, 1927, с. 20) яки 8,4% (ф. 3682, оп. 1, д. 1147, л. 63); 1927/28 — 9,8% (ф. 732, оп. 1, д. 1138, лл. 15-16); 1929/30 — 20,1% (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 280); 1930/31 — 24% (Материалы к отчету, 1931, с. 24). Күренгәнчә, 8 уку елы эчендә татарларның саны 18,83%ка арткан.

Югары уку йортлары арасында иң аз татар студентлылары булып ветеринария институты һәм Казан дәүләт университеты санала. Мәсәлән, 1925-1927 елларда ветеринария институтында татарлар 3,7-3,8%ны, ә университетта 6,7-7,03%ны тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 147; Тезисы к докладу, 1927, с. 23). Бу вакытта медицина һәм физика-математика факультетларыннан гына торган университет 1927/28 уку елында да татарларның саны белән мактана алмый — 7,4% (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 39). Гомумән, университетта бу вакытта руслар абсолют күпчелекне алып торалар. Ветеринария институты да татар мал врачларына мохтаҗлык кичергән Татарстанның ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый. Мәсәлән, 1928 елда бөтен Татарстан республикасында 5 кенә татар ветврачы исәпләнә, аларның да 2се әле мәгълүмат бирелгән вакытта дәүләт имтиханнарын тапшырмаган була (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 40).

Агрономнар һәм урманчылар әзерләүче авыл хуҗалыгы институты да Татарстанны гаять кирәкле татар авыл хуҗалыгы белгечләре белән тәэмин итә алмый. Анда укучы татар

студентларының саны хәтта милли азчылыктан да азрак була (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 14). 1925-1927 елларда ул 8,4-9,4% арасында тирбәлә (Тезисы к докладу, 1927, с. 23). Мәсәлән, 1925 ел ахырына бөтен студентларның саны 960 булып, шуларның 81ен татарлар тәшкил итә. Авыл хуҗалыгы факультетында татарлар күбрәк була (61 студент), бу аның беренче чиратта Татарстанны тәэмин итүе белән аңлатыла. Гомумән алганда, авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты студентларының күпчелеген башка губерна, өлкә һәм республикалардан килгәннәр тәшкил итә, шунлыктан татар телен өйрәнү дә мәҗбүри рәвештә куелмый (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 14).

Бары Көнчыгыш педагогия институтында гына татарлаштыру азмы-күпме җайга салына. Исеме үк Көнчыгыш өчен хезмәткәрләр әзерләү икәнне күрсәтеп торган һәм нигездә 2 нче баскыч мәктәпләр, эшче факультетлары, техникумнар, крестьян яшьләре һәм ФЗӨ мәктәпләре өчен укытучылар һәм туган якны өйрәнү хезмәткәрләре әзерләүче Көнчыгыш педагогия институтында татарларның бары 12%ны гына тәшкил итүе (Тезисы к докладу, 1927, с. 23) — зур казаныш түгел, шулай да бары әлеге институтта гына мәҗбүри рәвештә татар теле укытыла (Доклад, 1927, с. 38), махсус татар бүлеге оештырыла (Третья сессия, 1926, с. 50). Дәресләр ике группага бүленеп алып барыла: бер укытучы татар студентлары өчен генә лекция укый, икенчесе — барлык студентлар өчен (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 13 об.).

1926 елның 11 февралендә Үзәк комиссиягә язган хатында Көнчыгыш педагогия институтында татар теле укытучы Абдуллин 13 тәкъдим белән чыга. Аларның әһәмиятлерәкләре: 1) ВПИда татар теле укыту һәм өйрәнүгә иҗтимагый-сәяси һәм дәүләткүләм әһәмият бирү; 2) татар телен өйрәнү Татарстан республикасындагы учреждениеләрдән стипендия алучы, шулай ук республикада эшкә

калырга җыенучы татар булмаган студентлар өчен мәҗбүри булырга тиеш; 3) киләчәктә студентларның бары соңгы курста гына татар теле өйрәнергә керешүләрен берничек тә булдырмаска; 4) 2 нче пунктта күрсәтелгән татар булмаган студентлардан институтка кергәндә 200 сәгатьлек курс күләмендә белемнәре булуны таләп итәргә, моның өчен кабул ителүчеләрнең законлы язма белешмәләре булырга тиеш. Булмаган очракта, аларны тикшерү аша уздырырга кирәк; 5) һәр студент, 1 нче курстан башлап, мәҗбүри рәвештә 400 сәгатьлек татар теле курсын үтеп бетерергә тиеш; 6) һәр төркем өчен татар теле дәресләре атнага 4 сәгатьтән дә ким куелмый; 7) студентларның дәресләргә йөрүе, соңга калмаулары, өй эшләрен үтәүләре ныклы контроль астында тотыла; 8) институтны бетерүче студентлар татар теленнән алган белемнәре буенча махсус комиссиягә зачет бирәләр. Комиссия составына партия ячейкасы, студентлар оешмасы, ТТГК Үзәк комиссиясеннән вәкилләр һәм татар теле укытучысы керә; 9) тикшерү комиссиясенә зачет бирә алмаган студентларга диплом бирелми һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 770, лл. 75-75 об.). Бу тәкъдимнәр күпме дәрәҗәдә тормышка ашырылгандыр — анысы билгесез. 1927 елда сметалар кыскартылу нәтиҗәсендә, институтта татар телен мәҗбүри укытуның тукталуы мәгълүм (Доклад, 1927, с. 39), ләкин җирле яки үзәк бюджетның булышлыгы ярдәмендә, татар телен өйрәтү дәвам иткән булырга тиеш.

Мәгариф халык комиссары урынбасары Мөхетдиновның 1927 елда булган ТҮБКның 3 нче сессиясендәге чыгышыннан күренгәнчә, Көнчыгыш педагогия институтыннан кала, башка югары уку йортларының берсендә дә татар теле укыту мәҗбүри төстә куелмый (Доклад, 1927, с. 38). Ләкин хөкүмәт карарлары нигезендә, мондый хәл килеп чыгарга тиеш булмый, чөнки 1922 елның 8 маендагы ТҮБК карарында югары уку йортларында татар теле укыту

кирәклеге билгеләнә (Сб., 1925, с. 9), ә шул ук елның 21 декабрендәге инструкциядә инде татар теле өйрәнүнең мәҗбүри икәнлеге ассызыклана (Сб., 1925, с. 13). 1926 елның 2 февралендә булган партия өлкә татар комитеты пленумында кабул ителгән резолюциядә дә (Культурное строительство в Татарии, 1971, с. 263), шул ук елның 25 июнендә Үзәк комиссия тарафыннан бирелгән белешмәдә дә урта һәм югары уку йортларында татар теле укытуның мәҗбүри булу фикере кабатлана. Белешмәдә күрсәтелгәнчә, студентлар башка предметлар кебек үк, татар теленнән дә зачет бирергә тиешләр, ә зачет бирә алмаганнарга диплом бирелми. Чыгарма булып диплом бирелгән очракта да, дипломга студентның татар теленнән зачет бирмәве языла (ф. 732, оп. 1, д. 768, л. 229). Бары 1925 елның ноябрендә булган ТТГК өчле комиссияләре киңәшмәсендә генә барлык вузларның уку планына татар телен факультатив нигезләрдә, ягъни теләгәннәр өчен генә кертү хакында карар кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 19). Шулай итеп, күп санлы карарлар нигезендә, урта һәм югары уку йортларында татар теле укыту мәҗбүри итеп куелса да, чынлыкта бу мәҗбүрият бары Көнчыгыш педагогия институтында гына тормышка ашырыла, ә башка уку йортларында исә күбесенчә я бөтенләй кертелми, я теләгәннәр өчен генә укытыла.

Югары уку йортларындагы рус студентларына татар теле өйрәтү өчен программа юклык та зур авырлык тудыра. Хәтта 1927 елда да әле вузлар өчен аерым программа төзүне иртәрәк санап, Гыйльми үзәк янындагы методика һәм педагогия комиссиясе әгъзалары 2 нче баскыч (9 еллык) рус мәктәпләре өчен төзегән программаларын вакытлы рәвештә югары мәктәпләр өчен дә нигез итеп алырга тәкъдим итәләр. Чөнки, аларның күрсәтүенчә, «югары уку йортлары өчен татар теле — урта типтагы рус мәктәпләренә

караганда да яңарак эш. Татар теле кайбер вузларга яңа кергән булса, кайберләренә әлегә кадәр бөтенләй кергәне дә юк. Татар теле укытылган вузларда да эшләр 1 нче курсларда гына түгел, соңгы курсларда да 2 нче баскыч рус мәктәпләренең 1 нче, күп булса, 2 нче уку елы өчен программадан, хәтта әлифбадан, югары узганы юк әле» (Икенче баскыч, 1927, б. 12-13).

Эшче һәм крестьяннарны югары уку йортларына хәзерләү максатында төзелгән һәм бүгенге көндә дә атамасы кулланылыштан төшмәгән эшче факультетлары 20-30 нчы елларда татар яшьләренә дә югары белем алуда зур ярдәм күрсәтәләр. Эшче факультетлары 1919 ел башында төзелә башлыйлар (Сатрапинский, 1923, с. 31) һәм, Казан дәүләт университетыннан тыш, башка уку йортларында озын гомерле булып чыкмыйлар. Мәсәлән, 1921/22 уку елында Казандагы политехника институтында, Көнчыгыш Академиясендә һәм художество-техник институтында да эшче факультетлары эшли, ләкин алдагы уку елында ук алар ябылалар (Сатрапинский, 1923, с. 32). КДУ каршында эшләүче эшче факультеты үзе 2 курска бүленә: төп курс һәм нигездә татарлар өчен әзерлек группалары. Шулай итеп, болай да университетка хәзерләү максатын күздә тоткан эшче факультетына керү өчен дә әзерлек группасы аша үтәргә кирәк була, ягъни куян шулпасының шулпасы барлыкка килә. Әзерлек группаларының төзелү сәбәпләре итеп Татарстан республикасындагы уку йортларында (1 нче баскыч татар мәктәпләрен исәпләмәгәндә) белем бирүнең 90%ка рус телендә алып барылуы, нәтиҗәдә татарларның гомуми белем дәрәҗәсе түбән булуы, рус телен бөтенләй белмәүләре күрсәтелә (Отчет за время, 1923, с. 204), ягъни татар яшьләренең белемнәре укыту фәкать рус телендә алып барылган университетка гына түгел, хәтта эшче факультетына керү өчен дә җитәрлек булмый.

КДУ янындагы Дәүләт эшче факультетыннан тыш, 1923/24 уку елында (За 5 лет, 1925, с. 110) Көнчыгыш педагогия институты каршында РСФСРдагы барлык татарлар өчен махсус Татар эшче факультеты төзелә (Отчет за время, 1923, с. 204). 1925 елның 1 декабренә бирелгән мәгълүматларда КДУ каршындагы Дәүләт эшче факультетында татарларның 22,4% алып торуы, ә Татар эшче факультетында укучы 238 кешенең 196сын (82,3%) татарлар тәшкил итүе күрсәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 147). 1926/27 уку елында Дәүләт эшче факультетына — 25,12% (195 кешенең 50се), Татар эшче факультетына 80,28% (142нең 114е) татар кабул ителә (Тезисы к докладу, 1927, с. 23).

Эшче факультетларында гына түгел, профтехник мәктәпләр карамагындагы әзерлек группаларына керергә әзерләүче курслар булуы да мәгълүм. Әле алай да мәгариф хезмәткәрләре эшләрнең нәтиҗәсе бик үк яхшы булмаудан зарланалар (Третья сессия, 1926, с. 53).

Казандагы югары уку йортларына 20дән артык губерна, өлкә һәм республикалардан килеп укыйлар. Мәсәлән, 1924/25 уку елында Татарстан республикасы студентлары 42,6%ны, ә чит өлкәләрдән килгәннәр 57,4%ны тәшкил итә (За 5 лет, 1925, с. 109). Татарстанда милли азчылыкны алып торган чуваш, мари, мордва, удмурт һәм башкаларның Казан вузларындагы саны, күрше өлкәләрдән килгәннәр белән бергә, 12,8%ка җитә. Шулай ук, әкренлек белән булса да, Казанга башка төрки халыклар да тартыла башлый. Мәсәлән, 1924-1925 елларда укучы башкорт, кыргыз, таҗик, үзбәк, кырым татарлары, калмык, караим һ.б. студентларның саны 73кә җитә, ягъни барлык студентларның 1,5%ын тәшкил итә (За 5 лет, 1925, с. 108-110). Ләкин башка республикалардан килеп укучы студентларның күпчелекне алып торуы болай да авыр хәлдәге

Татарстан өчен өстәмә мәшәкатьләр тудыра. Мисал өчен Үзәк комиссия сәркатибе Н.Петров сүзләрен китерик: «Башка губерна һәм республикалардан килеп укучы студентларга кунакчыллыгыбыз беркем тарафыннан да инкяр ителә алмый. Ләкин үзебезнең Татарстан республикасы студентларының яшәү шартлары коточкыч. Чуваш республикасы, Мари өлкәсе һәм башка губерналарның студентлары стипендиягә өстәмә рәвештә пособие алалар, аларның үз тулай тораклары, якташ студентлар оешмалары бар. Ә Татарстан республикасы студентлары алар белән чагыштырганда авыррак хәлдә яшиләр, нәтиҗәдә авыл хуҗалыгы һәм ветеринария институтларыннан качу, бер уку йортыннан икенчесенә күчү яисә, гомумән, совет учреждениеләренә эшкә китү очраклары күзәтелә (Доклад, 1927, с. 47).

Әлеге мәсьәләдән тыш, Татарстан Главпрофобр карамагындагы уку йортларында татар телен гамәлгә кертүгә аяк чалучы проблемаларның күбесе башка уку йортларындагы белән тәңгәл килә: белемле татар укытучыларының аз булуы, булганнарының да матди кыенлыкта яшәве (ф. 3682, оп. 1, д. 997, л. 368), татар теле дәреслекләре, кулланмалары һәм программалары булмау, татар студентларына стипендия аз түләнү (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 19), уку йортлары биналарының начар хәлдә булуы, татарлар өчен тулай торак һәм интернатлар кирәк булу (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 9) һ.б.

Моннан тыш, Главпрофобр идарәсе үзе дә уку йортларында татар теле укыту мәсьәләсенә җитәрлек әһәмият бирми. Аның үз карамагындагы уку йортларында татар теле атнасына 2 сәгать 2 ел буе укытыла дигән кәгазеннән башка бернәрсә дә булмый (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 8). Нәтиҗәдә нинди хәлләр килеп чыкканын күз алдына китерү кыен түгел. Татар теле укытучысы Касыйм Субаевның 1925 елның 16 октябрендә Үзәк комиссиягә язган

хатыннан алынган өзек моңа ачык мисал булып тора: «... медицина техникумында 1924/25 уку елында татар теле фәкать 1 нче курста гына куелган иде. Студентларның яртыдан артыгы татар теле дәресенә йөрмәделәр. Мин берничә мәртәбә мәктәп администрациясенә белдергәннән, йөрмәүчеләрнең исемлеген биргәннән соң, «татар теленнән зачет бирмәгән кешеләр техникумнан чыгарылачак» дип, кәгазьябыштырдылар. Яз җиткәч, татар телен күз күне бирергә калдырдылар. Күз җиткәч, минем разый булмавыма карамый, зачетсыз-нисез үткәрделәр. ...Студентлардан артык күп сорарга да мөмкин түгел иде, ләкин администрация узган кадәр сорауны да күп санады. Туры әйтмәсәләр дә, ничек булса да аз гына сорап үткәрү яклы икәннәре бик ачык күренде. Җыелышта бөтен укучылар алдында техникум мөдиренең «Главпрофобр татар телен гамәлгә куюга ничек карый?» дигән сорауга: «Главпрофобр дает 2 часа в неделю и смотрит формально» дип җавап бирүе нәтиҗәсендә, билгеле, укытучының обязательный предмет дип сөйләп килгән сүзләренә укучыларның ничек караячаклары, татар теленә моннан соң ничек әһәмият бирәчәкләре алдан ук мәгълүм...» (ф. 732, оп. 1, д. 769, л. 8).

Хәзерге вакытта югары уку йортларында татар группалары оештырылды, укырга кергәндә, татарлар өчен ана телләрендә сочинение язу мөмкинлеге бирелде, күп кенә фәннәрне татар телендә укыту тәҗрибәләре барлыкка килде, башка милләт студентларына да татар теле өйрәтелә башлады. Болар барысы да — бүгенге көннең уңай күренешләре. Ләкин татар теле өйрәтү һәм фәннәрне татарча укыту өчен кадрларның һәм дәреслекләрнең җитмәве; югары уку йортларына бюджеттан 15% кына акча бүлеп бирелү; бигрәк тә русларга тел өйрәткәндә, татар теленә атнасына 2 генә сәгать вакыт бирелү; уку йортлары җитәкчеләренең бу эшкә бик

формаль караулары; күп факультетларда татар теленең телəгəннəр өчен генə укытылуы; студентларның татар телен өйрəнүне кирəксенмəүлəре дə — шулай ук бүгенге көн күренешлəре. Бу тискəре яклар нəкъ 20-30 нчы еллардагы кебек үк һəм, əйтерсең лə, 75 еллап вакыт эчендə берни дə үзгəрмəгəн.

3.3. Гыйльми үзәк (Академцентр) эшчәнлеге. 1918 елның май аенда Казанда үткəрелгəн Бөтенроссия мөселман укытучыларының өченче съездында Татарстанда беренче гыйльми оешма — Гыйльми һəйəт (фəнни коллегия) сайланып, аның каршында төрле бүлеклəр оеша: тел-əдəбият, тарих бүлеге, музей, театр һəм нəфис сəнгать бүлеге, мəктəплəр өчен программалар төзү бүлеге, матбугат бүлеге һ.б. (Хаков, 1985, б. 6). Соңрак Гыйльми һəйəт, исемен аз гына үзгəртеп, Гыйльми үзəк дип йөртелə башлый. 1921 елда, күп үзгəртүлəр соңында, ТАССР халык мəгарифе комиссары һəм сəркатибе тарафыннан төзелгəн гомуми нигезлəр кабул ителə. Бу нигезлəр буенча, Гыйльми үзəк Мəгариф комиссариатының фəнни, уку-укыту, агарту эшлəре һəм əдəби эшчəнлек белəн гомуми җитəкчелек итə, аның составына 4 комиссия керə: 1) фəнни-сəяси; 2) фəнни-техник; 3) фəнни-педагогик; һəм 4) сəнгать комиссиясе үзе 4 кечкенə комиссиягə бүленə: а) əдəбият; б) театр; в) музыка; г) сынлы сəнгать; д) кинематография. Гыйльми үзəк 5 кешедəн торган коллегия тарафыннан идарə ителə (ф. 3682, оп. 1, д. 59, л. 389).

Гыйльми үзəк 1922 елга кадəр оештырылу дəверен кичерə. 1922 елның 10 февралендə аның рəисе итеп Гаяз Максуд билгелəнə (ф. 3682, оп. 1, д. 76, л. 109). Гыйльми үзəк президиумы составына бу елларда Г.Максуд, фəнни-педагогик комиссия рəисе Г.Гобəйдуллин һəм гыйльми сəркатип Заһидулла Норкин (Нуркай) керəлəр. 1925 елның 16 февраленнəн алып, Гыйльми үзəк рəисе вазифасын Г.Ибраһимов башкара (ф. 3682, оп. 1, д. 690, л. 1). 1925 елның 7

апрелендә булган Гыйльми үзәк президиумы утырышында М.Корбангалиевкә фәнни-педагогик комиссия һәм нәшрият буенча эш алып барырга, Г.Ибраһимов булмаган вакытта, Гыйльми үзәк рәисе вазифаларын үтәп торырга тәкъдим итеЛә һәм бу хакта карар да чыгарыла (ф. 3682, оп. 1, д. 690, л. 24).

Гыйльми үзәкнең эшчәнлеге дәвамында аның составында күп төрле комиссияләр төзелә. Еллар үткән саен, бу комиссияләр юкка чыгалар яки исемнәрен генә үзгәртәләр, алар урынына яңа комиссияләр, җәмгыятьләр һәм бюролар барлыкка килә. Алдарак саналган 1921 елгы комиссияләрдән тыш, 1922 елның 18 мартында (ф. 3682, оп. 1, д. 410, л. 23) 2 редакцион комиссия (берсе — татар телендәге хезмәтләр өчен, икенчесе — рус телендәге), татар телендәге китапларның хисабын алу комиссиясе (Х.Бәдигый һәм Кулиев) һәм «Татар мәдәнияте тарихы»н төзү комиссиясе «Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, Г.Мансуров, Г.Ибраһимов, Х.Бәдигый) оештырыла. Татар редакция комиссиясенә 6 әгъза керә: Гаяз Максуд, Ф.Бурнаш, Г.Ибраһимов, Г.Максудов һәм Ф.Сәйфи (ф. 3682, оп. 1, д. 76, л. 177). Соңрак милли азчылык редакция комиссиясе дә оештырыла. 1923 елда фәнни-методик комиссия дә эшләве, Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте төзелүе мәгълүм (Отчет за время, 1923, с. 190). 1926-1927 елгы хисапларда инде Үзәк педагогия-методик комиссиясе, Татар мәдәнияте йорты хакында да сүз бара (ф. 3682, оп. 1, д. 1147, л. 65).

Гыйльми үзәк карамагында эшләүче комиссияләрнең гаять күп санлы булуына да карамастан, үзәкнең эшчәнлеге нигездә 3 төп юнәлештә алып барыла: 1) фәнни-педагогик; 2) редакция-нәшрият эшчәнлеге; һәм 3) туган якны өйрәнү эше.

3.3.1. Фәнни-педагогик эшчәнлек. 1922 елга кадәр барлык фәнни-педагогик эшләр Мәгариф комиссариатының төрле

бүлекләрендә һәм төрле юнәлешләрдә алып барыла. 1922 елның октябреннән исә Мәгариф комиссариатындагы барлык фәнни-педагогик, методик эшләр Гыйльми үзәк һәм аның составындагы фәнни-педагогик комиссия кулына туплана. Әлеге комиссиягә Мәгариф комиссариатының барлык бүлекләреннән дә вәкилләр керә, махсус эшләр башкарганда, күренекле педагоглар һәм югары уку йортлары профессорлары чакырыла (ф. 3682, оп. 1. д. 501, л. 76). Әһәмиятле һәм бәхәсле мәсьәләләр комиссия утырышларында, махсус секцияләрдә, конференцияләр һәм съездларда хәл ителә.

1925 елга кадәр фәнни-педагогик комиссия тарафыннан түбәндәге эшләр эшләнә: 1) барлык кантон мәгариф бүлекләрендә методик бюролар төзелә; 2) консультацияләр бюросы оештырыла; 3) 1 нче баскыч (4 еллык) мәктәпләр өчен программалар әзерләнеп, татар һәм рус телләрендә бастырып чыгарыла; 4) 2 нче баскыч (5 еллык) мәктәпләр өчен программалар төзелә һәм аларга күләмле аңлатмалар да языла; 5) 1 нче баскыч мәктәпләр өчен комплекслы система буенча программалар төзелә; 6) 2 нче баскыч мәктәпләр өчен өлешчә комплекслы программалар әзерләнә; 7) якшәмбе мәктәпләре, кантоннардагы кыска сроклы курслар программалары; 8) 2 нче баскыч рус мәктәпләре өчен татар теле программалары; 9) татар педагогия техникумнары өчен программалар; 10) ШКМнар өчен уку планнары һәм программалар; 11) укытучыларның белемен күтәрү курслары өчен уку планнары һәм программалар төзелә; 12) күп санлы методик кулланмалар, аңлатма язулары, методик хатлар күбәйтелеп таратыла (ВНОТ. — 1925. — №3. — С. 8).

Комиссия тарафыннан башкарылган эшләрнең дә иң әһәмиятлеләре булып төрле тип уку йортлары өчен программалар, уку планнары һәм дәреслекләр төзү мәсьәләсе санала. 20 нче еллар — элекке программа һәм дәреслекләрне кире кагып, яңаларын уйлап

табарга тырышу, эзләнүләр һәм бәргәләнүләр чоры. 1922 елның августына 1 нче һәм 2 нче баскыч мәктәпләр өчен яңа чорга туры килгән программалар эшләнеп бетеп, төрле фәннәр белән бергә, татар теленнән дә программа төзелсә дә (ф. 3682, оп. 1, д. 288 б, л. 264), ул елларда Мәскәүдәге ГУС (государственный ученый совет) программасына нигезләнеп, яңадан программалар төзү эшенә керешергә туры килә. ГУС программасы комплекслылык системасы буенча төзелә. «Аның үзенчәлеге — хезмәт процессларын укытуның нигезе итеп кую. Процесс иң элек гади примитив формасында өйрәнелә, аннан соң әкренләп катлаулана бара. Кешелек үсешенең төрле стадияләрендәге хезмәт процессларын өйрәнү физика, химия һ.б. фәннәр нигезендә алып барыла, шулай итеп, барлык предметлар бергә бәйләнә, комплекс барлыкка китерә һәм шуның белән ул предметлык системасыннан аерылып тора» (Третья сессия, 1926, с. 41). ГУС программасы буенча укуда һәм язуда күнекмәләр бик акрынлык белән, сочинениеләр язу, сөйләү, коллекцияләр төзү һ.б. аркылы барлыкка килә. Билгеле, мондый хәлне кабул итә алмаган ата-аналар һәм укытучылар, бигрәк тә авылдагылар, баштарак әлеге программаларга каршы чыгалар. Мәскәүдә 1925/26 уку елыннан комплекслы системага күчү башлана. Ләкин иң элек бу эш яхшы мәктәпләрдә генә тулысынча үткәрелә. 1925 елның маенда Мәскәүгә барып кайткан Г.Ибраһимов комплекслы система буенча төзелгән дәреслекләрнең, әзер схемаларның булмавы, хәтта кульязмалар да табып булмау хакында хәбәр итә. «Крупская рәислегендә коллектив төзелгән һәм дәреслекне июльгә тәмамларга уйлыйлар», — ди ул (ф. 3682, оп. 1, д. 690, л. 28). Татарстанда да әлеге үрнәк нигезендә программалар төзелергә тиеш була. Чыннан да, 1925 елның 8 июленә 1 нче баскыч мәктәпләр өчен татар һәм рус телләрендә

программалар әзерләнеп, редакцияләү өчен М.Корбангалиев һәм Линсцерга тапшырыла (ф. 3682, оп. 1, д. 690, л. 32).

1926/27 уку елыннан 1 нче баскыч мәктәпләрдә 1 нче һәм 2 нче уку еллары өчен ГУС программасы нигез итеп алына, ә Гыйльми үзәк программасы өстәмә методик кулланма буларак кына файдаланырга тиеш була. 3 нче уку елы өчен Гыйльми үзәкнең төзәтелгән һәм кыскартылган программасы кабул ителә, ни өчендер «Туган як» темасы мәҗбүри рәвештә кыскартыла. 4 нче уку елы өчен шактый кыскартулар белән ГУС программасы кабул ителә (ф. 3682, оп. 1, д. 1147, л. 66).

Моннан тыш, 1927 елга кадәр түбәндәге программалар эшләнеп, фәнни-педагогик комиссия тарафыннан раслана һәм бастырып чыгарыла: 1) җаваплы хезмәткәрләр өчен татар теле программасы; 2) совет учреждениеләре өчен татар теле; 3) 2 нче баскыч рус мәктәпләре, техникумнар һәм ФЗӨ мәктәпләре өчен татар теле программалары. Шулай ук 2 нче баскыч мәктәпләрнең соңгы ике елына педагогик уклон буенча уку планы төзелә (ф. 3682, оп. 1, д. 1147, л. 66).

Яңа программалар яңа дәреслекләр таләп итә. 20 нче елларда дәреслекләр күбесенчә коллектив авторлар тарафыннан иҗат ителә. 1920 елның 12 ноябрендә үк Татгосиздатның нәшрият бүлеге киңәйтелгән утырышында татар телендәге дәреслекләр төзү буенча коллектив оештырыла. Аның составына 6 күренекле галим: Г.Ибраһимов, М.Корбангалиев, Ф.Сәйфи, Г.Шәрәф, Х.Бәдигый һәм Г.Сәйфуллиннар кертелә. Аларның бурычы итеп булган дәреслекләр белән исәпләшмичә, бөтенләй яңа дәреслекләр төзү, моның өчен төп принцип итеп коммунистик хезмәт принцибын алу, ә милли һәм дини тенденцияләрне катгый рәвештә булдырмау куела (ф. 3682, оп. 1, д. 5, лл. 118-119). Шул вакыттан алып, әкренләп коллектив

тарафыннан да, аерым авторлар тарафыннан да татар телендәге дәреслекләр төзелә һәм бастырыла башлый. Мәсәлән, 1922 елның октябрь-ноябрь айларында Татар редакция коллегиясе тарафыннан Х.Бәдигыйның «Зурлар өчен әлифба»сы, дивар алфавиты, Г.Сәйфуллинның татар теленнән таблицалары, Харитоновның «Бүләк» исемле татар әлифбасы басарга дип кабул ителә (ф. 3682, оп. 1, д. 288 б, лл. 283, 310). 1922 елның октябреннән 1923 елның октябренә кадәр бер ел эчендә дә күп санлы дәреслекләр һәм уку планнары бастырыла. Алар арасында коллектив тарафыннан төзелгән «Ана теле дәресләре», «Әлифба», «Ана теленең гамәли сабаклары», «Балалар өчен татар әлифбасы», «Руслар өчен татар әлифбасы», «Җанлы сөйләм дәресләре (руслар өчен)», өч бүлектән торган уку китаплары, Ә.Максудиның руслар өчен «Татарстан» үзөйрәткече бар (ф. 3682, оп. 1, д. 501, л. 84).

1924 елда фәнни-педагогик комиссия ГУС программасы нигезендә 1925 елның көзенә 1 нче баскыч мәктәпләр өчен дәреслекләр төзү буенча конкурс игълан итә. Ләкин 1925 елның 16 февралендәге Гыйльми үзәк президиумы утырышында бу фикердән кире кайталар (ф. 3682, оп. 1, д. 690, л. 19). Г.Ибраһимов моның сәбәпләре итеп конкурс үткәрү өчен вакытның аз калганлыгын, икенчедән, татар педагогик көчләренең бик чикле булып, аларны бары планлы һәм билгеле бер бурычлар куеп эшләткәндә генә нәтиҗәгә ирешергә мөмкин икәнлекне күрсәтә (ф. 3682, оп. 1, д. 628, л. 77). Яңа дәреслекләр төзү өчен 19 кешедән торган зур коллектив оештырыла. Алар арасында М.Корбангалиев, Х.Бәдигый, Р.Газиз, З.Норкин, Г.Сәйфуллин, Г.Толымбайский, Линсцер, М.Фазлуллин, Г.Богданов, Х.Кәримов һ.б. бар. Коллектив эшенең шартлары итеп: 1) максимум гонорар бирү; 2) программа һәм фикерләрне — 15 мартка; 3) 1-2 нче уку елы өчен дәреслекләрне — 1 майга, 3 нче ел

өчен — 1 июньгә һәм 4 нче ел өчен 1 июльгә әзерләү куела. Коллективка файдалану өчен бердәнбер китап бирелә: «Освобожденный труд» хрестоматиясе (ф. 3682, оп. 1, д. 690, л. 19).

Шулай итеп, ул вакыттагы дәреслекләр баштанаяк үз чоры идеяләре белән сугарылган булалар, марксистик теорияне, хезмәт процессларын нигез итеп алалар. Бу чорда предметлык системасыннан баш тартып, русларның ГУС программасына иярү һәм комплекслы система буенча дәреслекләр төзү эше киң җәелә.

3.3.2. Редакция-нәшрият эшчәнлеге. Татарстан республикасында чыгарыла торган барлык китаплар, дәреслек-кулланмалар, уку-укыту характерындагы һәм фәнни хезмәтләр Гыйльми үзәк карап чыгып, раслаганнан соң гына бастырылалар, бары вакытлы матбугат, өлкә комитеты, ТҮБК, Халык комиссарлары советы һәм комиссариатларның махсус басмалары өчен генә Гыйльми үзәк рөхсәте таләп ителми (ф. 3682, оп. 1, д. 501, л. 79). Гыйльми үзәккә килгән барлык хезмәтләрне дә карап чыгу өчен, башта 2, аннары 3 редакция коллегиясе төзелә: татар, рус һәм милли азчылык телләрендәге китапларны карау өчен. Татар редакция коллегиясе эчендә тагын 8 коллектив һәм махсус комиссияләр эшли, алар ел саен нәшрият планнары төзиләр, бу планнарны үтәү өчен эшләрне бүлеп бирәләр, план буенча каралган хезмәтләрне яки өстәмә рәвештә килеп кергән әдәби әсәрләрне карап чыгып, редакцияләр (ВНОТ. — 1925. — №3. — С. 6). 1921/22 елларда Татар редакция коллегиясе татар телендә 36 исемдәге кульязма караган, шуларның 18ен басарга тәкъдим иткән. 1922/23 елларда бу күрсәткеч 79 һәм 49ны, 1923/24 елларда 139 һәм 102не тәшкил итә (ВНОТ. — 1925. — №3. — С. 7). 1924/25 еллар өчен кабул ителгән планда татар телендә 657 басма бит, моннан тыш, 87 стена таблицасы, рус телендә исә 122 басма бит күләмендә һәм 30 таблица

бастыру күздә тотыла (ф. 3682, оп. 1, д. 690, л. 11). Гыйльми үзәк хисабыннан күренгәнчә, бу план тулысынча үтәлә (Отчет 5-го созыва, 1926, с. 99; ф. 3682, оп. 1, д. 1148, л. 25). 1925/26 елларда планны күбәйтеп, татар телендә Мәгариф комиссариаты буенча 1515 басма бит, ә рус телендә 303 бит күләмендә әдәбият чыгарырга уйласалар да (ф. 3682, оп. 1, д. 1148, л. 134), татар типографияләренең техник шартлары начар булу, татар хәреф җыючыларының җитәрлек булмавы (ф. 3682, оп. 1, д. 1148, л. 135), хөкүмәттән дә, җирле бюджеттан да бернинди ярдәм алмау, машиналарның 70%ы тузып бетү (иң яңалары — 1914 елгы) нәтиҗәсендә (Третья сессия, 1926, с. 55), Татгосиздат китаплар бастыру буенча гаять зур кыенлыклар кичерә, планнарын үз вакытында үти алмый. Шулай да 1926 ел ахырына татар телендә 316 исемдә 1414 басма бит, ә рус телендә 191 исемдә 704 басма бит күләмендә әдәбият чыгарыла (Отчет 6-го созыва, 1927, с. 95).

20 нче елларда Мәгариф комиссариаты буенча чыгарылган әдәбиятның күпчелеген төрле тип мәктәпләр, техникумнар һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр, кулланмалар һәм уку ярдәмлекләре тәшкил итә, ә РКП(б)ның ТАССР өлкә комитеты линиясе буенча, билгеле, В.И.Ленин хезмәтләре, сәяси һәм икътисади характердагы әсәрләр, эшче-крестьян китапханәсе төп урынны алып тора (ф. 3682, оп. 1, д. 628, л. 76).

Гыйльми үзәк составындагы фәнни-педагогик комиссия караган һәм бастырырга тәкъдим иткән хезмәтләрнең күпчелеген татар телендәге китаплар тәшкил итә. Бу аңлашыла да, чөнки Татарстан республикасында яшәүче рус халкы ихтыяҗын нигездә гомумроссия масштабындагы басмалар канәгатьләндерә, ә Казан нәшриятына рус телендә җирле әһәмияткә ия булган, туган як, тюркология, татар белеме буенча хезмәтләрне, татар һәм рус мәктәпләре өчен уртак

программалар нигезендә төзелгән дәреслекләрне, Татарстанда яшәүче күренекле галимнәрнең китапларын бастыру эше кала. Шулай да Гыйльми үзәкнең рөхсәте таләп ителмәгән басмаларның күбесе рус телендә чыгарылу нәтиҗәсендә, Татарстан республикасында бастырылган китапларның күпчелеген ахыр чиктә рус телендәгеләр тәшкил итә (Отчет за время, 1923, с. 211).

Кулъязмалар тикшерү, редакцияләү, бастырырга рөхсәт бирү эшеннән тыш, Гыйльми үзәк тарафыннан журналлар да нәшер ителә. Аларның беренчесе — 1918 елдан бирле татар телендә чыгып килгән «Мәгариф» фәнни-педагогик журналы. 1922 елның 15 декабрендә булган Мәгариф комиссариаты коллегиясенең президиумы утырышында «Мәгариф» журналының редакция комиссиясенә Ф.Сәйфи һәм Г.Максуд кертеләләр (ф. 3682, оп. 1, д. 283, л. 107 об.). «Мәгариф» журналының шулай ук рус телендә дә чыгарылуы мәгълүм (Отчет за время, 1923, с. 212). Педагогика һәм методиканың теоретик һәм гамәли мәсьәләләре, татар теле һәм туган якны өйрәнү проблемаларын яктыртучы журнал 1938 елдан «Совет мәктәбе» исеме астында чыга башлый.

20 нче елларда Гыйльми үзәк кул астында чыгарылучы икенче басма — рус телендәге «Вестник просвещения» журналы. Аның редакторы итеп 1922 елның декабрендә Кочкарин билгеләнә (ф. 3682, оп. 1, д. 283, л. 107об.). Шулай ук бу елларда татар телендә иҗтимагый-сәяси һәм әдәби характердагы «Безнең юл» журналы да үзенең эшчәнлеген җәелдерә (Отчет к 5-му съезду, 1925, с. 123).

Гыйльми үзәк тарафыннан нәшер ителүче әлеге журналлар Татарстан республикасында гына түгел, СССР территориясендә яшәүче барлык төрки халыкларга да таратыла (Отчет за время, 1923, с. 211).

Татар телендә бастыру өчен төрле характердагы әдәбият әзерләгәндә, шулай ук, гомумән, татар телен дәүләт теленә яраклаштыру процессында, Гыйльми үзәк башта ук татар шрифты, орфографиясе, татар телендә фәнни терминология эшләү мәсьәләләре алдына килеп баса. Гыйльми үзәктә терминнар төзү буенча махсус комиссия оештырыла, аның кул астында «Татарстан» газетасы редакциясендә һәм Җир эшләре комиссариатының нәшрият бүлегендә дә комиссияләр эшли (ф. 732, оп. 1, д. 154, л. 20). Терминология комиссиясе тарафыннан 1921 елда атамалар хакында кабул ителгән төп нигезләрдә татар теленең нигез итеп алынуы, татарча терминнар булмаганда, татар әдәби теленә якынрак шивәләргә, ул да булмаганда, шәрекъ һәм гарәп телләренә мөрәҗәгать итәргә кирәклегенә, нигез итеп алыначак сүзләр арасыннан татар теленең аһәңенә, табигатенә һәм язуына якынрак булганнары сайланырга тиешлегенә басым ясала (Мәгариф. — 1927. — №10-11. — Б. 67). Шушы нигезләр буенча, Гыйльми үзәк тарафыннан атамалар эшләнә башлый, кайберләре «Мәгариф» журналында игълан ителәләр. 1922 елның октябренә терминология комиссиясе тарафыннан 1500 атама карала (ф. 3682, оп. 1, д. 288 б, л. 283).

«Мәгариф» журналының 1924 елгы март-апрель саннарында татар теле терминнары хакында Мәскәүдә булган тел-атама киңәшмәсендә Г.Ибраһимов тәкъдиме белән кабул ителгән 8 маддәлек карар урын ала, журналның май санында исә кайбер маддәләргә тагын да ачыклык кертелә. Әлеге карар буенча, Гыйльми үзәкнең атамалар турында 1921 елгы элеккеге нигезләре ныгытыла. Гарәп, европа һәм рус сүзләре хакындагы кайбер маддәләрне китереп үтик: «2) бер вакытларда татарчага кергән гарәп сүзләреннән телебезгә ят-кирәксез һәм килешсез булганнарын

йөртүдән саклanырга. Шулай да әдәби телебезгә яхшы урнашкан һәм аның табигатенә ябышып торган гарәп сүзләрен кирәк урыннарда кулланырга. Гарәпчәдән качам дип, гомуми урынына общий, сәнгать урынына искусство, хөкүмәт урынына правительство, дәүләт — государство, мәсьәлә-вазифа урынына задача, рәис урынына председатель йөртү шикелле мәгънәсезлекләрдән качарга; 3) чит телләрдән яңа сүзләр алганда, бәйнәлмиләл (интернациональ — З.К.) характерындагы сүзләргә әһәмият бирергә; 5) гыйльми сүзләрнең русчада да күбесенчә гарәпчәдән алган булып, русчада дистәләрчә, меңнәрчә гарәп сүзләре йөртелүен игътибарга алсак, чын русча сүзләр алуга зур хаҗәт калмаганлыгы күренә. Шуңа күрә читтән сүз алганда, ...русларның үзләрендә генә йөргән чын русча куллануда саклык күрсәтелер. Завод, союз, совет, волость, өяз һ.б. шикелле һәркем тарафыннан кабул ителгән һәм телебезнең табигатенә дә якын торган сүзләрдән башка нинди дә булса яңа бер русча сүз йөртелү тиеш табылса, бу турыда Гыйльми мәркәзгә мөрәҗәгать ителер».

Гыйльми үзәк атамалар турында шундый нигезләр игълан итсә дә, матбугатта кайбер атама аерымлыклары дәвам итә, бу бигрәк тә сәяси китаплар тәрҗемә итүчеләр белән газета сәхифәләрендә язучылар арасында сизелә. Матбугатта шушы рәвешчә атамалар буенча һаман да бердәмсезлекләр сизелүе нәтиҗәсендә, Гыйльми үзәк, элек чыгарылган карарларны һәм алынган тәҗрибәләрне игътибарга алып, 1925 елның 6 ноябрендә атамалар турында яңадан бер инструкция кабул итә. Бу инструкциядә Мәскәүдә кабул ителгән тезистагы русча сүзләр хакындагы томанлы 7 нче маддә урынына түбәндәге маддә эшләнә: «Матбугатта, әдәбиятта урынсыз сүзләрне куллануга каршы кискен чара күрергә тиешле. Бу кагыйдәдән тик түбәндәге урыннарда гына чигенергә туры килә: а) татарчасы

булмаган яки ясалма рәвештә төзелә алмаган, гарәпчәсе халыкка аңлашылмаган урыннарда рус сүзләре кулланырга (завод, пристань, пароход, поезд, самовар кебекләр); б) рус идарәсенә, рус тарихына каратылган рус сүзләре кулланылырга (өяз, земство, волость, князь, бояр, крестьян, дума, совет кебек) (Мәгариф. — 1927. — №10-11. — Б. 70).

Татар телендә терминнар төзү өчен кабул ителгән карарлар нигезендә, Гыйльми үзәк тарафыннан бик күп фәннәрнең атамалары төзелә һәм шул атамалар буенча бик күп дәреслекләр, гыйльми әсәрләр һәм фәнни-популяр китаплар мәйданга чыгарыла. Мәсәлән, 1927 елның ахырына кадәр ана теле, математика, физика, ботаника, гомуми биология, анатомия-физиология һәм идарә атамалары стеклография белән бастырылып таратыла; химия һәм зоология атамалары шул исемдәге китапларның азагында бастырыла; хокук атамалары исә Юстиция халык комиссариаты тарафыннан җыентык рәвешендә нәшер ителә. Бөтен фәннәрнең дә атамалары эшләнеп бетү белән, Гыйльми үзәк тарафыннан аерым атамалар сүзлеге әзерләнә (Мәгариф. — 1927. — №10-11. — Б. 70). Тагын шуны да өстәргә кирәк: Җир эшләре халык комиссариатының нәшрият бүлеге тарафыннан авыл көнкүрешенә кагылышлы атамаларның сүзлекчәсе бастырыла; авыл хуҗалыгы институтындагы татар студентлары оешмасы тарафыннан да күп кенә авыл хуҗалыгы атамалары, татар докторлары оешмасы тарафыннан медицинага кагылышлы атамалар җыйнала. Кыскасы, 1925 елның 17 сентябрендәге Гыйльми үзәк президиумы утырышында терминология мәсьәләләре белән шөгыльләнү эше тапшырылган Шнаси (ф. 3682, оп. 1, д. 690, л. 38) сүзләре буенча, 1927 елга кадәр «Гыйльми үзәкнең һәм татар гыйльми көчләренең тырышлыклары аркасында, 15 меңгә якын атама эшләнде, татар теле гыйлем теленә әйләнде» (Мәгариф. —

1927. — №10-11. — Б. 71). 20-30 нчы еллар дәвамында бер-бер артлы басылып чыккан төрле өлкәләр буенча терминологик сүзлекләр әлеге фикерне ачык дәлилли: Г.Габидов «Русча-татарча сәяси сүзлек» (1918); Г.Камал «Русча-татарча мөкәммәл сәяси лөгать» (1918); Г.Нигъмәти, С.Шәрәфетдинов «Сәяси лөгать» (1925); «Кыскача русча-татарча сугыш сүзләре» (1926); «Математика атамалары» (1927); Һ.Максудов «Фәнни камус (русча, гарәпчә һәм төркичә фәнни мәҗмугалар буенча тәгъриф кылынган фәнни, әдәби вә сыйнагый истыйлахлар камусы)» (1927); «Физика атамалары» (1927); «РСФСР кодексларында очрый торган атамалар лөгатьнамәсе» (1927); М.Гали «Газета укучыларның кесә сүзлеге» (1928); «Русча-татарча атамалар сүзлеге (физика, математика, астрономия буенча)» (1931); «Русча-латинча һәм татарча атамалар сүзлеге (кеше морфологиясе, анатомия, гистология)»(1931); «Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары» (1931); Г.Вәлитов «Химия атамалары» (1931); Г.Дистанов, Г.Вәлитов «Химия терминнары (русча-татарча сүзлек, Г.Камай редакциясендә. — 1934»); Х.Халиков һ.б. «Элементар математика терминнары җыентыгы» (1935); «Табигать һәм биология терминнары» (1938); «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге» (1939); М.Галиев, Х.Мөштәри, Х.Хөснуллин «Физика һәм метеорология терминнары» (1939); К.Кадыйров һ.б. «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге» (1939) һ.б.

Татар теле орфографиясенә реформа ясау мәсьәләсе буенча 10 елдан артык барган бәхәсләр дә 20 нче еллар башында күренерлек нәтиҗәгә китерә: 6 сузык аваздан торган орфография нигез итеп алына һәм бу татар халкы өчен шактый зур адым була (ф. 732, оп. 1, д. 154, л. 20). 1920 елның 1 декабренә Мәгариф комиссариатының фәнни бүлеге коллегиясе утырышында орфография төзү буенча

комиссия составы игълан ителә. Әлеге комиссиягә «Эшче», «Татарстан», «Кызыл Шәрекъ», «Кызыл армия» редакторлары, Татрост, Госиздат вәкилләре һәм 9 белгеч кертелә: М.Корбангалиев, Г.Ибраһимов, Г.Шәрәф, Х.Бәдигый, Г.Максуд, Г.Рәхим, Г.Динмөхәммәтов, К.Сәгыйтов, Г.Хәбидов (ф. 3682, оп. 1, д. 7, л. 14). 1920 елның 13 декабрендә Татарстан халык комиссарлары советы тарафыннан кабул ителгән декретның бер маддәсе татар теле орфографиясенең нигезе итеп 6 сузык авазны алу һәм нечкә сүзләрне калыннардан аеру өчен махсус билге кертү мәсьәләсенә багышлана (Сборник декретов и распоряжений, 1921, с. 81). Яңа орфография 1922 елда Татарстан республикасы буенча тулысынча урнашып бетә һәм әкренләп республикадан читтә булган татар вакытлы матбугатына да керә башлый (ф. 732, оп. 1, д. 154, л. 20).

Халык комиссарлары советының алдарак күрсәтелгән декреты нигезендә шулай ук татар шрифтына да реформа ясала. Элек һәр хәреф өчен 4 шәкел кирәк булса, хәзер исә ул башлангыч формада гына калдырыла (Сборник декретов и распоряжений, 1921, с. 81-82). Орфографиягә һәм татар шрифтына үзгәреш кертү язуда шактый уңайлык тудыра, грамотага өйрәнүне һәм типография техникасын җиңелләштерә. Реформалашкан шрифт шунда ук һәм тулысынча түгел, ә әкренләп кертелә: башта китапларның исемнәре, бүлек, мәкалә башлары һәм кайбер мәкаләләрдә кулланыла. Галимнәрнең фикеренчә, яңа шрифт нәшрият эшендә дә, педагогика өлкәсендә дә күп вакытка һәм акчага экономия ясауны вәгъдә итә (ВНОТ. — 1925. — №3. — С. 6-7).

Ләкин, билгеле булганча, 20 нче елларда күп кенә халыклар латин алфавитына күчәләр. Бу эшне азәрбайҗан галимнәре башлап җибәрәләр, күп кенә республикаларда әлеге тәкъдим хуплап кабул ителә. 1926 елның февралендә Бакуда төрки телле халыкларның

язуын латинлаштыру мәсьәләләренә багышланган I Бөтенсоюз тюркологлар съезды үткәрелә. Съезд эшендә Азәрбайҗан һәм Урта Азиянең союздаш республикалары делегацияләреннән тыш, автоном республика һәм өлкәләрнең вәкилләре, Мәскәү, Ленинград һ.б. шәһәрләрдән күренекле рус телче галимнәре һәм ориенталистлары катнаша. Барлык төрки халыкларның да делегацияләре гарәп графикасын латинга күчерү тәкъдимен керткәч, Г.Ибраһимов, Татарстан делегациясенең башлыгы буларак, моңа каршы чыга, латинга күчмәскә, гарәп хәрефләрен реформалау белән чикләнергә тәкъдим итә: «Без, Татарстан вәкилләре, гарәп хәрефләренә реформа ясау, шуның белән аны хәзерге заман техникасына ярату юлында булдык, — дип яза ул съезддан кайткач. — ... Башкаларның тәҗрибәсеннән ни нәрсә чыгар, аны киләчәк күрсәтер» (Ибраһимов, 1987, б. 274-275). Тюркологлар съездындагы доклады матбугатта чыккач, Г.Ибраһимов позицияләрен тәнкыйть итеп язылган мәкаләләр һәм җыелышларда чыгышлар шактый күп була. Шуларга җавап итеп, әдип күләмле генә өч мәкалә белән чыга һәм үзенең графика өлкәсендәге позициясен тагын да ачыклый, башкаларның һәм читләтеп кенә тюркологлар съездының принципиаль ялгышын ачып сала. Ул, графика алмаштыру элекке мирастан аерылу куркынычы белән бәйләнгән, халыкның иҗтимагый үсешен артта калдырырга мөмкин, ди (Ибраһимов, 1987, б. 348).

Билгеле, Г.Ибраһимовның латинлаштыруга мондый мөнәсәбәте гарәп графикасына мөкиббән китү белән бәйле түгел. Ул әле революциягә кадәр үк гарәп язуының татарлар өчен бик үк туры килеп бетмәве, зур кимчелекләргә ия булуы турында язып чыга. «Тарих агымы илә татарның муйнына тагылган гарәп хәрефләренең шул ничә йөз елдан бирле изеп килгән авырлыгы астында халкымыз ыңгырашмакта», — дип яза ул (Ибраһимов, 1987, б. 56).

Революциядән соң да Г.Ибраһимов тел һәм язудагы гарәп калдыкларын тәнкыйтьләп чыга. Ләкин ул гарәп алфавитын тулысынча алмаштыру өчен тиешле шартлар өлгереп җитмәгән дип саный. Татарстанның хәле дә башка төрки телле республикаларныкыннан аерылып тора. Мәсәлән, 1926 елгы мәгълүматлар буенча, халыкның грамоталылык дәрәҗәсе Азәрбайҗанда — 25,2%, Казахстанда — 22,8%, Кыргызстанда — 15,1%, Төркмәнстанда — 12,1%, Үзбәкстанда — 10,6% тәшкил итсә, Татарстанда исә халыкның 40%тан артыграгы гарәп алфавиты нигезендә укый-яза белә. Татар халкы гарәп язулы бай тарихи-әдәби мираска ия була (Хасанов, 1977, с. 299).

Күренгәнчә, Г.Ибраһимов административ чаралар куллану, латинлаштыруны ясалма тизләтү ягында булмый, халыкның аңлы рәвештә, өстән басым ясалмыйча бу яңалыкны кабул итүен тели.

Чыннан да, инде 1926 елның көзенә үк латинлаштыру хәрәкәте киң рәвештә җәелеп китә, бик күп тарафдарлар туплый. Казанда «Латин дусы» җәмгыяте үзенең эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. Конференциядән соң латин хәрефләре нигезендә төзелгән яңа татар әлифбасын тарату максаты белән «Яңалиф» җәмгыяте төзелә. Латинчылык идеясен тормышка ашыруда башта өлешчә, ә соңыннан тулысынча латин хәрефләре белән басыла торган «Яңалиф» журналы һәм атналык газета зур роль уйный.

Ниһаять, 1927 елның 3 июлендә Татарстан республикасы Халык комиссариатлары советы үзенең махсус карары белән латин алфавитын татар теленең рәсми алфавиты дип игълан итә. 1930 елның 1 гыйнварыннан башлап Татарстанда яңалиф йөз процент гамәлгә куелган дип исәпләнә.

Латин алфавиты нигезендәге орфографиянең төп принцибы итеп фонетик принцип алына. Орфография сузыкларда унчылык

нигезендә корыла. Башка телләрдән кергән сүзләр татарча әйтелешкә буйсындырыла. Бу язуның шактый кимчелекләре, җитешсезлекләре булуга карамастан, анда бирелгән орфографик кагыйдәләр татар әдәби телен нормалаштыруда зур роль уйныйлар.

30 нчы елларның ахырында исә рус әлифбасына күчү мәсьәләсе күтәрелә. Латинлаштырудан аермалы буларак, бу эш күбрәк өстән басым ясау юлы белән алып барыла. Рус алфавитына күчүнең кирәклеге болай аңлатыла: рус һәм татар телен өйрәнгәндә, рустан кергән сүзләрне русча язарга мөмкинлек туа, янәсе.

Рус графикасы нигезендәге яңа алфавитның беренче проекты 1938 елның август аенда игълан ителә. Проектта үзенчәлекле авазлар өчен бернинди өстәмә хәрефләр алынмый (Курбатов, 1960, б. 100). Билгеле, мондый хәл җәмәгатьчелекне канәгатьләндерә алмый. 1939 елда проектның тагын ике төрле варианты игълан ителә. Беренчесе профессор М.Корбангалиев редакциясендә чыга, һәм ул аеруча үзенчәлекле. Анда специфик авазлар өчен алты өстәмә хәреф алына: ә, ө, ү, ж, ң, һ. Нәтиҗәдә орфографиянең тартык һәм сузык авазлар язылышы бүлекләре өр-яңадан үзгәртелеп эшләнә. Къ, гъ авазлары аерым хәрефләр белән бирелмәгәнлектән, къара, къама, сакъ, гъадәт кебек сүзләрдә къ, гъ комбинациясе саклана яки кадер, кәгазь кебек сүзләрдә ә урынына а языла һ.б. Татар сүзләрендә w ярымсузыгы сүз башында в хәрефе белән алыштырылып (Вәли, ватан, вакыт), калган очракларда у-ү хәрефләре аша бирелә: тау — тауы, дәү — дәүе (Курбатов, 1960, б. 104).

Шул елны чыккан проектның икенче вариантында (төзүчеләре Ш.Рамазанов һ.б.) ярымсузык w авазы сүз башында гына түгел, иҗек башына туры килгәндә, сүз уртасында да в хәрефе белән языла: тавы, дәве, башлавы. Иҗек ахырында у-ү калдырыла: тау, дәү, киәү. Э хәрефенең сүз уртасында язылуы бетерелә: килүе, килүем. Калган

очракларда бу ике проект бер үк диярлек. Тик соңгысында кагыйдәләрнең параграфларга бүленеше һәм аларның формулировкалары гына уңышлырак. Татарстан АССР Югары Советы тарафыннан 1939 елның 5 маенда проектның шушы соңгы варианты раслана. Барлык мәктәп, техникум һәм югары уку йортларында яңа алфавит белән укыту 1939/40 уку елыннан башлана. Матбугат һәм учреждениеләр яңа алфавитка 1940 елның 1 гыйварында күчә (Курбатов, 1960, б. 105).

Яңа алфавит һәм орфография киң кулланылышка керү белән, тора-бара аның җитди кимчелекләре дә ачыла. Барыннан да бигрәк къ, гъ авазлары өчен аерым хәрефләр алынмау, я, ю, е хәрефләренең төрле-төрле авазларны белдереп, кайбер сүзләрдә аларның дөрес укылышы анык билгеле булмау, җ хәрефенең язылышында төгәлсезлекләр калу һ.б. орфография кагыйдәләрен яңадан карап чыгарга, аңа кайбер төзәтмәләр кертергә кирәклекне таләп итә (Курбатов, 1960, б. 105-106).

Бу мәсьәлә 1940 елның 5-9 июлендә Татарстан Мәгариф халык комиссариаты белән Татарстан тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты үткәргән грамматика һәм орфография фәнни конференциясендә карала. Өстәмәләр 1941 елның 10 гыйнварында раслана. Әмма моннан соң да әле орфографиядә җитди кимчелекләр кала. Мәсәлән, әдәби телдә булган къ, гъ фонемаларына аерым хәрефләр алмау белән киң җәмәгатьчелек һич тә килешә алмый. Я, ю, е хәрефләренә йөкләтелгән функцияләрнең артык киңәюе, в хәрефенең рус теленнән кергән в тартыгы өчен дә, татар телендәге w өчен дә йөрүе һәм нәтиҗәдә әдәби әйтелешне бозуга китерүе шулай ук уңай күренеш булмый (Курбатов, 1960, б. 106).

20-30 нчы елларда язулар алмашынуга бәйләнешле рәвештә орфографиягә һаман үзгәрешләр керә бара һәм алар кагыйдәләрдә

чагыла киләләр. 1927 елда күренекле тел галиме Г.Алпаров «Татар телендә имла сүзлеге»н төзеп бастыра. Шул ук елны сүзлек өч тапкыр һәм 1928 елда тагын бер кат басыла. 1928 елда И.Рәми төзегән «Имла сүзлеге» дә нәшер ителә. Латин язуына күчүгә бәйле рәвештә, Гыйльми үзәк 1931 елда «Татар теленең орфография сүзлеге»н әзерләп бастыра. Рус язуына күчкәч, 1939, 1941 елларда яңа орфографик сүзлек чыга.

Бу елларда аңлатмалы сүзлек өчен дә материал туплана башлый һәм Җ.Вәлидинең зур хезмәте дөнья күрә. «Татар теленең тулы сүзлеге» дип исемләнгән бу сүзлекнең ике томы гына (I том — 1927 ел, II том — 1928 ел) басылып чыгарга өлгерә.

Шулай итеп, 20-30 нчы елларда бер-бер артлы ике алфавит алыштырыла. Бу процесс, бер яктан, кыенлыклар китереп чыгарса да, икенче яктан, бигрәк тә 20 нче еллар, татар теленең вазифалары киңәю, аның беренче мәртәбә дәүләт теле дәрәҗәсенә менүе, мәктәпләрдә, кайбер югары уку йортларында ана телендә төрле фәннәр укытыла башлау, халыкның гомуми мәдәнияте үсү белән характерлана. Бу елларда тел фәнен үстерүгә зур өлеш керткән Галимҗан Шәрәф, Җамал Вәлиди, Хуҗа Бәдигый, Гыйбад Нугайбәк, Нигъмәт Хәким кебек күренекле телчеләрнең хезмәтләрен искә алып үтмичә мөмкин түгел. Нигездә әдәбият галимнәре, язучылар булсалар да, Г.Ибраһимов, Г.Рәхим, Г.Сәгъди, Ф.Сәйфи, Г.Толымбайларның да тел белеменә караган хезмәтләре бар.

3.3.3. <u>Татар дөньясын өйрәнү (Татароведение) фәнни җәмгыяте (НОТ) эшчәнлеге</u>.

1922 елда Казандагы Көнчыгыш Академиясе каршында, аның ректоры профессор Н.Н.Фирсов җитәкчелегендә Көнчыгышны өйрәнү җәмгыяте төзелә. Ләкин бу җәмгыять, артык зур максатлар кую сәбәпле, үзенең эшен тиешенчә җәелдерә алмый. Тиздән

Көнчыгыш Академия дә ябыла һәм Көнчыгышны өйрәнү җәмгыяте дә үзенең эшчәнлеген туктата. Ләкин бу җәмгыять нигезендә икенчесе төзелә: 1923 елның 30 маенда Гыйльми үзәк каршында Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте оештырыла (ВНОТ. — 1925. — №1-2. — С. 57). Җәмгыятьне төзүдә, бер яктан, Гыйльми үзәк, икенче яктан, Көнчыгышны өйрәнү җәмгыяте әгъзалары зур роль уйный, шулай ук Мәскәүдәге Гомумроссия Көнчыгышны өйрәнү фәнни ассоциациясе дә актив катнаша. 1927 елның көзенә кадәр җәмгыять Гыйльми үзәк карамагында эшли, ә күрсәтелгән вакыттан алып Татар мәдәнияте йорты кул астына күчә. Җәмгыять оешканнан алып, аның рәисе вазифасын рус тарихы буенча профессор Н.Фирсов башкара, сәркатипләр булып төрле вакытта М.Худяков, Е.Чернышев һәм Г.Рәхим эшли (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 201-202).

Җәмгыятьнең максаты итеп түбәндәгеләр куела: татарларны һәм татар мәдәниятен төрле яклап фәнни өйрәнү эше белән шөгыльләнүче белгечләрне бергә туплау, шулай ук бу өлкәгә кагылышлы мәсьәләләрне фәнни эшкәртү. Бу максатларны күздә тотып, җәмгыять үзенең бөтен халык алдында үткәрелә торган гомуми җыелышларында фәнни докладлар һәм белдерүләр тыңларга, экспедицияләр оештырырга һәм хезмәтләрен махсус журналда бастырырга тиеш була.

Баштарак җәмгыять татарларны өйрәнү өлкәсендәге үзенең бурычларын артык киң итеп куя: революцион хәрәкәт тарихы, археология, статистика, икътисад, халык хуҗалыгы, этнография, фольклор, лингвистика, әдәбият, археография һәм татар сәнгате. Моннан тыш, җәмгыять Татарстан республикасындагы татарларны гына түгел, ә СССР территориясенә таралган барлык Идел буе татарларын, хәтта өлешчә Тобол, Кырым һәм Литва татарларын да

өйрәнүне максат итеп ала. Әлеге саналган бурычлардан бары икътисад, халык хуҗалыгы һәм статистика гына җәмгыять эшендә тиешле урын тапмый, моның сәбәбе итеп җәмгыять әгъзалары арасында бу өлкәләр буенча татар белгечләренең бик аз санны тәшкил итүе һәм булганнарының да тиешенчә эшләмәве күрсәтелә. Шулай итеп, Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте үзенең эшчәнлеген татар халкының матди һәм рухи мәдәниятен төрле яклап өйрәнү нигезендә алып бара (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 201).

Шундый зур максатлар куйган Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте дә озын гомерле булып чыкмый: 1929 елның 3 ноябрендә ул Татарстанны өйрәнү җәмгыятенә кушыла (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 213). Алты ел ярым эшләү дәверендә җәмгыятьтә 4 идарә алмашына. Аларга төрле вакытта түбәндәге әгъзалар керә: Г.Рәхим, Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин, Г.Ибраһимов, М.Корбангалиев, Г.Максуд, Г.Шәрәф, Г.Сәгъди, М.Таһиров, М.Худяков, Н.Фирсов, Н.Воробьев, В.Егерев, В.Смолин, Е.Чернышев.

Җәмгыять әгъзаларының саны да елдан-ел арта барып, 1929 елга 98 кешегә җитә, шуларның 53е — татар, 39ы — рус милләтеннән (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 209). 98 кешенең 14ен почетлы әгъзалар тәшкил итә, араларында хәтта И.В.Сталин да була. Шулай ук А.Луначарский, профессорлар В.В.Бартольд, А.Ф.Баллод, И.Н.Бороздин, М.Н.Покровский, А.Н.Самойловичлар, ТҮБК рәисләре Р.Сабиров, Х.Габидуллин, Мәгариф халык комиссары булып эшләгән М.Ю.Борындыков, К.Р.Мохтаров (ВНОТ. — 1925. — №1-2. — С. 60) һәм күренекле галим Г.Ибраһимов (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 209) Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыятенең хөрмәтле әгъзалары булып сайланалар. Җәмгыятьтә 74 кеше гадәти әгъза һәм 10 кеше әгъза-хезмәткәр исәбендә тора.

Җәмгыятьнең аеруча актив эшчәнлеге 1925 елдан башлана. Нәкъ шул вакытта гомуми җыелышларның саны шактый арта, җәмгыять үзенең махсус органын чыгара башлый һәм фәнни экспедицияләр оештыра.

Үзенең барлык яшәеше дәверендә җәмгыять тарафыннан идарәнең 39 утырышы һәм шулай ук 39 гомуми җыелыш уздырыла, шуларның 7се рәисе шул ук Н.Фирсов булган Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте белән берлектә үткәрелә. Гомуми җыелышларда 65 фәнни доклад һәм чыгыш укыла. Докладлар белән 28 әгъза чыгыш ясый (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 202). Докладлар татар тарихы, этнографиясе, әдәбияты, теле һәм башка бик күп проблемалар буенча күренекле галимнәр тарафыннан ясала. Мәсәлән, алар арасында В.А.Богородицкийның «Төрки-татар фонетикасы», «Төрки телләрдә сингармонизм законы», Җ.Вәлидинең «Казан татарлары диалектлары», Н.Ашмаринның «Казан татарлары телендә исем җөмләләр», «Татар телендә сүз тәртибе», Г.Сәгъдинең «Татар әдәбияты үсешенең төп моментлары», Самойловичның «Татарстан республикасында туган якны өйрәнүнең бурычлары» кебек докладларны аерым күрсәтергә мөмкин. Моннан тыш, татар тарихы һәм этнографиясе буенча Г.Гобәйдуллин — 6 доклад, этнография буенча Н.Воробьев — 6 доклад, Г.Рәхим — М.Корбангалиевнең 30 еллык эшчәнлегенә багышлап, К.Насыйри хакында, халык медицинасы һ.б. буенча — 5 доклад, Г.Ибраһимов — Бакудагы I тюркология съезды хакында, М.Худяков — татар халкы тарихы буенча — 2 доклад ясыйлар һ.б. (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 203-205). Чыгышларның кайберләре җанлы фикер алышулар һәм бәхәсләр дә китереп чыгара. Җәмгыять шулай ук юбилей даталарын да билгеләп үтә: Пугачевны җәзалауның 150 еллыгы һәм Ленин үлеменә бер ел тулуга багышланган

җыелышларда Н.Фирсов, Е.Чернышев, Г.Гобәйдуллин һәм башкаларның докладлары тыңлана.

Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте Казан Кремлендә һәм Болгар хәрабәләрендә археологик казулар үткәрү эшен планлаштырган була, ләкин, акча булмау сәбәпле, бу идеяләр тормышка ашмыйча кала. Күбесенчә, зур чыгымнар таләп ителми торган теоретик, кабинет эшчәнлеген генә җәелдерергә туры килә.

Җәмгыять әгъзалары тарафыннан башкарылган эшләрнең аеруча әһәмиятлеләре: 1) М.Худяков Татарстан республикасының археологик картасын төзи; 2) Г.Гобәйдуллин тарафыннан туган якны өйрәнү буенча татар библиографиясен төзү эше тәмамлана; 3) җәмгыять рәисе Н.Фирсов Мәскәү һәм Ленинградка фәнни командировкасы вакытында Үзәк дәүләт архивында Идел буе татарлары тарихына кагылышлы материалларның копиясен ясатып алып кайта, нәтиҗәдә Нугай урдасы тарихына һәм XVI-XVII гасырларда Мәскәү-нугай мөнәсәбәтләренә багышланган зур кулъязма том Гыйльми үзәккә тапшырыла; 4) Г.Гобәйдуллин һәм Н.Воробьев, татарларның этнографиясен өйрәнү максаты белән, Татарстан кантоннарына чыгып китәләр (ВНОТ. — 1925. — №1-2. — С. 57-58). 1925-1929 елларда барлыгы 7 фәнни экспедиция оештырыла. Аларның барысы да фотограф белән берлектә уздырыла, нәтиҗәдә кызыклы күзәтүләр һәм фотодокументлар барлыкка килә (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 205-206); 5) Г.Гобәйдуллин һәм Е.Чернышев тарафыннан архив материаллары өйрәнелә; 6) Х.Бәдигый, халык иҗатын җыю эшен дәвам итеп, басар өчен берничә җыентык әзерли; 7) М.Васильев тарафыннан рус телендә татар әкиятләре җыентыгы чыгарыла һ.б. (ВНОТ. — 1925. — №3. — С. 9).

Җәмгыять эшчәнлегенең соңгы 4 елында аның махсус органы — «Вестник научного общества Татароведения» (ВНОТ) журналы чыгарыла. Журнал битләрендә җәмгыятьнең гомуми җыелышларында укылган әһәмиятле фәнни докладлар, шулай ук тикшеренү характерындагы аерым хезмәтләр дә урын ала. Журналның чыгып өлгергән 10 номерында барлыгы 70 фәнни мәкалә һәм 75 вак заметка, рецензия һ.б. материал бастырыла.

Үзенең басма органы ярдәмендә Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте СССР территориясендәге һәм чит илләрдәге 120 фәнни, укыту, гыйльми оешмалар һәм җәмгыятьләр белән регуляр бәйләнеш урнаштыра. Чит илләр арасында Берлин, Гамбург, Лондон, Рим, Харбин, Нью-Йорк һ.б. 10 шәһәр исеме билгеле (ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 206-207).

Шулай итеп, Гыйльми үзәк карамагында 5 ел эшләгән, ә соңгы 2 ел эшчәнлеген Татар мәдәнияте йорты каршында үткәргән Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте татар халкын төрле яклап өйрәнү буенча зур эш башкара, үзенең тирәсенә танылган галимнәрне, шул исәптән татарлар арасыннан күренекле белгечләрне туплый. Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте генә түгел, гомумән, Гыйльми үзәк тә үз тирәсенә татар хезмәткәрләрен туплау эшенә зур әһәмият бирә. Татарстан республикасыннан гына түгел, Башкортостан, Кыргызстан, Төркестан, Себер һ.б. өлкәләрдә яшәүче татар белгечләре дәреслекләр, брошюралар төзү эшенә, Казан вакытлы матбугатына актив катнаша башлыйлар (Отчет за время, 1923, с. 212). Г.Сәгъди, Г.Алпаров, Г.Шнаси, Н.Надиев кебек күренекле галимнәр чит өлкәләрдән Казанга чакыртып алыналар һәм Гыйльми үзәктә, шулай ук Казан уку йортларында уңышлы гына эшли башлыйлар (ф. 3682, оп. 1, д. 1148, л. 27).

3.4. Нәтиҗә ясап әйткәндә, 20-30 нчы елларда Татарстан Мәгариф комиссариаты һәм аның карамагындагы күп санлы комиссияләр, Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте һәм комиссариатның иң әһәмиятле бүлекләреннән берсен тәшкил иткән Гыйльми үзәк җитәкчелегендә республикада татар телен гамәлгә кую буенча гаять зур эш башкарыла: 1) комиссариат барлык төр уку йортлары өчен дә татар теле программалары, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре төзеп бастыра; 2) уку-укыту эшләре белән җитәкчелек итә; 3) уку йортларына татарларны күбрәк җәлеп итә башлый; 4) квалификацияле татар белгечләрен әзерләү һәм бергә туплауга зур әһәмият бирә; 5) татар телендә журналлар чыгара; 6) татар халкының телен, тарихын, мәдәниятен төрле яклап өйрәнү эшен оештыра һ.б.

## 4 бүлек. Кантон, волость һәм авыл советларында татар телен гамәлгә кую.

20-30 нчы елларда Татарстан республикасында өч төрле административ-территориаль бүленешне билгеләп үтәргә кирәк: кантон, волость һәм авыл советлары. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә кантон атамасының бер мәгънәсе «Татарстанда 1921-1926 еллардагы административ-территориаль берәмлек» дип бирелсә дә (2 том, б. 42), ТАССР Үзәк дәүләт архивы юл күрсәткеченнән күренгәнчә, кантон башкарма комитетлары 1920 елның сентябрендә төзелеп, 1930 елда гына район административ бүленеше белән алыштырыла (Центральный гос. архив, 1967, с. 98), шунлыктан соңгы төгәлрәк чыганакка таянып, кантоннарның Татарстандагы рәсми яшәеше 1920-1930 елларны эченә ала дигән фикергә килергә мөмкин. Шул ук вакытта аңлатмалы сүзлектә дә дөреслек чаткылары бар, чөнки 1926 елдан соң кантоннарның саны әкренләп арта бара, аларның исемнәре дә еш кына район атамасы белән бирелә башлый.

Кантоннардан кечерәк административ-территориаль берәмлекләр — волостьлар — 1917 ел ахырлары-1918 елның март айларында оешып, 1930 елда бу бүленеш юкка чыгарыла, волость башкарма комитетлары үз функцияләрен район башкарма комитетларына тапшыралар (Центральный, с. 102).

Иң кечкенә территориаль берәмлекне тәшкил иткән авыл советлары 1918 елның 2 декабрендәге карар нигезендә оештырылалар (Центральный, с. 107). Авыл советы атамасы, алдагы икесеннән аермалы буларак, озын гомерле булып чыкты һәм бары 1995 елда гына җирле үзидарә советы исеме белән алыштырылды.

Иң түбән совет оешмаларын тәшкил иткән авыл советлары һәм волостьларда ТТГК хакындагы беренче карар 1922 елның 8 маенда

чыгарыла. Әлеге карарда татар халкы күпчелекне тәшкил иткән авыл советлары һәм волостьларда, 1922 елның ахырыннан да соңга калмыйча, татар телендә эш башкаруны кертү кирәклеге ассызыклана (Сб., 1925, с. 8). Шул вакыттан алып даими рәвештә хөкүмәт карарларында кантон, волость һәм авыл советларында татар телен гамәлгә кертү хакындагы боерыклар да урын ала.

4.1. Авыл советларында ТТГК 1922 елдан башлана. Моңа кадәр хәтта чын татар авылларында да бөтен язу-сызу эшләре рус телендә алып барылырга тиеш була. Татар авыл советы рәисләре һәм сайланган әгъзалар гадәттә үз авылы кешеләре арасыннан билгеләнә һәм алар белән тел мәсьәләсендә каршылыклар килеп чыкмый. Ә эш башкаруны рус телендә алып барырга кирәк булганлыктан, квалификацияле һәм рус телен белгән авыл советы сәркатипләре һәм эш башкаручылары табуы зур кыенлык тудыра. Татарлар язу-сызу эшләрен тиешле тәртиптә алып бара алмыйлар, нәтиҗәдә аерым түләү хакына күрше рус авылларыннан сәркатип чакырырга туры килә. Русча язылган кәгазьләргә кул яисә «тамга» куйганда, кешеләр күпчелек очракта аның эчтәлеген дә аңламыйлар, моннан исә усал ният белән файдалану очраклары, төрле аңлашылмаучанлыклар да еш күзәтелә (За 5 лет, 1925, с. 40-41).

Ниһаять, 1922 елдан татар авылларында эш кәгазьләрен татарча алып бару мөмкинлеге туа. Татар телендә эш башкару беренче тапкыр кертелү, татарча терминнар һәм әзер формалар булмау сәбәпле, баштарак бары квалификацияле сәркатипләре булган яки бу эштә укытучылар катнашкан авыл советларында гына татар теле актив кулланыла ала (За 5 лет, 1925, с. 41). 1923 елда ТТГК Үзәк комиссиясе өчәр мең экземплярда авыл советларында һәм волость башкарма комитетларында эш башкару буенча инструкция һәм практик кулланмалар чыгара (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 36). Күп кенә

волость һәм кантоннарда авыл советы сәркатипләре өчен кыска сроклы курслар һәм аларны инструкцияләү үткәрелә (За 5 лет, 1925, с. 41).

Татарстан территориясендәге авыл советларының саны төрле чыганакларда төрлечәрәк бирелә, шулай да нәтиҗәләр ясаганда алар зур каршылыкларга китерми. ТҮБКның 2 нче сессиясендәге (1924 ел, 15-16 июнь) чыгышында ТҮБК һәм ТТГК ҮК рәисе Г.Ганиев түбәндәге саннарны китерә: 1924 елның 1 июненә Татарстандагы 2658 авыл советының 1222се татар була (моңа әле 128 керәшен авыл советы керми), шуларның 1000ендә (82%) эш алып бару тулысынча татар теленә күчерелә (Сб., 1925, с. 31). Күренгәнчә, барлык авыл советлары арасында татар авыл советлары 50,8%ны тәшкил итәләр һәм, ТҮБК карары буенча, аларда 1922 елның ахырына ук татар теле гамәлгә куелып бетәргә тиеш булса да, билгеләнгән вакытка аларның 20%ы гына эш башкаруны татар теленә күчереп бетерә ала. 1923 елда — 50%, 1924 елда — 82%, 1925 елда исә 85% татар авыл советлары татар телендә эш алып бара (За 5 лет, 1925, с. 41).

ТТГК Үзәк комиссиясе тарафыннан гел басым ясалып торса да, 1926 елда барлык татар авыл советларының 90%ы гына эчке эш башкаруны татар телендә урнаштырып бетерә. Калган авыл советлары бу эшне башкарырдай грамоталы белгечләрнең булмавын яки волость башкарма комитетлары белән язышуның русча алып барылырга тиешлеген сәбәп итеп күрсәтеп, үзләрен акларга тырышалар (Отчет 6-го созыва, 1927, с. 130). 1926 елдан соң авыл советлары эреләндерелә һәм 2658 урынына 2616 авыл советы калдырылып, шуларның 963ен татар авыл советы тәшкил итә. Бер чыганакта 1928 елга шуларның 98,5%ы татар телендә эш башкаруга күчеп беткән итеп күрсәтелсә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 14); икенче чыганакта, 1928 елның 5 июлендә бирелгән хисап буенча, 963 авыл

советының барысы да татар телендә эшләгәнлеге хәбәр ителә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 33). 1929 елгы мәгълүматларда авыл советларының саны тагын да азайтып күрсәтелә — 2115, шуларның 1017се татар булуы һәм барысының да татарча эш башкаруы билгеләп үтелә (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 34).

Шулай итеп, хәтта татар авыл советлары да бары 1928 елда гына эш алып баруны тулысынча татар теленә күчереп бетерә алалар, рус авылларында исә бөтен эш рус телендә калдырыла.

4.2. <u>Волостьларда ТТГК</u>. 1924 елга кадәр Татарстан территориясе 223 волостька бүлгәләнгән була. Артык ваклыгы, икътисади яктан уңышсыз бүленүе белән беррәттән, тагын ике зур кимчелек күзгә ташлана һәм алар ТТГК эшенә дә комачау итәләр: 1) волостьларның чикләре этнографик чикләр, ягъни теге яки бу телнең таралыш чикләре белән тәңгәл килми; 2) күпчелек татар волостьларының үзәкләре рус авылларына урнашкан була (Отчет к 5-му съезду, 1925, с. 21). Икътисади каршылыкларны гына түгел, тел ягыннан да мәсьәләне хәл итү максатында, волостьлар эреләндереләләр һәм нәтиҗәдә 125 волость барлыкка килә. Моңа кадәр бер телле волостьлар 22%ны алып торган булса, эреләндергәннән соң бу күрсәткеч 45%ка җитә (55 волость). Шулай ук татар халкының 8%ы гына рус волостьларында азчылык булып кала. Волость үзәкләренең 45%ы татар авылларына туры килә (элек — 32%) (За 5 лет, 1925, с. 42). Эреләндерелгән волостьтагы халык саны 15-25 меңне тәшкил итә, бер волостька уртача 20дән алып 35кә кадәр авыл советы керә (Сб., 1925, с. 52).

125 волостьның 81ендә (65%) татар халкы күпчелекне тәшкил итә, шуларның 50се, ягъни татар волостьларының 62%ы, 1924 елның 1 июненә эш башкаруны тулысынча татар теленә күчереп бетерә (Сб., 1925, с. 31).

1925 елгы мәгълүматлар исә 2 нче сессия нәтиҗәләреннән шактый аерылып тора. Мәсәлән, 5 нче съездга биргән хисабында Үзәк комиссия түбәндәгеләрне билгели: татар халкы күпчелекне тәшкил иткән волостьларның 48%ы барлык эшләрен татар телендә алып баралар; 29%ы, төп эш башкаруны татарча алып барса да, кайбер өлкәләр буенча (бигрәк тә салым һәм милиция өстәлләре) эшне рус телендә йөртәләр; 15%ында, татар авыллары белән мөнәсәбәтләре татарча урнаштырылса да, төп эш башкаруда нигездә рус теле сакланган; ниһаять, 8% татар волостьларында хәтта татар авыллары белән дә рус телендә эш йөртелә. Татар халкы азчылыкны тәшкил иткән волостьларга килгәндә, 19 волостьның 6сы гына (26%) татар телен пассив рәвештә гамәлгә керткән (Отчет к 5-му съезду, 1925, с. 23).

Волостьларның берсендә дә хәрби эш башкару татарчага күчерелми, шулай ук кайбер волостьларда гомуми канцелярия, салым, җир, ЗАГС, хисапчылык, милиция бүлекләре өлешчә генә татарчалаштырыла. Тулысынча татар теленә күчерелмәүнең сәбәпләре итеп татар волостьларында кирәкле хезмәткәрләрнең җитешмәве һәм түбән хезмәт хакы күрсәтелә (Отчет 6-го созыва, 1927, с. 31).

Ике телдә дә эш башкара алырлык белгечләрнең бик аз булуын исәпкә алып, ТТГК Үзәк комиссиясе 1923 елның гыйнвареннән үк Үзәк курслар карамагында волость башкарма комитетлары өчен хезмәткәрләр әзерләү циклы оештыра (ф. 732, оп. 1, д. 154, л. 19). Татарстан республикасының 3 еллык юбилеена, ягъни 1923 елның 25 июнендә, башка белгечләр белән бергә, волость сәркатипләре дә әзерләп чыгарыла (ф. 732, оп. 1, д. 262, л. 8). 1923 елда барлыгы 42, 1924 елда — 23, 1925 елда 38 волость сәркатибе һәм эш башкаручысы әзерләнә (За 5 лет, 1925, с. 44). 1924-1929 еллар өчен

перспектив планында Үзәк комиссия барлыгы 390 волость хезмәткәре кирәклегенә басым ясый: волость сәркатипләре — 60, эш башкаручылар — 180, хисапчылар — 70 һәм волость милиция башлыклары — 80. Моннан тыш, татарча шрифтлы язу машинасында эшли белүче 80 машинистка да таләп ителә (Сб., 1925, с. 52).

1928 елгы мәгълүматлар буенча, волостьларның гомуми саны 116га гына калган һәм шуларның 66сында татар халкы күпчелекне тәшкил итә. Хәрби һәм салым эшләреннән кала, төп эш башкару 66 волостьта да татар телендә алып барыла (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 33).

Кыскасы, волостьларда да, авыл советларындагы кебек үк, ТТГК процессы ике моментны үз эченә ала: 1) татар халкы күпчелекне тәшкил иткән волостьларда татар теле актив кулланылышка кертелә, ягъни төп эчке эш башкару татар телендә урнаштырылып, рус азчылыгы өчен телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрне кабул итү һәм аларга җаваплар бирү рус телендә тәэмин ителә; 2) татар халкы азчылыкны тәшкил иткән волостьларда татар теле пассив кулланылышка кертелә, ягъни төп эш башкару рус телендә алып барылып, татарлар белән аңлашу татар телендә булдырыла (Сб., 1925, с. 51).

4.3. <u>Кантоннарда ТТГК</u> эше белән кантон башкарма комитетлары (КБК) һәм кантон ТТГК комиссияләре җитәкчелек итә. Канткомиссияләрнең төп нигезләре ТҮБК тарафыннан 1922 елның 13 маенда игълан ителә. ТҮБК рәисе урынбасары Казаков һәм сәркатип Петров кул куйган әлеге карар 6 маддәдән тора һәм түбәндәгеләрне эченә ала: 1) барлык кантон башкарма комитетларында 1922 елның 15 июненнән дә соңга калмый кантон ТТГК комиссияләре төзелергә, аның составына КБКдан, Юстиция комиссариатыннан һәм идарә бүлегеннән берәр вәкил керергә тиеш

була; 2) канткомиссиягә кантондагы барлык учреждениеләрдә ТТГК эше белән җитәкчелек итү, хөкүмәтнең бу өлкә буенча чыгарган карарларының үтәлешен тикшерү, Үзәк комиссиянең күрсәтмә һәм боерыкларын үтәү, кантонның үзенчәлекләрен күздә тотып, ТТГК буенча конкрет чаралар үткәрү бурычлары йөкләнә; 3) канткомиссиянең беркетмәләре кантон башкарма комитеты тарафыннан раслана; 4) канткомиссиянең карарлары кантондагы барлык учреждениеләр өчен мәҗбүри итеп куела һәм бары тик КБК һәм ТҮБКга гына жалоба бирергә мөмкин була; 5) кантон комиссияләре һәр ай саен Үзәк комиссиягә барлык утырышларының беркетмәләрен, үзләренең эшчәнлеге хакында хисаплар, кантонда ТТГКның гомуми торышы һәм очраган каршылыклар хакында мәгълүмат биреп торырга тиеш булалар; 6) канткомиссияләрнең үз канцелярия аппаратлары булмый һәм алар КБК аппаратыннан файдаланалар (Сб., 1925, с. 9-10).

Күренгәнчә, канткомиссияләр кантонда зур хокукка ия булалар. КБК канткомиссия карарын расларга теләмәгән очракта, комиссия ТТГК ҮК аша ТҮБКга мөрәҗәгать итә ала (ф. 732, оп. 1, д. 154, л. 15).

Карарда билгеләнгән вакытка — 15 июньгә — барлык кантонда да комиссияләр төзелеп бетмәсә дә, Үзәк комиссия хисабыннан күренгәнчә, бу эш июнь-июль айларында эшләнеп бетә. Мәсәлән, Арча һәм Чистайда — 15 июньдә, Чаллы һәм Минзәләдә — 20 июньдә, Мамадыш һәм Спаста — 8 июльдә, Буада 12 июльдә комиссияләрне төзү тәмамлана (ф. 732, оп. 1, д. 154, лл. 15-16).

Үзәк комиссия кантоннарда комиссияләрнең төзелүен шулай тиз һәм җиңел генә булган вакыйга итеп күрсәтсә дә, вакытлы матбугатта еш кына тәнкыйть сүзләре дә әйтелә. Мәсәлән, «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елның 4 сентябрь санында

комиссияләрнең бары берничә кантонда гына төзелеп, кайбер кантоннардан бернинди хәбәр дә килмәве, ә Тәтеш кебек кантоннарның «татар эшчеләренә мохтаҗлык зур булу аркасында, комиссия төзегәнебез юк әле» шикелле җавап белән генә канәгатьләнүләре билгеләнә (Татарстан хәбәрләре. — 1922. — 4 сентябрь).

Кантон комиссияләрендә, 3 әгъзадан тыш, Үзәк комиссия тарафыннан финанслана торган берәр инструктор да эшли (Отчет к 5-му съезду, 1925, с. 24). Инструкторлар, волость һәм авыллар буйлап йөреп, кантонда ТТГК эшенең торышын тикшерәләр. Шул ук вакытта инструкторларны башка эшләргә кушу, бигрәк тә аларның хезмәтен тәрҗемә итүгә генә кайтарып калдырырга омтылу очраклары да күзәтелә (Сб., 1925, с. 73). Җитмәсә, аларга хезмәт хакы да бик аз түләнә һәм анысы да үз вакытында бирелми. Мәсәлән, Мамадыш кантоны инструкторына 1924 елның июле өчен 16 сум 66 тиен түләнгән (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 104), ә Үзәк комиссия инструкторы Хәмзинга 85 сум 38 тиен хезмәт хакы түләнүе мәгълүм (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 290). Нәтиҗәдә тәҗрибәле инструкторлар эштән китәргә мәҗбүр булалар, ә аларга алмаш табуы бик авыр була. Мисал өчен, Чистай кантоны инструкторы 1924 елның июлендә алга таба эшләүдән баш тарта, чөнки ул инде апрель аеннан бирле хезмәт хакы ала алмый (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 104). Башка юл калмагач, кантон үз исәбеннән аңа июль өчен 15 сум хезмәт хакы түли (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 99).

Кантинструкторлар кантоннарда татар телен гамәлгә кертүдә әһәмиятле урын тоталар, үз эшләрендә килеп туган каршылык һәм проблемаларны хәл итү өчен, әледән-әле Казанга җыелып, киңәшмәләр уздыралар. Мәсәлән, 1925 елның 12 мартындагы киңәшмәдә кантоннарда татар телен гамәлгә куюның барлык

якларын да эченә алган 28 карар кабул итәләр. Бу карарлар 1925 елның 17 апрелендә Үзәк комиссиянең утырышында расланалар. Карарлар арасында канткомиссияләрнең составын 5 кешегә җиткерү хакындагы тәкъдим дә урын алган (Сб., 1925, с. 71). Чыннан да, 1925 елның 4 апрелендә кабул ителгән ТТГК комиссияләре нигезләрендә кантон комиссияләре 5әр кешедән торырга тиеш дип бирелә (Сб., 1925, с. 28): комиссия рәисе булып КБК рәисе яки аның урынбасары, әгъзалар булып кантонның оештыру бүлеге мөдире, ТТГК инструкторы, мәгариф бүлегеннән һәм профорганнардан берәр вәкил сайлана (Сб., 1925, с. 71). Киңәшмәдә шулай ук үзәк учреждениеләр һәм комиссариатларның кантоннарга җибәргән һәм волостьларга таратылырга тиешле барлык циркуляр һәм карарлары рус һәм татар телләрендә булу да таләп ителә. Әлеге мәҗбүриятнең төп нигезләре ТҮБКның элегрәк чыгарылган карарларында да чагылыш тапкан була. Мәсәлән, 1923 елның 24 ноябрендә булган ТҮБК президиумы утырышында барлык үзәк һәм кантон учреждениеләренең татаравыл советларына юнәлдерелгән инструкция һәм карарларын кантон һәм волость башкарма комитетларына татар теленә тәрҗемәсе белән дә җибәрергә тиешлекләре ассызыклана. Кантон һәм волость башкарма комитетларыннан да үз чиратларында карарларын татар авылларына татар телендә җибәрү таләп ителә (ф. 732, оп. 1, д. 139, л. 4). Беренче карашка киңәшмәдә кабул ителгәннән аерылып торган кебек тоелса да, бу ике карарның нигезләре бер үк. ТҮБКның 1924 елның 30 апрелендәге карарында да нәкъ шул боерык яңадан кабатлана (Сб., 1925, с. 18). Ләкин, киңәшмәдән аңлашылганча, ел саен кабатланып торган бу карар 1925 елда да тиешенчә тормышка ашырылмый.

ТҮБКның 1924 елның июнендә булган 2 нче сессиясендә ҮК рәисе Г.Ганиев татар теле канәгатьләнерлек дәрәҗәдә гамәлгә

куелган 7 кантон исемлеген китерә: Арча, Чаллы, Мамадыш, Бөгелмә, Буа, Минзәлә һәм Тәтеш (Сб., 1925, с. 31). Бу кантоннарның уңай яктан бәяләнүе табигый да, чөнки Татарстандагы 12 кантонның нәкъ шул 7сендә татар халкы күпчелекне тәшкил итә (76-55%), калган 5 кантонда исә: Лаеш, Алабуга, Зөя, Спас һәм Чистайда татар халкы 49-35%ны алып тора (Сб., 1925, с. 82-86). Баштарак барлык кантон учреждениеләрендә дә татар телен пассив рәвештә генә гамәлгә кую бурычы куела (Отчет 5-го созыва, 1926, с. 47), ягъни төп эш башкаруны рус телендә калдырып, бары язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрне генә татар телендә кабул итү һәм аларга татарча җавап бирү. Ләкин кантоннарның татар волостьлары, авыл советлары һәм халык белән аралашуы һәм язышуның татар телендә булырга тиешлеге хакында 1924 елның 30 апрелендә чыгарылган ТҮБК карары (Сб., 1925, с. 18) татар телен пассив гамәлгә кертү идеясен юкка чыгара. ТТГК буенча 5 еллык перспектив планда да 1925-1926 елларда татар халкы күпчелекне тәшкил иткән 7 кантондагы КБК, җир эшләре, мәгариф, милиция бүлекләрендә һәм кооператив органнарда татар телендә эш башкаруны булдырып, 1926-1927 елларда исә барлык бүлекләрдә дә татар телендә эш йөртүгә күчү хакында сүз бара, ягъни актив ТТГК күздә тотыла. Калган 5 кантонда татар хезмәткәрләренең саны 1927 елга 40%ка җитәргә тиеш дип табыла (Сб., 1925, с. 58).

Кантон башкарма комитетларындагы һәм тулаем кантоннардагы татар хезмәткәрләренең саны елдан-ел арта бара. Мәсәлән, КБКларда татар хезмәткәрләре: 1921-1922 елларда — 34,3%, 1922-1923 елларда — 41,4%, 1923-1924 елларда 51,7%ны тәшкил итә (За 5 лет, 1925, с. 42).

Татар хезмәткәрләренең саны әкренлек белән булса да арта, ә 7 кантонда тулысынча татар телендә эш башкаруга күчү исә

билгеләнгән вакытка үтәлә алмый. 1927 елның 12-13 мартларында булган ТҮБКның 3 нче сессиясендә Үзәк комиссия һәм ТҮБК рәисе Х.Габидуллин бу турыда пессимистик рухта сөйли: 1925-1926 елларда гына түгел, хәтта 1926-1927 елларда да әлеге эшнең тормышка ашмаячагын, бары татар халкы 70%ны алып торган Минзәлә һәм Мамадыш кантоннарында гына 1927 ел ахырына, бәлки, үтәргә мөмкин булыр дип билгели. Төп каршылык итеп квалификацияле татар хезмәткәрләренең булмавын күрсәтә (Доклад, 1927, с. 13). ТТГК буенча кантоннар 4 категориягә бүлеп бирелә һәм мәгълүматлар 1924 елдагыдан шактый аерыла. ТТГКның торышы ягыннан уртачадан югары категориягә Арча, Чистай, Чаллы, Бөгелмә кантоннары, урта категориягә Мамадыш, Буа, Минзәлә кантоннары, уртачадан түбән категориягә Спас, Зөя кантоннары керә, бөтенләй начар хәлдә итеп Лаеш һәм Алабуга кантоннары күрсәтелә (Доклад, 1927, с. 12). Тәтеш кантоны ни өчендер төшереп калдырылган.

1928 елгы мәгълүматлардан да татар халкы күпчелекне тәшкил итүче кантоннарның татар телендә эш башкаруга күчеп бетмәгәнлекләре аңлашыла. Бары Арча, Мамадыш һәм Минзәлә кантоннарында гына төп бүлек һәм учреждениеләрдә татар телендә эш йөртә башлаулары һәм инде нәтиҗәләр күренүе билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 15). Бу кантоннарның башкарма комитетлары, мәгариф, администрация, юстиция һәм җир бүлекләре татар волостьлары һәм авыллары белән язу эшләрен татарча алып баралар. Татарстан республикасындагы 117 суд-тикшерү участогының 43е татар районнарында урнаша һәм аларда утырышлар һәм хөкем эшләре татар телендә алып барыла. Хәрби эш башкару барлык кантоннарда да рус телендә генә йөртелә. Финанс бүлекләре дә

кантон, волость һәм үзәк учреждениеләр белән язышуны нигездә рус телендә алып баралар (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 34).

Күренгәнчә, хәтта татар халкы күпчелекне тәшкил иткән 7 кантонда да татар телендә эш башкаруга тулысынча күчеп бетә алмыйлар, калган 5 кантонны исә тора-бара бөтенләй искә дә алмый башлыйлар. Кантоннарда ТТГК хакындагы мәгълүматлар нигездә 20 нче еллар буенча гына бирелә, кантоннарны районнарга әйләндерү, колхозлашуның киң колач алуы әлеге мәсьәләне читкәрәк этәрә. Шунлыктан алга таба һәр кантонда ТТГКның торышы хакында кыскача биреләчәк мәгълүматлар нигездә 20 нче елларны эченә ала. Кантоннарга күзәтү ясаганда, аларның урнашу тәртибе татар телен гамәлгә куюдагы урыннары ягыннан түгел, ә кантоннар арасында татар халкының саны буенча тоткан урыннары ягыннан билгеләнде.

4.3.1. Минзәлә кантонында татар халкы иң зур күпчелекне тәшкил итә: 1925 елгы мәгълүматлар буенча, волостьларда татарлар 78,8%ны, Минзәләнең үзендә — 15,7%ны, ә барлык кантон буенча 76,3%ны алып тора (Сб., 1925, с. 84). Минзәлә кантонында волостьлар эреләнгәнче барысы 16 волость булган, шуларда татарлар 83% булып, руслар 17%ны тәшкил иткән (ләкин татар хисабына татарча белгән башка милләт кешеләре дә кертелгән) (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 120).

1924 елдан соң кантонда волостьларның саны 9га кала. Шулардан 7сендә барлык халыкның 75тән алып 99%ка кадәресе татар, калган 2 волостьта татарлар, бер чыганак буенча 25-30% (ф. 732, оп. 1, д. 791, л. 22), икенчесендә исә 30-49% дип күрсәтелә (Сб., 1925, с. 78). Димәк, Минзәлә кантонында татар телен гамәлгә куйганда, бөтен волостьларда да татарча эш башкаруга күчәргә кирәк булып чыга. Кантонның үзеннән җибәргән хисаплардан күренгәнчә, ТТГК эшләренең бигрәк тә күзгә күренеп алга китүе

волостьлар эреләнгән вакыттан башланып китә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 120). 7 волость башкармасында эчке эш алып бару (хисап йөртү һәм хәрби эшләрдән башка) саф татар телендә алып барыла. Кайбер волостьларда хисап кенәгәләрен дә татарча йөртергә тырышалар, шулай да бу эш әле тулысынча башкарылып бетми. Бөтен волость башкармаларының әгъзалары 69 кеше булып, шуларның 49ын татарлар тәшкил итә. Волость башкарма рәисләре вазифасын да 2сендә генә рус, ә 7сендә татар кешесе башкара (ф. 732, оп. 1, д. 791, л. 22).

Кантонда татар халкын гына эченә алган 137 авыл советы булып, боларда эчке эш йөртү татар теленә күчерелеп бетә. Аннан башка рус, керәшен һәм татарларның 14 катнаш советлары була, аларның кайберләрендә эш русча гына, кайберләрендә ике телдә куела (ф. 732, оп. 1, д. 791, л. 48).

Кантон учреждениеләрендә татар телен куллану буенча төрлелек хөкем сөрә. Шуларның кайберләренә тукталып үтик.

Кантон башкарма комитетында циркулярлар, карарлар, еллык хисаплар һәр ике телдә языла. Башкарма сәркатибе эшне русча да, татарча да алып бара. Аппаратта бөтенләй татарча язу танымаган кеше 2-3 кенә була. Тик бер генә каршылык күзәтелә: татарча язу машинасы булмау сәбәпле, волостьлар белән мөнәсәбәт русча тәэмин ителә (ф. 732, оп. 1, д. 791, л. 22).

Кантон башкармасының бүлекләрендә исә, татар теле беркадәр гамәлгә кертелсә дә, канәгатьләнерлек булмый. Бары суд һәм тикшерү оешмаларын, мәгариф бүлеген генә уңай яктан аерып алып әйтергә мөмкин. Мәсәлән, кантонда 5 халык хөкеме участогы булып, шуларның 3сендә эчке эш йөртүләр татарча алып барыла, калган 2сендә дә, судьялары татарча сөйләшә белгән һәм сәркатипләре татарча эшли алганлыктан, татар теле тәэмин ителә. Прокурор

ярдәмчесе һәм сәркатибе булып татарлар эшли, бөтен тикшерүчеләр дә татарча сөйләшә беләләр — димәк, тикшерү участокларында да татар теле яхшы куела (ф. 732, оп. 1, д. 791, л. 22).

Финанс бүлегендә исә татарча белүче эшчеләр җитәрлек булмый, волостьлар белән мөнәсәбәт тә рус телендә алып барыла. Комиссия финанс бүлегенә кирәкле татар эшчеләрен таба алмыйча аптырый (ф. 732, оп. 1, д. 791, л. 22).

Кантон учреждениеләре арасында иң начар татарлаштырылганнары итеп сәламәтлек саклау, кооператив һәм почта-телеграф оешмаларын күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, сәламәтлек саклау бүлегендә бер генә татар эшли, докторлар арасында татарча яхшы белүчеләр бөтенләй булмый, фельдшерларның да 2-3е генә язу таный. Хастаханәләрдә хезмәт итүче татарлар да бик аз санны тәшкил итәләр. Квалификацияле татарлар гомумән булмыйча, татарлар хәтта сиделкалыкка да кермиләр (ф. 732, оп. 1, д. 791, л. 22). Почта-телеграфларда да татар телен үткәрү бик кыенлык белән бара, бары күчмә почталарда гына хат ташучылар арасында татарлар булып, Минзәләдәге район почта-телеграф конторасында исә бер генә татар эшли (ф. 732, оп. 1, д. 791, л. 20 об.).

Минзәлә кантонында ТТГКның торышын тикшергән ҮК инструкторы Хәмзин кантонда татар эшчеләре хәзерләү мәсьәләсенең бик начар куелуын, руслар өчен татар теле курсларының бернинди нәтиҗә бирмәвен, канткомиссиянең мәркәз белән мөнәсәбәте йомшак булуын билгели (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 100).

4.3.2. Мамадыш кантонындагы волостьларда татар халкының саны 69,8%ны, ә Мамадыш шәһәре белән бергә 69,2%ны тәшкил итә (Сб., 1925, с. 84). Кантонда 9 волость булып, шуларның бары

бирсендә генә татарлар 8,8% белән исәпләнә, калганнарының исә 3сендә 93-99%ны, 5сендә 54-81%ны алып тора (Сб., 1925, с. 78).

Мамадыш кантонында ТТГК эшләре барлык хисапларда да уңай яктан гына бәяләнә. ҮК инструкторы Хәмзин хәтта: «Мамадыш кантонының волостьлары татар телен гамәлгә куюда Татарстанда беренче урынны алдылар», — дип белдерә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 124). Кантон комиссиясе дә, башка кантоннар белән чагыштырганда, аеруча зур бер энергия белән эшли, ай саен рәттән Үзәк комиссиягә хисаплар тапшыра. Кантондагы учреждениеләр татар волостьлары өчен кирәкле булган эш йөртү, касса, керем-чыгым, ЗАГС дәфтәрләрен татар телендә эшләтеп, волостьларга тараталар. Кантон оешмаларының татар волостьлары белән бөтен мөнәсәбәтләре татарча тәэмин ителә. Авыл һәм волость советы эшчеләрен хәзерләү өчен курслар ачыла. Канткомиссия тарафыннан Казандагы Үзәк курсларга һәр наборда сораган кадәр кешеләр җибәрелеп бара, димәк, кантонда татар эшчеләре җитештерү мәсьәләсе дә шактый хәл кылына (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 124).

Кантон инструкторы Рәхмәтуллинның үз эшен бирелеп һәм тырышып башкарганы күренеп тора. Ул һәр ай саен кантондагы волость һәм авылларны йөреп чыгып, аларда ТТГКның торышын җентекләп тикшерә, эш нәтиҗәләрен, айлык хисапларны төгәл рәвештә һәм үз вакытында Үзәк комиссиягә җибәреп бара. Аның хисапларында эштә килеп туган каршылыклар да чагылыш таба. Мәсәлән, кантонның финанс бүлегендә баштарак ТТГК эше яхшы гына юлга салына башлый, чөнки монда эшләүче татар эшчеләренә һәртөрле тәрҗемәләр өчен вазифаларыннан тыш өстәмә түләү бирелеп бара. Ләкин Финанс комиссариаты бу чарага рөхсәт бирми, нәтиҗәдә татар эшчеләренә өстәмә түләү, штаттан тыш өйрәнчекләр алу туктала. Финанс бүлегендә генә түгел, башка оешмаларда да

тәрҗемә эше бик күп җыела, чөнки русча язылган кәгазьләрне татар волостьлары кабул итмиләр, яллап тәрҗемә иттерергә оешмаларның акчалары булмый. Ахыр чиктә кәгазьләрне кантон ТТГК комиссиясенә җибәрәләр, ләкин комиссия дә ул эшне өстенә ала алмый (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 102).

Шулай итеп, Мамадыш кантоны 20 нче елларда ТТГК буенча иң алда торган кантоннардан санала. Ләкин монда да эшләр каршылыксыз гына бара алмый. Бигрәк тә Мамадыш шәһәрендә русларның ризасызлык белдерү очраклары күзәтелә. Рәхмәтуллинның 1924 елның 11 февралендә Үзәк комиссиягә язган хосусый хатыннан һәм хисабыннан китерелгән өзекләр әлеге хәлне ачыграк күз алдына китерергә ярдәм итәр (тексттагы сүзләр үзгәртелмәде — З.К.): «ТТГК комиссиясенең эшләре шәһәрдә җитди төс ала башлады. Комиссиянең эшләре (эшкә круторак ябышуы) мөәссәсәләрдә (оешмаларда — З.К.) эшләүче рус иптәшләрне уйларга, бәгъзе юкарак башлыларын тыпырчынырга мәҗбүр итә башлады. Татарлашкан волость башкармаларына комиссия тарафыннан рус телендә генә җибәрелгән кәгазьләр кабул ителмәскә тиеш дип җибәрелгән тәкъдиме өчен бик эче пошкан иптәшләр булып, миңа как инструктор: «рус теле дә — шулай ук хокуклы тел, син аны хокуксыз итәргә тырышасың, бу юл — фанатизм юлы», — дип бәйләнгәннәр иде. Хәзер урыслар да кире кайткан кәгазьләрне тотып минем яныма килеп, «На, теперь переводи сам и напиши от руки 5 экземпляров» дип, минем өстәлемә куя башладылар. Ихтимал, алай ук круто ябышу сәяси яктан хатадыр да, ләкин шунсыз тоткан җирдән сындырмаганда эшләр бик салпы барачак. Шушы көнгә кадәр һичбер кантон мөәссәсеннән комиссиягә татар эшче кирәксенеп мөрәҗәгать итүче булмады. Соңгы көннәрдә татар эшчеләре кирәклеген әйтә башладылар... (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 85).

Лəкин безнең кулда аларны тəэмин итəрлек эшчелəребез юк. Шуның өчен комиссия хəзерендə кантонда эшкə яраклы татар егетлəрен эзлəп табып мөəссəсəлəргə куюга, килəчəк өчен кəнсəлəриягə татар эшчелəре хəзерлəү курсларын ныграк оештыруга əһəмият бирə... Татар телен гамəлгə кую эшендəге өндəү, аңлату, оештыру эшлəре юлга салынды» (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 102).

4.3.3. Арча кантоны. Арчаның үзендə татар халкы 8,3%ны гына тəшкил итсə дə, бөтен волостьлары белəн бергə бу сан 63,6%ка җитə (Сб., 1925, с. 82). Арча кантоны иң күп волостьлы кантоннардан санала: 1925 елга анда 19 волость исəплəнə, ə волостьлар эрелəндерелгəнче хəтта 32 волостька бүленгəн була (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 98).

ТҮБК сессиялəрендə һəм кайбер хисапларда Арча кантоны ТТГКның торышы буенча иң алгы урыннарда күрсəтелə. Чыннан да, əле 1924 елга кадəр үк кантондагы 13 волость татар телендə эш башкаруга күчкəн була. Волостьлар эрелəнгəннəн соң, 14 волостьта татар халкы күпчелекне тəшкил итеп, аларның барысында да татарча эш йөртелə (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 98), калган 5 рус волостенда исə рус теле саклана (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 32). Волостьларда һəм авыл советларында татар хезмəткəрлəренең саны да шактый була: «татар эшчелəренə ихтыяҗның 90%ы каплана» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 113).

Арча кантонындагы волостьларның яхшы татарчалаштырылуы ТҮБК игътибарыннан да читтə калмый. ТҮБК президиумының 1924 елның 12 январендəге утырышында Куллар волостен Кызыл тактага язу, ə волбашкарма хезмəткəрлəренə 3 червонец күлəмендə акча бирү турында карар кабул ителə (ф. 732, оп. 1, д. 336, л. 2). Кызыл такта хакында аңлатма: ТТГКда уңышка ирешкəн учреждение һəм хезмəткəрлəрне билгелəп үтү максатында, «Татарстан» һəм «Известия ТЦИК» газеталарында Кызыл такта булдырыла. Шулай

ук Әтнә, Кармыш һәм Мәмсә волостьлары да, 1923 елның 24 ноябрендәге ТҮБК президиумы карары нигезендә, Кызыл тактага кертелә, һәр волбашкармага 5шәр червонец акча тапшырылып, ул җаваплы хезмәткәрләргә бүләк итеп бирелергә тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 139, л. 4).

Волостьларда татар телен гамәлгә кертү буенча артык зур каршылыклар килеп чыкмаса да, кантон учреждениеләрендә хәлләр катлаулырак була. Канткомиссия инструкторы Ковaленский кантон оешмалары җитәкчеләренең ТТГК мәсьәләләренә пассив мөнәсәбәтен билгеләп үтә, моның белән көрәшү чарасы буларак әледән-әле комиссия утырышларында җитәкчеләрдән үз учреждениеләрендә татар теленең ничек тормышка ашырылуы хакында докладлар ясату турында карар кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 31). Аеруча начар татарлаштырылган оешмалар итеп түбәндәгеләр күрсәтелә: кантон финанс бүлеге, милиция идарәсе, сәламәтлек саклау бүлеге, Татсоюз, җир бүлеге, почта бүлекләре, хастаханәләр, агропунктлар, ветпунктлар, кантвоенкомат һ.б. Бары кантон башкарма комитеты, мәгариф бүлеге, Селькредпромсоюз, Татторг кебек учреждениеләр генә яхшы татарлаштырыла (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 32). Оештыру бүлеген санамаганда, кантонның барлык оешмаларында да татар волостьлары белән язышу күбрәк рус телендә алып барыла, татар телендәге кәгазьләр үтәлмичә озак тотылалар һәм уңайсызлыклар китереп чыгаралар (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 114).

Кантон оешмаларында татарлаштыруның начар хәлдә булуының төп сәбәбе итеп квалификацияле татар белгечләренең, бигрәк тә медиклар, агрономнар һәм финансистларның җитешмәве күрсәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 33). Казандагы Үзәк курсларга кантоннан татарлар даими рәвештә җибәрелеп тора. Ләкин,

беренчедән, бу сан гына бушлыкны тутыру өчен аз була, икенчедән, укып бетергән курсантларның барысы да Арчага кире әйләнеп кайтмый. Шунлыктан канткомиссиянең 1924 елның 10 июлендәге утырышында «...мәркәз ТТГК комиссиясенең Арча кантонынннан киткән курсантларның бөтенесен курслар беткәннән соң Арча кантонына кайтарылуларын һәм мөмкинлек табылган хәлдә башка кантон, урыннардан килгән, курсларны яхшы узган иптәшләрнең дә берникадәресен Арчага кайтарылуларын сорарга. Шулай ук мондагы кантон мөәссәсәләрендә татар теле гамәлгә куелуның түбәнлеге белән хисаплашып, киләсе приемнарда Арча кантонына (курсларда) киңрәк урын бирелүен сорарга» дигән карар кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 114).

Арчадагы татар хезмәткәрләрен арттыру максатында, Үзәк комиссия дә татар эшчеләре җибәреп тора. Ләкин, кантон комиссиясенең җавап хатларыннан күренгәнчә, ул эшчеләрнең хәзерлекләре бик начар була: канцелярия эше белән дә аз танышлар, җибәрелгән җиргә барып җитмиләр яки, барып җитсәләр дә, аз гына эшләп, күбесе каядыр китеп югалалар (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 110). Учреждениеләр үзләре дә аларны, түбән квалификацияле булуларын күрсәтеп, комиссиягә кире кайтаралар. Шулай берничә мәртәбә кайта-килә йөргәннән соң гына, хезмәткәрләр башка оешмаларга урнаштырылалар (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 33). Бу хәлләр кантон комиссиясен шактый уңайсыз хәлдә калдыра.

Башка юл калмагач, канткомиссия җәй көнендә генә булса да татар хезмәткәрләрен арттырып тору чарасына керешә: мәгариф бүлегеннән вакытлыча эшләү өчен җәйләрен эшсез торган мәгариф эшчеләрен биреп торуларын үтенә (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 114).

Акча булмау сәбәпле, кантон учреждениеләре үзләре өчен татар хезмәткәрләре әзерләү эше белән бөтенләй шөгыльләнмиләр.

Нигездә оешмалар тарафыннан практикантлар алынмый, шулай да кайбер учреждениеләр, үзләре өчен татар хезмәткәрләре әзерләү өмете белән, түбән квалификацияле татар эшчеләрен штатка кертәләр. Ләкин бу юл да үзен акламый, чөнки әлеге эшчеләр, билгеле бер квалификациягә ия булгач, акча күбрәк түләнә торган башка эшкә китеп баралар, яки югары органнар тарафыннан соратып алыналар (ф. 732, оп. 1, д. 770, лл. 33-33об.). Шунлыктан учреждениеләр кабат практикантлар алу фикереннән кире кайталар.

Арча кантоны ТТГК комиссиясенең 1924-1926 еллар өчен планында бик изге максатларны күздә тоткан, ләкин үтәлүе тиз арада мөмкин булмаган пунктлар да бар. Мәсәлән, 1 нче баскыч мәктәпләр программасына татар телен мәҗбүри предмет итеп кертү; 2 нче баскыч мәктәпләрдә татар телендә эш башкару һәм хисапчылык предметларын укыту; барлык башка милләт белгечләрен татар телен өйрәнергә мәҗбүр итү (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 34). Эшче-крестьян инспекциясе тикшерүчесе Красавина (үзе дә татар телен белми) гомумән барлык планны һәм бигрәк тә әлеге пунктларны тәнкыйть итә, аларның үтәлә алмаячагын ассызыклап күрсәтә (ф. 732, оп. 1, д. 770, л. 34).

Шулай итеп, Арча кантонындагы волостьларда һәм авыл советларында татар теле яхшы гамәлгә куелса да, кантон учреждениеләрендә, ягъни Арчаның үзендә, шактый күп каршылыклар килеп чыга.

4.3.4. Бөгелмә кантонын да гадәттә татар телен яхшы гамәлгә куйган кантоннар исәбенә кертәләр. Бөгелмәнең үзендә татарлар 11,5%ны гына алып торса да, бөтен кантон буенча бу күрсәткеч 60,2%ка җитә (Сб., 1925, с. 82). Бөгелмә кантонында волостьлар эреләнгәнче барлыгы 26 волость була, 1924 елдан аларның саны 14кә калдырыла. 14 волостьның 10сында татарлар 65тән 100%ка

кадәр тәшкил итә һәм, инструктор Хәмзин күрсәтүе буенча, «татар телен гамәлгә кую эшләре 100% тормышка үткәрелгән дип әйтеп була». 3 волостьта эчке эшләр русча алып барылып, татар авыллары татар телендә тәэмин ителә, 1 волость исә — саф рус волосте (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 112). Ләкин хисабының икенче урынында ук Хәмзин үз фикеренә үзе каршы килә. Инструкциянең татар халкы күпчелекне тәшкил иткән волостьларда барлык эчке эш алып баруны татар телендә куярга дигән маддәнең үтәлешен ни өчендер 1% дип кенә бәяли (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 111). Башка чыганакта да Бөгелмә кантонында бары 4 волостьта гына татар теле актив гамәлгә кертелгән дип күрсәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 521, л. 8).

Волостьлар «татар совет эшчеләре хәзерләү юлында бик зур егетлек күрсәтәләр». Мәсәлән, 5 волостьта, авыл советы сәркатипләре хәзерләү өчен, канткомиссия көче белән унар көнлек курслар үткәргәннәр (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 111). Волостьлар арасында бигрәк тә Бәйрәкә волосте аерылып тора. Бу волостьта ике мәртәбә курс булып (берсе — 10 көнлек, берсе — бер айлык), барысы 40 кеше имтихан белән укуларын тәмамлаганнар. Бәйрәкә курсларыннан чыккан кешеләр башка волостьларда гына түгел, Татарстандагы башка кантоннарда, хәтта Башкортостанда да эшлиләр. Моннан тыш, Бәйрәкә волостеннан СССРның төрле вузларында 17 кеше әзерләнә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 111).

Бөтен чыганакларны чагыштырып карап, авыл советлары һәм волостьлар хакында түбәндәге фикергә килергә мөмкин: Бөгелмә кантонындагы татар авылларында, авыл советларында ТТГК эшләренә зур әһәмият бирәләр, эчке эш йөртүләрне татарча алып баралар, ә волость учреждениеләрендә исә актив татар теленә күчү акрынрак бара.

Кантон оешмаларында татар хезмәткәрләренең гаять аз санны — 9%ны — тәшкил итүе дә зур авырлык тудыра (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 112). Бөгелмә кантоны ТТГК комиссиясе, әлеге мәсьәләне хәл итү өчен, барлык чараларны да күрергә тырыша: Казандагы Үзәк курсларга даими рәвештә курсантлар җибәреп тора; мәгариф бүлеге янында 27 кешелек волость, авыл советы эшчеләре хәзерләү өчен 3 айлык курслар ачып, шуларның 11ен волостьларга тарата, калганнарын төрле курс һәм уку йортларына җибәрә; оешмалар янында рус эшчеләре өчен дә татар теле курслары, түгәрәкләре эшләп килә һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 111).

Бөгелмә канткомиссиясе, башка кантоннарга караганда соңрак төзелсә дә, эш ягыннан шактый алга китә һәм аның эшчәнлеге һәрвакыт уңай бәя ала (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 74). Комиссия төрле запрос һәм доклад таләп итү юлы белән оешмаларга зур тәэсир ясый (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 112).

Бөгелмә кантоны буенча тагын шуны әйтеп үтәргә мөмкин: башка кантоннарда милиция һәрвакыт диярлек татар теле аз гамәлгә куелган бүлекләрдән саналса, бу кантонда исә милиция татар теленә әһәмият бирү ягыннан хәтта барлык кантоннар арасында беренче урын тота дип билгеләнә. Бөтен составта татарларның аз булуына да карамастан, булган татар милиционерлары татарча дознаниеләр алып, хәтта, киресенчә, рус теленә тәҗемәчегә ихтыяҗ күренә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 112).

4.3.5. <u>Тәтеш кантоны</u>нда татар халкы 57,6%ны алып тора, Тәтешнең үзендә бу күрсәткеч 18,8%ны тәшкил итә (Сб., 1925, с. 85). Кантонда волостьлар эреләнгәнче барысы 17 волость булып, 1924 елдан соң 7гә кала (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 116). Боларның өчесендә татар халкы 90-97%ны, икесендә 49-62%ны тәшкил итә (Сб., 1925, с. 80) һәм аларда татар теле актив рәвештә гамәлгә

кертелергә тиеш була. Әмма бары Бикеев волостенда гына эш башкару (хәрби эшләр һәм хисапчылыктан кала) татар телендә алып барыла. Ә 95-97% татарлардан торган Кильдураз һәм Урта Балтай волостьларында исә рус телендә эш йөртелә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 117). Ләкин бу волостьларда сәркатип итеп татарлар билгеләнгәннән соң, эшләр җайланган булырга тиеш. Татар авыл советлары белән язышу татар волостьларында электән үк җайга салынган була (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 142).

Кантон учреждениеләрендә татар телендәге телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр кабул ителә, ләкин язма җаваплар, КБК һәм ТТГК комиссиясен санамаганда, рус телендә генә бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 142).

Канткомиссия утырышында Тәтешнең үзендә татар эшчеләренең саны 13% дип күрсәтелә, моннан тыш, әле татарча белә торган хезмәткәрләр дә була. Бу күрсәткеч Татарстан республикасы масштабында ярыйсы дип табыла, ләкин моның белән генә тукталып калмаска, татар хезмәткәрләрен арттыру өчен чаралар күрергә дигән карар кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 116). Һәр учреждениедә диярлек татар хезмәткәрләре булып, татар телендә кабул ителгән кәгазьләрне тәрҗемә итүдә авырлыклар тумаса да, түбән органнарга таратылырга тиеш булган циркуляр һәм мөрәҗәгатьләрне тәрҗемә итү һәм берничә экземплярда күчереп язу алар өчен мөмкин хәл булмый, чөнки бу аларның үз эшләренә комачау итәр иде. Бер генә оешмада да штаттагы тәрҗемәче булмый. Татар эшчеләренең, бигрәк тә техник хезмәткәрләрнең җитешмәве, татарча шрифтлы машинкалар булмау, ТТГК өчен махсус акча бүлеп бирелмәү дә зур каршылыклар итеп аерып күрсәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 142).

Татар хезмәткәрләрен арттыру максатында, канткомиссия азмы-күпме квалификациягә ия татарларны эзләп табу, аларны

учреждениеләргә урнаштыру эше белән дә шөгыльләнә. Үзәк курсларга да һәрвакыт кешеләр җибәреп тора. Тәтеш канткомиссиясе тарафыннан да курсантларның тәҗрибәсез булулары, эшли белмәүләре күрсәтелә, ләкин комиссия аларны куып чыгару юлына басмый, ә оешмаларга ничек тә күбрәк татар җәлеп итү һәм аларга эшләргә мөмкинлек бирү максатын күздә тота. Чыннан да, эшкә урнаштырылган курсантлар бераздан шактый җаваплы урыннарда һәм яхшы итеп эшләп китәләр (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 116). Комиссия инструкторы тарафыннан кантондагы барлык учреждениеләрнең татар телен ничек гамәлгә куюлары һәрвакыт тикшерелеп тора (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 118).

Кантон ТТГК комиссиясе хисапларында тулаем Тәтеш кантонындагы татар хезмәткәрләренең саны 28% белән билгеләнә, шулай ук һәр оешманың инструкцияне ничә процентка үтәве исәпләнә (ф. 732, оп. 1, д. 530, лл. 143-144). Ләкин бу нәтиҗәләрнең якынча гына булулары күренеп тора, чөнки күрсәткечләр төрле чыганакта төрлечәрәк бирелә. Әмма бер фикер барлык чыганакларда да раслана: Тәтеш кантонында ТТГК эшләре акрын, ләкин уңышлы бара һәм бер урында тукталып тормый (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 116; д. 446, л. 11).

4.3.6. Чаллы кантонында татар халкының саны 57,7% белән билгеләнә, Чаллы шәһәренең үзендә исә 23,9%ны тәшкил итә (Сб., 1925, с. 85). Чаллы кантонында, волостьларны эреләндергәнче, барысы 18 волость булып, 1924 елдан соң 11гә калдырыла. Аларның берсе саф татар волосте булып, 5се — 72дән 95кә кадәр % тәшкил иткән татарлы волостьлар, калган 5 волостьта руслар-татарлар катнаш (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 119; Сб., 1925, с. 80).

Инструктор Хәмзин күрсәтүе буенча, кантонда татар теле бигрәк тә волостьлар эреләнгәч кызып китә. 6 татар волостенда

эшләр бөтенләй татар телендә юлга куелган. Аларның кантон оешмалары белән дә бөтен мөнәсәбәтләре татарча бара. Калган 5 волостьта эчке эш йөртүләр рус телендә булсалар да, татар авыллары белән булган мөнәсәбәтләре татарча тәэмин ителгән. «Шулай итеп, Чаллы кантонының волостьларында татар теле 100% гамәлгә кертелгән була» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 119).

Кантон учреждениеләрендә эшләүчеләрнең гомуми саны 452 булып, шулардан татарлар — 64 кеше (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 39), ягъни 14% килеп чыга. Моннан күренгәнчә, кантондагы оешмалар татар хезмәткәрләренең күплеге белән мактана алмыйлар. Оешмалар арасында кантон башкарма комитеты, мәгариф һәм җир бүлекләре яхшы татарлаштырылган һәм татар волостьлары белән бөтен мөнәсәбәтләрен диярлек татарча йөртүче бүлекләрдән саналалар (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 119). Ләкин бу бәяләмәнең дә якынча гына бирелүен икенче бер чыганакка күз ташлап күрергә мөмкин: «кантон башкармасы хозурында бер генә татар эшчесе булып, ул да, 1902 елда туганлыктан, урыннан азат ителде. Шунлыктан кантон башкармасының бөтен татарча эшләрен үтәү ТТГК комиссиясенә йөкләнелә, соңгысының бөтенләй даими эшчесе бер сәркатип, бер эш башкаручыдан гыйбарәт булганлыктан, килгән татарча эшләрне, беркетмәләрне, айлык хисапларны русчага әйләндерү, шулай ук башкармадан шул ук 6 волость өчен чыгачак язуларны татарчага әйләндереп, 6 волость өчен 6 экземпляр кул белән язып утыру комиссиягә ифрат авыр» (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 37). Тикшерүләр нәтиҗәсендә шулай ук финанс бүлеге, Татсоюз, почта-телеграф конторалары, Уголовный розыск һәм ГПУда татар теленең начар тормышка ашырылуы билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 25). Мәсәлән, финанс бүлегендә татар телендә килгән кәгазьләргә җаваплар рус телендә генә языла; почта-телеграф контораларында

1924 елдан татарча адрес язылган хатлар да кабул ителә башласа да, телеграф конторасындагы актык татар эшчесен дә Казанга алулары сәбәпле, уңайсызлыклар очрый башлый: татар телендә язылган хатлар иң элек берәр якындагы татар эшчесе булган конторага җибәрелә (бу очракта Әгерҗегә), шуның аркасында хатлар җибәрелгән урынга кичегеп баралар. Комиссия почтага бер татар эшчесе бирергә булса да, почта-телеграф мөдире Главконторадан рөхсәт булмыйча алудан баш тарта (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 60). Гомумән, күпчелек учреждениеләрнең җитәкчеләре комиссия тарафыннан җибәрелгән татар хезмәткәрләрен акча һәм штат булмауны сәбәп итеп алмыйлар. Комиссия аларны рус хезмәткәрләрен кыскартып булса да алуларын таләп итә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 25). Күпчелек оешмаларның ТТГК инструкциясен бөтенләй белмәүләрен, белсәләр дә, татар волостьларына русча кәгазьләр җибәрүләрен, татарча гариза кабул итмәүләрен комиссия ачыну белән хәбәр итә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 25), аларны тикшереп, ТТГК эшләрен башкарырга мәҗбүр итү чараларына керешә, хәтта татар телен кертүгә әһәмият бирмичә салкын караучы учреждениеләргә актлар төзеп, тиешле урыннарга тапшыра (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 39).

Татар эшчеләре хәзерләү буенча кантон комиссиясе Казандагы Үзәк курсларга кешеләр җибәрү белән генә чикләнми, Чаллы шәһәрендә татар телендә эш башкаручылар әзерләү курслары оештыра һәм укып бетергәннәрен төрле волостьларга, кантон оешмаларына эшкә билгели. Ләкин ул курсантларны күп кенә оешмалар, алда әйтелгәнчә, эшкә алудан баш тарталар (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 25), нәтиҗәдә комиссиягә мәҗбүр итү чараларына керешергә туры килә.

Чаллы кантоны ТТГК комиссиясе тарафыннан шулай ук Үзәк комиссия дә шактый тәнкыйтьләнә, ҮКның бервакытта да кантоннан җибәрелгән айлык хисапларны карап, андагы җитешсезлекләрне күрсәтмәве, инструкторлар җибәрмәве (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 60), эшләрне алып бару өчен күрсәтмәләр һәм үрнәкләр белән тәэмин итмәве (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 39) гаеп ителә.

Гомумән алганда, Чаллы кантонында ТТГК эшләре канәгатьләнерлек дип бәяләнә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 26) һәм моны алдарак ясалган күзәтүдән дә күрергә мөмкин. Хәзерге вакытта Чаллы шәһәре татарларның иҗтимагый, икътисади һәм мәдәни үзәге булган кебек, 20 нче елларда да Чаллы кантонында татар телен чын мәгънәсендә дәүләт теле итүгә зур әһәмият бирелә.

4.3.7. Буа кантонында татар халкы 55,3%ны тәшкил итә. Буаның үзендә татарларның саны 34,6% белән билгеләнеп, бу күрсәткеч башка шәһәр һәм кантон үзәкләре арасында беренче урынны били (Сб., 1925, с. 83). Буа кантонында 1924 елга кадәр барлыгы 17 волость булып, волостьлар эреләнгәннән соң, аларның саны 7гә калдырыла (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 121). Шуларның 6сында татарлар 54%тан 96%ка кадәр тәшкил итәләр (Сб., 1925, с. 76), димәк, аларда татар телен 100% гамәлгә кертергә кирәк булып чыга. Иске Шәйморза, Зур Тархан, Чүпрәле волостьларында әле 1924 елга кадәр үк бу эш тормышка ашырыла (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 121). 1925 елның октябрендәге мәгълүматлар буенча, Чүпрәле волостендагы милиция һәм салым өстәлләре генә татар эшчеләре булмаганлыктан татарлаштырылмый. Буа волостенда татар теле яртылаш кына кертелә. Калган 3 волостьта татар эшчеләре бөтенләй булмыйча, бары 1925 елда гына аларга берәр техник эшче билгеләнә. Нәтиҗәдә ул волостьлар да аз гына булса да татарчалаштырылып, эштә беркадәр җанлылык сизелә башлый (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3 об.).

Волость башкармаларында да татарлар элек 25%ны тәшкил итсәләр, 1925 елга аларның саны 45%ка җитә (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3).

Барлык татар авыл советларында татар телендә эш башкаруга күчү эше Буа кантонында 1925 елга 90%ка үтәлә. Бары Городище һәм Уби волостьлары һәм аларга кергән авыллар арасындагы бәйләнеш кенә татарчага әйләнеп бетә алмый (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3 об.). Авыл советларындагы татар эшчеләренең саны 1925 елга 28%тан 45%ка җитә (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3).

Татар авыл советларының эшләрен җанландыру, волостьлар белән элемтәләрен татарчалаштыру нияте белән, 1925 елның 25 маеннан 25 июньгә кадәр 30 кешелек авыл советлары сәркатипләре курсы ачыла. Дәресләр Казаннан җибәрелгән программа буенча үткәрелә. Гомумән алганда, курсларның нәтиҗәсе яхшы дип бәяләнә (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3 об.). 1926 елда исә 40 кешелек татар эшчеләре хәзерләү курсы ачарга уйлануы мәгълүм (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3), ләкин аның нәтиҗәләре хакында берни дә билгеле түгел.

Кантон учреждениеләрендә, авыл советлары һәм волостьлар белән чагыштырганда, ТТГК эше акрынрак бара, шулай да кантон инструкторы аларның татар теленә салкын карашлары сизелмәвен, кирәк вакытта тиешле ярдәм күрсәтүләрен билгели (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3). Кантон башкарма комитеты, гомуми бүлек, ГПУ, мәгариф һәм җир эшләре бүлекләре татар эшчеләре белән беркадәр тәэмин ителә. Бу оешмалар татар волостьлары белән булган мөнәсәбәтләрен татар телендә алып баралар (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3 об.). Ике халык хөкеме (суд) төбәгендә һәм бер тикшерү участогында бөтен эшләр татарча куела, аларның татар эшчеләре белән тәэмин ителеше дә 100% дип бәяләнә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 121; д. 789, л. 3 об.). Финанс бүлеге, урман идарәсе, сан алу бүлеге, почта идарәсе, телеграф станциясе, милиция идарәсе һәм профсоюз оешмаларында

исә татар телен эшкә ашыру түбәнрәк тора, чөнки татар эшчеләре булмау сәбәпле, бу бүлекләрне татарчалаштырып булмый. Шулай да татар телендәге гаризалар кабул итү, зуррак циркулярларны ике телдә йөртү тәэмин ителә (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 3).

1922-1926 ел мәгълүматларын чагыштырып карасак, 1922 елда кантон оешмаларындагы татар эшчеләре 5,5%ны, 1924 елда — 18,8%ны (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 121), ә 1925 елда 22,3%ны тәшкил итәләр. 1926 елда бу күрсәткеч тагын да артыграк булырга тиеш кебек тоелса да, чынлыкта татар хезмәткәрләре 19,6%ны алып торалар. Ике ел күрсәткечләрен чагыштырып карасак, әлеге хәл тагын да ачыграк күзаллана: 1925 елда җаваплы хезмәткәрләрнең саны 40,35% булган булса, 1926 елда 28,63%ка гына кала; техник хезмәткәрләр: 1925 елда — 16%, 1926 елда — 13,77%; квалификациясез эшчеләр: 1925 елда — 10,7%, 1926 елда — 16,34% (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 42 об.). Бу мәгълүматлардан күренгәнчә, кантон учреждениеләрендә җаваплы һәм техник хезмәткәрләрнең саны бер ел эчендә шактый кимегән, ә түбән эшчеләрнең саны, киресенчә, арткан. Кимүнең төп сәбәбе — татар хезмәткәрләренең бик аз булуы, булганнарының да, хезмәт хакы бик түбән булганлыктан, эшкә керергә теләмәүләре. Канткомиссия шундый урыннарны тутыру уе белән Буа кантонына күрше Чуваш җөмһүриятеннән дә татар хезмәткәрләре чакырткалап карый, ләкин алар да хезмәт хакын азсынып килмиләр. Кантон учреждениеләрендә эшләрлек квалификациягә ия булган техник хезмәткәрләр дә я укытучы, китапханә мөдире кебек урыннарда эшли, я уку йортларына кереп укый, я Төркестан, Донбасс, Баку һәм үзәк губерналар кебек хезмәт хакы югары түләнә торган һәм завод-фабрикалы төбәкләргә китеп баралар (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 42 об.).

Нәкъ шул сәбәпләр аркасында, 1926 елга татар хезмәткәрләренең саны сирәкләнә.

Буа кантоны башкарма комитеты президиумы 1924 елның 17 маендагы утырышында хезмәткәрләрнең ике телне дә белүләрен квалификациягә санап, аларның хезмәт хакын арттыру тәкъдиме белән чыгып, әлеге мәсьәләне хәл итү өчен канткомиссия рәисен ТҮБКга җибәрү хакында карар кабул итә (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 62). Ләкин, югарыда күренгәнчә, Буа кантонындагы татар хезмәткәрләре хезмәт хакларының зурлыгы белән һич тә мактана алмыйлар, димәк, әлеге изге максат тормышка ашмыйча, чираттагы хыял гына булып калган.

Буа кантоны ТТГК комиссиясе хисабында татарчалаштыру эшенең тиз адым белән алга баруына тоткарлык ясаучы сәбәпләр итеп татар хезмәткәрләренең җитешмәве, татар телендәге язу машиналарының булмавы, шулай ук кайбер учреждение җитәкчеләренең татар телен тормышка ашыру эшенә иң соң хәл ителергә тиешле мәсьәлә дип карaулары күрсәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 789, л. 42).

4.3.8. <u>Лаеш кантоны</u> — 20 нче елларда Татарстанда татар халкы азчылыкны тәшкил иткән 5 кантонның беренчесе. Бөтен волостьлары белән бергә татарлар 49,9%ны алып торса да, башка шәһәр һәм кантон үзәкләре арасында иң түбән күрсәткечкә — 5,7%ка — ия Лаеш белән бергә, татар халкының саны бөтен кантонга 49%ка кала (Сб., 1925, с. 83). 1924 елга кадәр Лаеш кантонында 17 волость булып, аларда ТТГК эшләре бик начар бара, фәкать Теләче волосте гына үзенең тырышлыгы белән татар телен кертүгә ирешә һәм практикантлар тоту юлы белән башка волостьларга да күп хезмәт күрсәтә. Ә башка волостьларда татар телен гамәлгә кертү эше 20% үткәрелгән дип бәяләнә. ҮК

инструкторы Хәмзин күрсәтүе буенча, волостьлар эреләнгәннән соң, эшләр бөтенләй башка юл белән китәләр, аларда ТТГК яхшы ук җайланып китә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 123). Бу вакытта 17 волость 9га калып, шуларның 5сендә татар халкы 63-76%ны, 3сендә — 15-39%ны тәшкил итә һәм бары бер волостьта, Балык Бистәсендә генә, татарларның саны 15 кенә булып, бу 0,1% күрсәткече белән билгеләнә (Сб., 1925, с. 77). Татар халкы күпчелекне алып торган 5 волостьта: Теләче, Яңа Арыш, Күгәрчен, Олы Солтан һәм Саралы (элекке Ташкирмән) волостьларында татар теле актив рәвештә гамәлгә куелырга тиеш була һәм шуларның 4сендә 1924 елга ук бөтен эшләрне татар телендә йөртүгә күчәләр, берсендә шуңа хәзерлек күрелеп ята (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 123). Татарлар күбрәк булган волостьларда татар телендәге язма һәм телдән мөрәҗәгатьләр кабул ителә һәм аларга җаваплар да татарча бирелә, барлык эчке эш башкару (хәрби өстәлдән һәм кайбер акча документларыннан кала) татар телендә тәэмин ителә, кантон оешмаларына җибәрелә торган барлык кәгазьләр дә татарча языла, бары Саралы волостенда гына татар телендәге кәгазьләрне кабул итү эше җайланмый. Әлеге 5 волостьта ТТГК инструкциясенең барлык пунктлары да диярлек үтәлгәнлеге билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 528, лл. 17-19). Калган 4 волостьта исә эш башкару рус телендә калдырыла.

Волостьлар белән чагыштырганда, кантон учреждениеләрендә ТТГК эшләре бик түбән хәлдә була. Инструкциянең 1-2 маддәсен генә гамәлгә кертү белән канәгатьләнәләр. Татарчалашкан волостьлар белән мөнәсәбәтләре искечә рус телендә бара, хәтта кайбер оешмаларның татарча җибәрелгән кәгазьләрне кире кайтару очраклары да күзәтелә. Мәсәлән, Лаеш кантоны прокурор ярдәмчесе татар суд участогына «безгә җибәрә торган кәгазьләрегезне татарча языгыз» дигән хат юллый (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 123).

Кантонда 4 суд участогы булып, бары берсендә генә суд эшләре тулысынча татар телендә йөртелә. Билгеле, бу татар халкының ихтыяҗларын канәгатьләндереп бетерә алмый.

Кантон оешмалары үзләренә татар эшчеләре җәлеп итүгә һич әһәмият бирмиләр. Мәсәлән, 1924 елның февраленә 400дән артык хезмәткәрнең бары 8ен генә татарлар тәшкил итә: 3се — җаваплы хезмәткәр, 5се — «сотрудник» дип кенә бирелә. Татар эшчеләре хәзерләү өчен бертөрле дә курс ачылмый һәм аны кирәксенгән кеше дә булмый (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 123). Рус хезмәткәрләренең татар телен белмәүләре татар телен гамәлгә кертүдә зур тормоз итеп күрсәтелсә дә (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 5), русларны татар теленә өйрәтү түгәрәгенең бары Лаештагы комсомол оешмасында гына булуы мәгълүм (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 11).

Башка кантоннарда татарлаштыру буенча гадәттә беренче урыннарны биләгән кантон башкарма комитеты да Лаешта артта сөйрәлә. Аның барлык бүлекләрендә дә татар теле начар кертелә, аппаратында да бары бер техник хезмәткәр булуы билгеле. Төп сәбәп итеп татар хезмәткәрләренең булмавы күрсәтелә, ләкин, кайбер кешеләр фикеренчә, алар бар һәм эшкә җәлеп кенә ителмиләр (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 17).

Йомгаклап әйткәндә, Лаеш кантоны учреждениеләрендә ТТГК эшләренә тиешле игътибар бирелми, оешмаларны татар халкына якынайту өчен бернинди план-перспектива да төзелми. Шулай да кантонда ике 2 нче баскыч мәктәп булып, һәр икесендә татар теле яхшы гына укытыла (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 123), шулай ук хәтта 1 нче баскыч мәктәпләрнең дә кайберләрендә татар телен укытуга зур игътибар бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 11).

4.3.9. Алабуга кантоны волостьларында татар халкы 49,4%ны тәшкил итсә дә, 12,8% татарлы Алабуга шәһәре белән бергә санаганда, күрсәткеч 48%ка кала (Сб., 1925, с. 83).

Алабуга кантоныннан ТТГК эшләренең торышы хакында мәгълүмат бик аз бирелә. Бары канткомиссиянең бик кыска бер хисабы, 1925-1926 еллар өчен эш планнары гына бар. Канткомиссиянең ҮКга җибәргән хисабында волостьларны эреләндерүнең нәтиҗәләре, кантон учреждениеләрендә татар теленең ничек гамәлгә куелганлыгы, татар хезмәткәрләренең саны — берсе дә күрсәтелми (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 38).

ҮК инструкторы Хәмзинның Алабуга кантоны хакындагы хисабында да мәгълүматлар бөтенләй юк диярлек. Бары волостьлар эреләнгәнче кантонда 8 волость булганлыгы хакындагы информация генә игътибарга лаек (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 122). 1925 елгы статистик мәгълүматларда Алабуга кантонында 7 волость күрсәтелә. Аларның 5сендә татар халкы 56-80%ны, берсендә — 11,3%ны тәшкил итә, ә бер волостьта бары 5 кенә татар яши (Сб., 1925, с. 77).

Алабуга кантонында ТТГК эшләренең гаять начар дәрәҗәдә булуын Үзәк комиссиянең 1925-1926 елларда кантонга җибәргән хатларыннан күрергә мөмкин. 1925 елның 31 декабрендәге беренче хатта: «Алабуга кантоны Татарстанның бөтен кантоннарына караганда ТТГК җәһәтеннән иң артка калган кантоннарның берсе булып күренә», — диелә һәм катгый рәвештә чаралар күрергә тиешлекләренә басым ясала (ф. 732, оп. 1, д. 790, л. 19). Ләкин көтелгән чаралар үткәрелмәгән булырга тиеш, чөнки 1926 елның мартында җибәрелгән икенче хатта да Алабуга кантоны бик нык тәнкыйть ителә. Кантон башкармасында бер генә татар канцелярия эшчесе дә булмау, кантон учреждениеләрендә эшләүче 1125 хезмәткәрнең бары 117се генә татар булып, башка милләтләр белән

чагыштырганда моның 1,04% кына тәшкил итүе гафу ителмәслек җитешсезлек һәм эшләмәгәнлекне күрсәтеп тора торган ачык шаһит дип белдерелә (ф. 732, оп. 1, д. 790, л. 21).

Канткомиссиянең эш планнарыннан күренгәнчә, хәтта 1926 елның маена да кантон оешмаларында һәм волость башкарма комитетларында ТТГК эше бик йомшак, бернинди плансыз алып барыла: татар халкы күпчелекне тәшкил иткән авыл советлары һәм волостьларда да татар теле актив кертелеп бетми, бу вакытка кадәр ике телне дә белүче хезмәткәрләрнең исәбе алынмый, кантон оешмаларында татарча мөрәҗәгатьләрне кабул итү һәм аларга татарча җаваплар бирү эше тәэмин ителми, җитәкче урыннарга ике дәүләт телен дә белгәннәрне кую, эштән азат ителгәннәр урынына татар хезмәткәрләрен алу мәсьәләләренә игътибар бирелми, татар төбәкләрендә суд эшләре татарчага күчерелми, хәтта пичәт, штамп, эленмә такталар да татарча эшләнеп бетми һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 790, лл. 63 об., 66-67 об.). Бу эшләр барысы да 1926 елның икенче яртысында башкарылырга тиеш булып, планга кертеләләр. Ләкин әлеге бурычлар үтәлгәнме, юкмы — анысы турында чыганаклар дәшми.

Бары бер генә мәсьәләдә Алабуга кантоны ТТГК комиссиясенең эшчәнлеген уңай яктан бәяләргә мөмкин: авыл советы һәм волость эшчеләре хәзерләү эшен комиссия иң беренче урынга куя һәм шактый актив эш алып бара. Мәсәлән, 1924 елның 20 мартында Алабугада ачылган бер айлык курсларда татар эшчеләре хәзерләнә. Курслар башта 40 кешелек итеп уйланылган булса да, 21 кеше генә укырга теләк белдерә. Курсларда татар һәм рус телләре, арифметика, эш башкару, политграмота, авыл хуҗалыгы, кыскача гына гигиена фәннәре укытыла. Курсантлар арасында бик начар әзерлеклеләре, татар педагогик курсларыннан чыгарылганнары да була, ләкин алар

бары 6 гына кешене тәшкил итә, калганнары исә уңышлы рәвештә укып, ике телдә дә эш башкара алырлык белгечләр булып чыгалар (ф. 732, оп. 1, д. 528, л. 38).

1926 елда да ай ярымлык һәм 25 кешегә хисапланган авыл советы эшчеләре хәзерләү курслары ачу эше планга кертелә, ләкин аның нәтиҗәләре билгеле түгел.

Кыскасы, булган бик аз санлы мәгълүматлардан Алабуга кантонында татар теленең бик начар гамәлгә куелганлыгы, бары тик татар эш башкаручылары әзерләүгә генә азмы-күпме игътибар бирелгәнлеге аңлашыла.

4.3.10. Зөя (Свияжск) кантонында татар халкының саны 37,7%ны тәшкил итә, кантон үзәгендә исә татарлар 30лап кына (0,1%) була (Сб., 1925, с. 79). Кантонда волостьлар эреләнгәнче, барлыгы 13 волость булып (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 116), эреләнгәч, 8гә кала. Шуларның 4сендә татарлар күпчелекне тәшкил итә (69-93%), ә 4се — саф рус волостьлары диярлек (0-5%) (Сб., 1925, с. 79). Татар халкының күпчелеге ягыннан караганда, 4 волостьта татар теле тулысынча гамәлгә куелырга тиеш булса да, 1924 елга кадәр фәкать бер волостьта гына татар теле 100% гамәлгә кертелеп, башка волостьларда эшләр бик йомшак була (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 116).

ҮК инструкторлары Хәмзин да, Гайнуллин да, Зөя кантонында ТТГК эшләренең барышын тикшергәннән соң, кантондагы комиссиянең барлыгы да билгеле булмавын (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 116), аның эшкә бик салкын каравы аермачык күренеп торганлыгын (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 56) билгеләп үтәләр. Канткомиссиянең Үзәк комиссия белән дә бернинди бәйләнеше юк һәм «Зөя кантонында ТТГК эшләре папкасы тәмам буш кабыктан гына гыйбарәт» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 116).

Зөя кантонындагы татар волостьлары эшләрен татар теленә күчереп бетергәннәрме, кантон белән мөнәсәбәтләре ничек, нинди авырлыклар бар — бу хакта бер чыганакта да мәгълүмат юк. Бары кантон учреждениеләре генә аерым-аерым шактый җентекләп тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләреннән түбәндәгеләр аңлашыла: кантонның гомуми бүлеге һәм аның карамагындагы оешмалар, татарлар белән аеруча тыгыз бәйләнгән булсалар да, бу бүлектә «һичнәрсә эшләнгәне юк» (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 55). Гомуми бүлектә бер генә татарча белгән кеше дә эшләми, 3 кеше бар дип хисап кылынса да, алар да язу белүчеләр түгелләр. Татар телендә кергән кәгазьләргә җаваплар бирелмәгән, бүлекнең үзеннән бер татарча язу да чыкканы юк. Карарлар, инструкцияләр, игъланнар волостьларга да, Свияжскиның үзенә дә рус телендә генә җибәрелә. Ләкин Свияжск өчен шулай булуы бер яктан гафу да ителерлек, чөнки шәһәрдә бары тик 3 татар гаиләсе яши. Бүлеккә һәм аның кул астындагы учреждениеләргә татаа хезмәткәрләрен алуга аларның бөтенләй булмавы комачаулый. Бөтен шәһәргә бер генә татар канцелярия эшчесе дә булмый (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 51).

Мәгариф бүлеген ТТГК буенча уңай яктан бәяләргә мөмкин. Бүлектә барлыгы 10 хезмәткәр эшли, шуларның 5се — татар, 2 кара эшченең дә берсе — татар. Бөтен кантон буенча мәгариф эшчеләре — 181, аларның 77се — татарлар һәм керәшеннәр (42,5%). Кантондагы рус мәктәпләре — 49, татар һәм керәшен мәктәпләре — 37. Мәгариф бүлегенә татар телендәге язулар кабул ителә һәм татарча җавап та бирелә. Татар авылларына инструкция һәм игъланнар җирле типографиядә татар телендә бастырылып җибәрелә. Бүлектә кәгазьләрне күбәйтү җайланмаларының, һич тә булмаса, татарча шрифтлы машинаның булмавы төп каршылыкларның берсен тәшкил итә (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 52).

Финанс бүлегендә эшләүче 42 кеше арасында бары бүлек мөдире генә — татар. Зөя кантонындагы финанс бүлеге начар татарлаштырыла: татар телендәге язулар кабул ителсә дә, аларга җаваплар русча бирелә, татар волостьларына да рус телендәге кәгазьләр җибәрелә, инструкция һәм карарлар да русча гына языла, барлык эчке һәм тышкы эшләрне алып бару рус телендә генә тәэмин ителә. Кыскасы, Гайнуллин сүзләре белән әйткәндә, финанс бүлегендә «иске карагруһ чиновниклар, Зөя мещаннары» эшли. «Бу бүлек крәстиән халкы белән нихәтле якын торса да, кантон комиссиясенә һич әһәмият бирми» (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 55).

Зөя кантонындагы 3 суд участогының берсендә, шулай ук бер тикшерү участогында барлык эшләр дә татар телендә генә алып барыла, суд-тикшерү органнарында эшләүче 23 хезмәткәрнең дә 12се — татар (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 48). Рус телендә эшләүче хөкем төбәкләренә дә кирәк урыннарга татарларны куялар (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 56).

Зөя кантоны милиция идарәсе дә татарлаштыру эшләрендә зур урын тота. Идарәгә татар волостьларыннан килгән татарча язмалар кабул ителә һәм аларга татарча җавап та бирелә. Татар волостьлары белән барлык эшләрен татар телендә йөртәләр. Волостьлардагы барлык милиционерлар да, эш башкаручылар да — татарлар (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 56).

Йомгаклап әйткәндә, Зөя кантоны авыл советлары һәм волостьларында ТТГК эшләренең барышы хакында мәгълүматлар бөтенләй юк, ә кантон учреждениеләре арасында мәгариф бүлеге, милиция идарәсе, суд-тикшерү участокларында татар теле канәгатьләнерлек тормышка ашырыла, финанс, сан алу, гомуми, җир эшләре бүлекләрендә исә татар теле гаять начар хәлдә була. Шулай

ук кайбер чыганакларда Зөя кантоны ТТГК комиссиясенең эшчәнлеге канәгатьләнерлек дип табыла (ф. 732, оп. 1, д. 792, л. 7).

4.3.11. Спас кантонында татарларның саны 37,3%ны, ә кантон үзәгендә 9,6%ны тәшкил итә (Сб., 1925, с. 85). Кантонда волостьлар эреләнгәнче барысы 14 волость булып, 1924 елдан 8 волостька калган (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 114). Алар арасында 3 волость 62-75% татарларны эченә ала, 4 волость — 7-38% татарлы, ә калган берсе — саф рус волосте (Сб., 1925, с. 79). Димәк, Спас кантонында 3 волостьны бөтенләй татарчалаштырып, 4 волостьның татар авыллары белән бәйләнешен татар телендә булдырырга кирәк була. Ләкин Спас кантоны волостьларында ТТГК эшләренең соң дәрәҗәдә түбән торуы күп чыганакларда раслана (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 114; д. 529, лл. 6-7, 24). Хәтта 1926 елның апреленә дә бер генә татар волосте да эшләрен татарча куярлык хәлгә килеп җитми. Бары Әлки волостеның гына моңа якынлашып килүе, эш йөртә алырлык сәркатип булса, төп эш башкаруны татарча куярга мөмкин булуы билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 793, л. 26а об.).

Спас кантонындагы волостьларга да, авыл советларына да татар хезмәткәрләре җитмәү зур кыенлык тудыра. Хезмәт хакының түбән булуы читтән килеп эшләү өчен мөмкинлек бирми, хәтта күрше волостьлардан да килергә теләмиләр. Авыл советларына хезмәткәрләр табып булмауның төп сәбәбен канткомиссия үзенчәлекле аңлата: моның сәбәбе шул авылда кеше юклыктан түгел, бәлки татарның традициясе буенча, авыл советы эшен, җәмәгатькә катнашуны түбән санау. Яшьләр булса, аларга халык «малай» дип карый, шуның өчен яшьрәкләр читтә йөри. Икенчедән, авыл советларының эш даирәсе дә киңәйгәнгә, һәрвакыт эш күп булып тора, эштә тәҗрибәлелек, игътибарлылык сорала (ф. 732, оп. 1, д. 793, л. 26а).

Ләкин Спас кантоны комиссиясе «татар хезмәткәрләребез юк» дип, кул кушырып кына утырмый, аларны хәзерләү чараларына да керешә. Үзәк курсларга кешеләр җибәрүгә зур әһәмият бирә, хәтта Үзәк комиссия тарафыннан Спас кантонына бүлеп бирелгән саннан да артык итеп кешеләр җибәрергә тырыша (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 34). Шулай ук кантонның үзендә дә, зурдан кубып, курслар ачу идеясе белән йөри. 1924 елның февралендә ачылып, ике тапкыр өчәр ай дәвамында, Спас шәһәрендә 660 укучыга, Базарлы Матакта 40 кешегә, барлыгы 5 укытучыга уйланылган курслар чыннан да тормышка ашырылган булса, кантон өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле эш башкарылган булыр иде. Ләкин курсларның 4 февральдә ачылуы хәбәр ителсә дә (ф. 732, оп. 1, д. 529, лл. 13-14), 9 апрельдә Финанс комиссариатыннан ТҮБКга җибәрелгән юлламада Спастагы курслар сметасының, җирле бюджетның бик авыр хәлдә булуы сәбәпле, кабул итела алмаячагы хәбәр ителә (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 9). Бу кире кагудан соң, 1924-1925 елларда, курслар ачарга омтылыш ясалганмы, юкмы — билгеле түгел. 1926 елның 20 мартында авыл советы сәркатипләре курсы ачылуы, ләкин «теләккә һәм ният иткән нәтиҗәгә хезмәт итмәячәге билгеле булгач», таратылуы мәгълүм. Комиссия аңлатуы буенча, сәркатипләрне мәҗбүри рәвештә китерү өчен, аларның җәмәгать эшләре беткәнне көтәргә туры килә, көткән арада яз җитеп, кыш эшләре башланачагы күренә, шулай итеп, сәркатипләрне ничек тә китереп булмавы беленә (ф. 732, оп. 1, д. 793, л. 26а). Күренгәнчә, чыганаклар буенча билгеле булган ике курс та бернинди нәтиҗәсез тәмамлана.

Кантон бүлекләре һәм учреждениеләрендә ТТГК эшләренең барышы хакында мәгълүматлар юк диярлек. Бары аларда эшләүче татар хезмәткәрләренең саннары гына билгеле. Барлык оешмаларда эшләүче 302 хезмәткәрнең бары 14ен генә татарлар тәшкил итә,

шуларның 6сы — җаваплы хезмәткәр, 3се — техник хезмәткәр, 5се — кара эшче (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 114). Димәк, кантон учреждениеләрендәге татар хезмәткәрләренең саны бары 4,6% белән генә билгеләнә ала. Оешмалар арасында кантон башкармасында 15 хезмәткәрнең 2се — татар, финанс бүлегендә 68нең 1се, җир эшләре бүлегендә 26ның 1се, мәгариф бүлегендә 14нең 2се, суд учреждениеләрендә 24нең 1се һәм милиция идарәсендә 74нең 5се генә — татарлар. Ә ветеринария идарәсе, профсоюз аппараты, Наркомтруд вәкиллеге, сан алу бүлеге, хәрби комиссариат, Татсоюз һәм Татторг бүлекләрендә бер генә татар хезмәткәре дә эшләми (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 114). Бу авыр хәлне бетерү максатында, канткомиссия кантондагы бөтен оешмаларның исемлеген соратып алдыра, һәрберсенең штатын карап чыга, эшсез татар хезмәткәрләрен исәпкә алып, аларны әкренләп кантон һәм волость оешмаларына урнаштырып бара, бу учреждениеләрне бигрәк тә татар һәм рус телләрендә эш башкаручылар, тәрҗемәчеләр белән тәэмин итүдә әһәмияте зур була (ф. 732, оп. 1, д. 529, лл. 31-32, 34). Комиссиянең ачынып хәбәр итүенчә, кантондагы оешмалар татар теленә әһәмият бирмиләр, берсе дә үзләре комиссиягә татар эшчеләре сорап мөрәҗәгать итми, комиссия билгеләгән очракта да әле озак тартышлар соңында гына алалар (ф. 732, оп. 1, д. 529, л. 32).

Йомгаклап әйткәндә, Спас кантонында ТТГК эшләре бик әкрен бара, бөтенләй татарчага әйләндерелгән волостьлар да, оешмалар да булмый. Канткомиссия кантон учреждениеләрен, волость һәм авыл советларын татар хезмәткәрләре белән тәэмин итү буенча кулыннан килгән кадәр эш башкара, ләкин оешмалар тарафыннан бернинди теләктәшлек тә булмау, курсларда укытырга акча бүлеп бирелмәү һ.б. сәбәпләр аркасында, күп эш ярты юлда гына калдырыла.

4.3.12. Чистай кантоны — 12 кантон арасында татар халкы иң аз санны тәшкил иткән кантон. Биредә татарлар чагыштырмача күп санны били — 21,8% (Сб., 1925, с. 86). Чистай кантоны волостьлар күплеге белән дә аерыла, бу яктан ул Арча кантонынннан кала икенче урында тора. Волостьлар эреләнгәнче, кантонда 23 волость булып, 1924 елда 17 гә калган (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 118). 17 волость арасында 6 сы — 51-81% татарлы һәм шуларда татар теле актив гамәлгә кертелергә тиеш була. 2 волостьта татар халкы 42-45% ны алып тора, ә калган 9 волостьта исә руслар зур күпчелекне тәшкил итә: 2 сендә — 31-37%ны (Сб., 1925, с.81).

Чистай кантонына гадәттә ТТГК эшләре буенча иң арттагы кантоннарның берсе дигән бәя бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 89). Кантон учреждениеләренә карата әлеге бәяләмә бик урынлы булса да, татар волостьлары хакында алай әйтү бик үк дөреслеккә туры килеп бетмәс иде. Чөнки 6 татар волосте (Каргалы, Иске Чаллы, Иске Әлмәт, Яңа Адәм, Мөслим, Күтәмә) инде 1924 елга ук бөтен эшләрен татар теленә күчереп бетерәләр (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 118), шулай ук 45% татарлы Чулпан волосте да татарлаштырылу алдында тора (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 89). Рус волостьларыннан хисапланган Аксубайда да рәиснең татар булуы ТТГК эшләренең байтагы үтәлүгә ярдәм итә, мәсәлән, татарча гаризалар кабул ителә, татар авылларына җибәрелә торган кәгазьләр татарча языла (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 88). Татар волостьларының электән үк эшләрен татар телендә йөрткәннәрендә ТТГК бик яхшы бара, ә 1924 елның 1 маеннан башлап кына татарча эшли башлаганнарында исә (Иске Чаллы, Яңа Адәм, Күтәмә) бары татар эшчеләре җитешмәү аркасында гына кайбер уңайсызлыклар чыккалый. Кантон комиссиясе, бу уңайсызлыкларны бетерү максатында, эшләрен электән үк татарча йөртә торган волостьларга эшкә өйрәнү өчен 4

практикант билгели һәм алар бераздан ТТГК акрынрак барган волостьларга эшкә җибәрелергә тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 84).

Әлеге уңай яклар белән беррәттән, ҮК инструкторы Юнысовның 1924 елның 11 маенда Чистай кантоны волостьларын тикшерү нәтиҗәләреннән түбәндәге җитешсезлекләрне дә күрергә мөмкин: барлык волостьларда да хәрби эшләр рус телендә генә алып барыла, күп каршылыклар бигрәк тә суд, тикшерү һәм милиция участокларында барлыкка килә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 80). Мәсәлән, татар волостьларында милиция начальниклары булып руслар гына эшли, ә рус волосте булган Иске Чишмәгә район милиция начальнигы итеп татар кешесе җибәрелә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 80). Татарлар арасында эшләүче милиционерларның руслар гына булуы эштә ифрат зур уңайсызлыклар тудыра. Шулай ук сорау алу вакытында русча җавап бирә алмый газапланган татарларга кайбер милиционерларның «татарин гололобый» дип кычкырыну очраклары да күзәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 87). Бу эшләрнең барысы да каты тәнкыйть ителгәннән соң, 6 татар волостена да татар милиция начальниклары һәм аларның канцелярияләрендә эшләр өчен 6 татар эш башкаручысы эзли башлыйлар һәм комиссия аларның табылуына ышаныч белдерә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 84).

Чистай шәһәрендәге кантон бүлекләре һәм учреждениеләрендә исә хәлләр тагын да катлаулырак була. Бары мәгариф бүлеге генә татар теле яхшы гамәлгә куелган оешмалардан санала ала, шулай ук җир эшләре, акча эшләре бүлекләрендә, бөтенләй үк булмаса да, татарча гаризалар кабул итү, аларга татар телендә җавап кайтару кебек эшләр тәэмин ителә (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 84).

Финанс бүлегендә 1924 елның апреленнән алып волбашкармалардан килгән татарча язулар кабул ителә башлый,

ләкин хосусый тәрҗемәче булмау сәбәпле, үтәлгәнче шактый вакыт уза. Татар волостьларына финагентлар итеп күбрәк руслар җибәреләә, алар үзләре үк татар халкы арасында эшләргә уңайсызланалар. Үзәк курсларга финанс бүлегеннән 2 генә кеше җибәрелеп, алары да «барасылары килгән вакытта гына барганнар». Халык арасына таратыла торган игъланнар да бары рус телендә генә языла (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 87).

Милиция идарәсе Чистай кантонында иң артта калган оешма дип күрсәтелә. Татарча гаризалар кабул ителми, сорау алулар, беркетмәләр — һәммәсе русча языла. Милиция идарәсе бөтен кантон буенча 6 районга бүленеп, берсендә дә татарлар эшләми. Кантмилиция үзенә эшчеләр хәзерләү өчен курслар да ачып караган, ләкин 2 генә татар килгән. Халык арасына таратыла торган боерыклар һәм карарлар, Чистайның үзендә татар хәреф җыючысы һәм татарча хәрефләр булса да, русча гына таратыла (ф. 732, оп. 1, д. 530, лл. 86-87).

Кантондагы кооператив оешмаларны татар халкына якынлаштыру эшенә дә һич игътибар ителми. Мәсәлән, райсоюзның 17 авылда кооператив кибете, 6 авылда кредит ширкәте булып, алар крестьяннарны кирәкле товарлар һәм авыл хуҗалыгы кораллары белән тәэмин итү максатына хезмәт итсәләр дә, бу 23 кибет һәм ширкәт арасыннан бары бер генә ширкәт татар авылында (Мөслимдә) урнаша. Моның сәбәбе дә бик кызык аңлатыла: авыллар буйлап йөреп, кибет һәм ширкәтләр ачарга кирәклекне аңлатып йөрүче һәм бу эшләрне оештыручы инструкторларның икесе дә рус милләтеннән, татар авылларында аларны, билгеле, бер кеше дә юньләп аңламый, шуннан соң инструкторлар, «татар аңламый» дигән бер карарга килеп, татар авылларына бер дә керми башлаганнар. Кантон ТТГК комиссиясе бер татарны инструктор

итеп куярга тәкъдим итсә дә, «безгә инструкторларны Татсоюз гына билгели» дип, райсоюз кабул итми (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 86).

Чистай кантонында барысы 5 суд участогы булып, шуларның берсендә генә эшләр саф татарча алып барыла. Бу участокка Мөслим, Каргалы, Яңа Адәм волостьлары һәм шәһәрнең татар районнары керә. Тагын ике татар участогы ясарга ихтыяҗ бик зур булганлыкны игътибарга алып, прокурор тарафыннан проект төзелә. Әлеге проект кантон башкарма комитеты, кантон комиссиясе утырышларында расланып, Казанга җибәрелә, ләкин Баш суд бу эшне расларга теләмичә, озакка суза (ф. 732, оп. 1, д. 537, л. 118; д. 530, л. 86).

Кантонда татар эшчеләренә ихтыяҗ бик зур булса да, аларны әзерләү юлында бер эш тә эшләнми. Кантон башкарма рәисе: «Без татар эшчеләре җитештерү өчен курслар ачарга җыенабыз, шулай булса да һаман да ачып бетерә алганыбыз юк», — дип аклана (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 87). Үзәк курсларга кеше җибәреп торалар, ләкин волостьлар бу хактагы хәбәрләрнең бик соң килүеннән яисә бөтенләй килеп җитмәвеннән зарланалар (ф. 732, оп. 1, д. 530, л. 88). Курслардан укып кайткан эшчеләрнең дә күбесен, эшкә яраксыз табып, оешмалар кабул итәргә теләми. Руслар өчен ачылган татар теле курсларының да бертөрле дә нәтиҗәсе булмый (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 117).

Күренгәнчә, Чистай кантонындагы татар волостьларында 1924 елга ук татар теле кертелеп бетсә дә, кантон учреждениеләре әлегә эшкә бик салкын карыйлар, кантон өчен татар хезмәткәрләре әзерләү мәсьәләсенә дә игътибар ителми.

4.4. Нәтиҗәләр.

1. Кантон, волость һәм авыл советларында ТТГК процессын чагылдырган мәгълүматлар 20 нче еллар буенча гына табылды,

шунлыктан бу бүлекчәдә 30 нчы елларны читләтеп үтәргә мәҗбүр булдык.

2. Әлеге оешмаларда ТТГКның торышына күзәтү 20 нче еллар буенча архивларда сакланган ҮК яки кантон инструкторлары тикшерүләре, шулай ук ҮК хисаплары нигезендә ясалды. Күп мәгълүматларның бик үк объектив булмавы, чыганаклар арасында фикер төрлелеге хөкем сөрү эштә авырлык тудырды.

3. Чыганаклардан күренгәнчә, ТТГК иң түбән совет оешмаларыннан — авыл советлары һәм волостьлардан башланып китә. 1922 елдан алып даими рәвештә кантон, волость һәм авыл советларында татар телен файдалануга багышланган карарлар чыгып килә.

4. Хөкүмәт карарлары нигезендә, татар авыл советлары һәм волостьларында татар теле актив кулланылышка кертелергә тиеш була, ягъни төп эш башкару татар телендә урнаштырылып, рус азчылыгы өчен телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрне кабул итү һәм аларга җаваплар бирү рус телендә тәэмин ителә. Татар халкы азчылыкны тәшкил иткән авыл советлары һәм волостьларда исә төп эш башкару рус телендә калдырылып, татарлар белән аңлашу татар телендә булдырыла.

5. Татар авыл советлары һәм волостьлары 1922 елның ахырына ук татар телен гамәлгә кертеп бетерергә тиеш булсалар да, бу эш бары 1928 елга гына тәгәлләнә ала, анда да күпчелек волостьларда хәрби һәм налог эшләре рус телендә калдырыла.

6. Татарстан 20 нче елларда 12 кантонга бүленгән була, аларның 7сендә татар халкы күпчелекне тәшкил итә һәм шул нигездә барлык эш йөртүләр татар телендә башкарылырга тиеш була. Руслар күпчелекне алып торган кантоннарда исә эш башкару рус телендә калдырыла.

7. Кантоннарда ТТГК эше белән кантон башкарма комитетлары һәм кантон ТТГК комиссияләре җитәкчелек итә. Канткомиссияләр 1922 елдан төзелә башлый, аларның составына баштарак 3әр әгъза, 1925 елдан 5әр кеше кертелә. Канткомиссияләр кантонда зур хокукка ия булалар.

8. ТТГК буенча бишьеллык перспектив план нигезендә, татар кантоннарының барлык бүлек һәм оешмалары да 1927 елга кадәр тулысынча татар телендә эш йөртүгә күчеп бетәргә тиеш булсалар да, бу план тормышка ашмый, бары 70% татарлы Мамадыш һәм Минзәлә кантоннарында гына үтәлү алдында тора.

9. Күп чыганакларны чагыштыру нәтиҗәсендә, ТТГК буенча иң алда барган кантоннар исемлегенә Мамадыш, Арча, Чаллы, Минзәлә һәм Бөгелмә кантоннарын кертергә мөмкин. Буа һәм, татарларның саны буенча иң соңгы урынны биләсә дә, Чистай кантоны да урта дәрәҗәдә татарчалаштырылалар. Лаеш, Алабуга, Зөя һәм Спас кантоннары татар телен куллану ягыннан иң артта сөйрәләләр. Шулай ук, татар халкының саны 60%ны тәшкил итсә дә, Тәтеш кантоны да һәрвакыт тәнкыйть ителә.

10. Барлык кантоннарда да диярлек кантон башкарма комитеты, мәгариф бүлеге, гомуми һәм җир бүлекләре яхшы татарчалаштырыла.

11. Милиция идарәләре бары Бөгелмә һәм Зөя кантоннарында гына уңай яктан бәяләнә.

12. Финанс, сәламәтлек саклау, сан алу бүлекләре, почта-телеграф идарәләре, хәрби өстәл, кооператив оешмалар барлык кантонда да татар телен я бөтенләй кулланмыйлар, яки бик аз гамәлгә кертәләр.

13. Татар суд-тикшерү участоклары һәрбер кантонда ачыла, ләкин татар халкының ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү ягыннан бары Минзәлә һәм Зөя кантоннары гына алда бара.

14. Барлык кантон, волость һәм авыл советларында да ТТГКга тоткарлык ясаучы иң зур сәбәп итеп квалификацияле татар белгечләренең җитәрлек булмавы, булганнарының да, хезмәт хакы аз түләнү сәбәпле, эшкә керергә теләмәүләре күрсәтелә. Бер яктан, Үзәк курсларда укып кайткан хезмәткәрләрнең эшкә яраксыз булуы, икенче яктан, кантонның үзендә курслар оештыру өчен акча җитмәү дә хезмәткәрләр әзерләү мәсьәләсен хәл итәргә мөмкинлек бирми. Шулай ук ТТГК өчен махсус акча бүлеп бирелмәү, кантон оешмалары җитәкчеләренең татар телен куллануга бармак аша гына караулары, татарча шрифтлы язу машиналарының җитешмәве кебек сәбәпләр дә кантон, волость һәм авыл советларында татар телен дәүләт теле итүгә гаять зур комачаулык тудыралар.

## 5 бүлек. Татар телен гамәлгә кую Үзәк курслары һәм руслар өчен татар теле курс-түгәрәкләре эшчәнлеге.

5.1. <u>ТТГК Үзәк курслары</u>. Ике телдә дә эш башкара алырлык белемле хезмәткәрләрнең бөтенләй диярлек булмавы татар телен гамәлгә кертүнең киң җәелүен тоткарлап торучы зур сәбәпләрнең берсе була. Югары уку йортлары, эшче факультетлары, техникумнарга татарларны алуны күбәйтүнең кирәклеге күп ассызыклана, шул юнәлештә эш тә алып барыла. Ләкин уку йортларында укып чыгу өчен, әле шактый вакыт кирәк, ә тормыш инде хәзер үк татар телен белүче хезмәткәрләрне таләп итә. Шунлыктан Казанда ТТГК ҮК каршында 1922 елның июлендә Татар телен гамәлгә кую Үзәк курслары ачыла (Сб., 1925, с. 17). Ул ике юнәлештә эш итә: беренчедән, татар телен белүче кешеләрдән кирәкле белгечләр әзерләү, икенчедән, квалификациясе булган, ләкин татар телен белмәгән хезмәткәрләрне татар теленә өйрәтү. Ләкин ул вакыттагы архив, вакытлы матбугат мәгълүматларына игътибар итсәк, беренчесенең өстенлек алуын күрергә мөмкин.

5.1.1. <u>Курсларны төзү идеясе һәм максатлары</u>. Курсларны ачу идеясе ТҮБК җаваплы хезмәткәрләре арасында туа. Идеянең тормышка ашуына ТҮБК һәм ТТГК ҮК сәркатибе вазифаларын башкаручы, милләте буенча керәшен татары, ул вакытта 25 яшьлек Николай Петров зур ярдәм итә. Ул үз тирәсенә бу эшне башкарып чыга алырлык педагогларны җыя, Курсларны ачу һәм яшәтү өчен акча табу, эшкә юнәлеш бирү кебек чаралар да аның тарафыннан башкарыла (ф. 732, оп. 1, д. 531, л. 180).

Курслар башта вакытлы һәм кыска сроклы (1,5-2 айлык) буларак ачыла. 1922 елның 17 декабрендәге карар нигезендә, алар

даими эшләүче оешмага әйләнәләр. 2 айлыктан соң 3-4, 5-9 айлык курслар эшли һәм 1926 елдан алар 2 еллыкка үзгәртелә.

5.1.2. Төзелеше. Курсларда эшләүче хезмәткәрләрнең саны шактый күп: мөдирдән алып мич ягучы, ат караучы кебек түбән персоналга кадәр барлыгы 61 кешедән тора (ф. 732, оп. 1, д. 531, л. 145). Барысының да эше һәм бурыч-хокуклары төгәл билгеләнгән. Мәсәлән, Курслар белән идарә итү мөдир һәм президиум тарафыннан башкарыла. Президиум составына Курслар мөдире, уку-укыту һәм административ-хуҗалык бүлекләре мөдирләре, укытучы һәм укучылардан берәр вәкил керә. Президиумга зур хокуклар бирелә: болар — укытучы яки хезмәткәрләрне эшкә алу яки чыгару, контроль комиссияләре булдыру, киңәшмәләр үткәрү, предмет һәм укыту комиссияләре карарларын кире кага алу, еллык смета төзү, барлык оешмалар белән бәйләнештә тору һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 280).

Моннан тыш, идарә итү эше белән Курслар советы да шөгыльләнә. Аңа Курслар президиумы, барлык укытучылар, укучылардан вәкилләр (укытучыларның биштән бере күләмендә), техник хезмәткәрләрдән, профсоюз һәм оешмалардан берәр вәкил керә. Совет президиумның хисап һәм планнарын, сметаны карый, хуҗалык эшләре, уку-укытуның гомуми мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә.

Укыту эшләре исә Курсларда предмет комиссияләре һәм Укыту бюросы аша алып барыла. Предмет комиссияләренә теге яки бу фән укытучылары һәм 50% күләмендә укучылар керә. Барлыгы 6 предмет комиссиясе төзелә: татар теле, математика, рус теле, география, җәмгыять белеме һәм машинкада басу буенча. Алар күбесенчә программаларны, укыту методикаларын тикшерү, укучыларның уку планын үтәүләре һ.б. буенча эш алып баралар.

Укыту бюросы исә предмет комиссияләренең эшчәнлеген яраштыру, уку-укыту эшләрен яхшырту кебек мәсьәләләр белән шөгыльләнә һәм аның составына уку-укыту бүлеге мөдире, предмет комиссияләре һәм укучылар оешмалары вәкилләре керә (ф. 732, оп. 1, д. 778, лл. 281-283).

Шундый тотрыклы нигезгә корылган Курслар бик күп белгечлекләр буенча татарча эш башкара алырлык хезмәткәрләр әзерли. Аларны санап китү генә дә күп урынны ала: кооператорлар, хисапчылар, финанс, налог, страховкалау һәм статистика агентлары, волость хезмәткәрләре, авыл советы сәркатипләре, татар һәм рус телләрендә эш йөртүчеләр (делопроизводители), машинкада басучылар, почта-телеграф, канцелярия, профсоюз эшчеләре, хәрби эш йөртүчеләр, суд хезмәткәрләре һ.б. Нинди дә булса берәр белгечлек буенча үткәрелгән курсны цикл дип атыйлар. Бу цикллар кемнеңдер теләге буенча ансат кына җыелмый, ә барлык Халык комиссариатлары, үзәк оешмалар, кантоннардан татарча белә торган хезмәткәрләрнең саны һәм нинди категориядә ничә белгеч кирәклеге турында мәгълүмат җыела. Шуның нигезендә Курслар президиумы комиссариатлар вәкилләре белән берлектә уку планы төзи. Теге яки бу циклны укыту чыгымнарының да күпмедер өлешен татар белгечләренә мохтаҗ оешма яки комиссариатлар үз өстенә ала. Мәсәлән, хисапчылар циклын Финанс комиссариаты, страхагентларны — Татстрах, статистларны — Статистика идарәсе, кооператорларны — Татсоюз һәм Авыл хуҗалыгы кредит-промышленность союзы финанслый һ.б. (ф. 732, оп. 1, д. 532, л. 13). Бу оешмаларны икенче төрле «кызыксынган оешмалар» дип атыйлар.

5.1.3. Кабул итү шартлары. Циклны ачар алдыннан, барлык дәүләт учреждениеләренә, кантоннарга Курсларның кабул итү

шартлары җибәрелә. Бу шартлар буенча, Курсларга 18 яшьтән зуррак ир яки хатын-кызлар кабул ителә. Белем дәрәҗәләре 1 нче баскыч мәктәптән дә түбән булырга тиеш түгел (ф. 732, оп. 1, д. 532, л. 19).

Курсларга махсус комиссия тикшерүе үтеп кенә кабул ителә алганнар. Укырга теләүчеләр татар һәм рус телләрендә йөгерек һәм аңлы рәвештә укый, сөйли һәм яза белергә тиеш булалар. Язуда төп игътибар эчтәлекне бирә алуга юнәлтелә, ә хәреф хаталары исә киртә булып тормыйлар. 1926 елда бу мәсьәләдә керү шарты азрак үзгәрә: татар сөйләм телен белеп, татарча уку һәм язулары начар булганнар да, беренче яртыеллыкта ук өйрәнү шарты белән кабул ителәләр (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 186). Татар һәм рус телләреннән тыш, кабул ителүчеләрдән арифметиканың дүрт гамәлен белү, сәяси аңлылык таләп ителә. Аларның гомуми белем дәрәҗәсенә, социаль чыгышына, партия яки комсомол әгъзасы булуына, физик яктан сәламәтлегенә зур игътибар бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 532, л. 176). Хәтта кабул ителгән курсантларны да уку барышында мулла яки хәлле кеше баласы булганы өчен генә дә чыгарып ташлый алганнар. Шунлыктан, мәсәлән, 1925 елгы 5 цикл курсантларының 98%ын эшче һәм крестьяннар, 55%ын РКП(б) һәм РЛКСМ әгъзалары тәшкил итә дә (За 5 лет, 1925, с. 37). Тагын да тулырак күзаллау өчен, шул ук 1925 елның 1 январена курсантларның саны — 168: 142 ир һәм 26 хатын-кыз; чыгышы буенча: 150 крестьян, 16 эшче һәм 2 — башкалар дип кенә куелган; 6 — РКП(б) әгъзасы яки кандидаты, 83 — РЛКСМ әгъзасы, 79 — партиясез; белем дәрәҗәләре ягыннан: 130 — башлангыч белемле, 35 — урта белемнән түбән, 3 — урта белемле (За 5 лет, 1925, с. 44).

Тырма яки станоктан гына килгән кешенең белеме ни дәрәҗәдә булуы билгеле инде. Шунлыктан курсантлар белән укытучыларга

көненә 10ар сәгать шөгыльләнергә туры килә. Шул чор идеяләренә бирелгәнлек исә курсантларда артыгы белән була.

Курсларда уку бушлай алып барыла. Моннан тыш, курсантлар тулай торак, өстәл, урын-җир әйберләре, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре һәм стипендия белән тәэмин ителәләр. Өс һәм аяк киемнәре бирелергә тиеш булмый, ләкин аеруча начар хәлле курсантларга бирелү очраклары да була (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 101).

5.1.4. Әзерләгән белгечлекләре һәм чыгарылышларга күзәтү. Курсларның нинди белгечләр әзерләвен ачыграк күз алдына китерү өчен, 1926 елга кадәрге 15 чыгарылышны аерым-аерым карап үтик. Аларда барлыгы 786 курсант белем алып чыккан.

Беренче чыгарылыш 1923 елның 1 январенда була. 11 кеше хисапчы дәрәҗәсен алып чыга һәм барысы да төрле оешмаларга эшкә урнаштырыла.

Икенче чыгарылыш 1923 елның 23 мартында 25 керәшен укытучысы белән була. Революциядән соң «Ильминский транскрипциясе»н кире кагып, татар язуына күчәргә теләк белдергән керәшен җаваплы хезмәткәрләренең съездларда бу хакта кабул иткән карарларының дәвамы буларак җыела бу курслар. Моннан тыш, беренче 3 елда Курсларның мөдире керәшен булу һәм укуларның Керәшен педогогик техникумында узуы да, бу турыда ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, зур роль уйнагандыр. Бу курслар 3 тапкыр оештырыла һәм керәшен укытучыларын татар язуына, укыту методикасына өйрәтү максатын күздә тота. Татарстан керәшен мәктәпләренең барлык укытучылары да курста укыйлар, һәм 1923/24 уку елыннан ук инде мәктәпләрдә татар язуы махсус предмет буларак үтелә башлый, ә кайбер урыннарда исә ул төп язуга әйләнә.

ТАССРның 3 еллык юбилее уңае белән өченче чыгарылыш әзерләнә. 96 кеше 3 цикл: волость, суд һәм налог хезмәткәрләре

дәрәҗәсен алып чыгалар. Барысы да Эчке эшләр, Юстиция яки Финанс комиссариатлары тарафыннан эшкә алына, икесе кантон финанс бүлеге мөдире итеп билгеләнә.

Дүртенче чыгарылыш 1923 елның 15 августында керәшен укытучылары белән була.

1924 елның 21 январенда булган бишенче чыгарылышта 18 кеше бухгалтер-хисапчы, 23 кеше волость хезмәткәре исемен алып чыга. Хисапчылар Финанс комиссариаты, ә волость хезмәткәрләре Эчке эшләр наркоматы тарафыннан эшкә билгеләнә.

Алдагы бурыч булып страховка эшчеләрен хәзерләү тора, чөнки бу вакытта татар һәм рус телләрен белгән хезмәткәрләр әлеге өлкәдә бөтенләй булмый. Татар авылларында эшли алырлык, крестьяннарның тормышын һәм психологиясен яхшы белгән 23 курсант 1924 елның 18 апрелендә укуларын бетереп чыгалар һәм шунда ук Татстрах тарафыннан страхагент яки практикант булып төрле урыннарга эшкә билгеләнәләр (ф. 732, оп. 1, д. 531, лл. 180-182).

Әлегә кадәр татар телен гамәлгә кую эше бөтенләй куелмаган кооперативлар турында 1924 елның апрелендә махсус карар чыгарыла (Сб., 1925, с. 20). Карарның дәвамы буларак, 1 июньдә Курсларның җиденче чыгарылышы кооперация хезмәткәрләрен әзерләүгә багышлана. 7 ай ярым уку дәверендә алар әзерлекле белгеч булып чыгалар һәм Татсоюз, Селькредпромсоюз оешмаларына эшкә алыналар.

10 июльдә тагын керәшен укытучылары катнашында сигезенче чыгарылыш була. Ул узган елгы курсларның дәвамы буларак, ләкин тулырак күләмдә үтә. Укытучылар 1 нче баскыч мәктәпләрдә татар теле укыта алырлык белем алып чыгалар.

10 августта булган тугызынчы чыгарылыш кооперация һәм канцелярия цикллары буенча белгечләр әзерли. Канцелярия циклын бетерүчеләр волость яки кантон башкарма комитетлары сәркатипләре, волостьта татар һәм рус телләрендә эш башкаручы яки хисапчы дәрәҗәләрен алып чыгалар. Мәгълүматлар буенча, шунда ук эшкә урнаштырылалар (ф. 732, оп. 1, д. 531, л. 182).

Алга таба да бер-бер артлы яки параллель рәвештә төрле цикллар эшли. Гомумиләштереп әйткәндә, 1923 елда барлыгы 130 белгеч әзерләнә, шуларның 42се — волость, 32се — суд, 22се — налог хезмәткәре, 34е — хисапчылар һәм эш башкаручылар.

1924 елда 156 белгеч әзерләнә: 18 хисапчы, 23 волость хезмәткәре, 23 страхагент, 43 кооперация буенча инструктор һәм хисапчы, 45 волость һәм кантоннар өчен канцелярия эшчесе.

1925 елда әзерләнгән 190 хезмәткәрнең 33е — налог эшчесе, 59ы — хисапчы, 28е — хәрби эш башкаручы, 32се — почта-телеграф хезмәткәре, 38е — волость сәркатибе дәрәҗәсен алып чыгалар (За 5 лет, 1925, с. 44).

5.1.5. Уку юнәлешләре. Курсларда уку 2 төп юнәлештә алып барыла: гомуми белем фәннәре һәм махсус предметлар.

Гомуми белем фәннәре барлык цикллар өчен дә диярлек уртак була: татар һәм рус телләре, математика, җәмгыять белеме, экономик география, кайберләрендә өстәмә рәвештә татар һәм рус телләрендә эш башкару, политэкономия, РКП(б) тарихы, СССР конституциясе кебек предметлар укытыла. Бу фәннәрнең планы президиум, ә программасы предмет комиссияләре тарафыннан төзелә һәм ТТГК ҮКдан раслана (ф. 732, оп. 1, д. 531, лл. 180-182).

5.1.5.1. Татар теленең урыны. Ана телебезгә мөнәсәбәттә карасак, татар теленә һәрвакыт рус теле белән чагыштырганда азрак сәгать бирелә. Мәсәлән, 1924 елгы 3 айлык кооператив циклда татар

теленә — 120, рус теленә — 150 сәгать бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 778, лл. 217-218). Вакыт узу белән, бу күренеш үзгәрми. Азрак алга китеп, 1926 елга күз салыйк. Бу вакытта инде Курслар 2 еллык була. Укуның беренче елында татар теленә 120 сәгать, рус теленә 180 сәгать бирелә, икенче елда бөтенләй аз: татар теленә — 60 сәгать (атнага 2 сәгать кенә), рус теленә — 120 сәгать (атнага 4 сәгать күләмендә) (ф. 732, оп. 1, д. 778, лл. 217-218). 1926/27 уку елы өчен төзелгән әлеге планны тикшергәндә, татар теле укытучысы Х.Вәлиевнең татар теле өчен бирелгән сәгатьләр аз дип чыгуына карамастан, Курслар президиумы моңа игътибар итми, план шул килеш раслана (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 267).

Татар теленә ни өчен азрак сәгать бирелүе беркайда әйтелмәсә дә, моны аңларга мөмкин. Архивларда сакланган исемлекләрдән күренгәнчә, Курсларда укучыларның күпчелеген татарлар тәшкил иткән. Бигрәк тә чын татар авылларыннан килгән курсантлар өчен татар теле авыр фән булып тормаганга, рус теленә күбрәк игътибар бирелгәндер, мөгаен. Шулай да, 1926 елда, Курсларда инде руслар да шактый күренә башлаган вакытта, татар телен һаман икенче планда калдыру һич аңлашылмый.

Курсларда махсус фәннәрнең укытылуына килсәк, алар циклның төренә карап аерыла. Мәсәлән, хисапчылар циклында бухгалтерия, коммерция арифметикасы, бюджет эше, дәүләт контроле нигезләре кебек тар белгечлек предметлары укытыла (ф. 732, оп. 1, д. 522, лл. 3-6).

5.1.6. <u>Курсларда укытучылар</u> баштарак махсус чакыру буенча, билгеле бер күләмдәге сәгатьләр укыту өчен вакытлыча гына эшлиләр. Ләкин Курслар бетүгә эшсез кала торган, матди яктан да кызыксындырыла алмаган укытучылар бөтен күңелләрен биреп укыта алмыйлар. Курсларның шәһәр читендә урнашкан булуы да

өстәмә кыенлыклар тудыра. Шул сәбәпләр аркасында тәҗрибәле укытучылар анда эшләүдән баш тарталар (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 77). Бу хәл Курсларның эшен авырайта. Өзлексез яңа укытучылар эзләүдән котылу һәм тәҗрибәле укытучыларны эшкә тартып, аларны матди яктан кызыксындыра алу максатында, 1926 елның 1 октябреннән гомуми фәннәр буенча 16 штатлы укытучы алына (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 77 об.). Аларның барысы да диярлек зур педагогик стажлы, Курслардан тыш, техникумнарда, партия мәктәбендә, 2 нче баскыч мәктәпләрдә укыталар. Милләтләре буенча 16 укытучының 13е татар (шуларның 5се — керәшен татары), 3 укытучы гына рус милләтеннән була. Кызганычка каршы, укытучылар турында 1926 елның 1 январенда Курслар мөдире Хәмидуллин тарафыннан язылган характеристикадан башка мәгълүмат юк диярлек. Аның исемлегендә 3 татар теле укытучысы бар. Шуларга аерым-аерым тукталыйк: Вәлиев Х. — урта белемле, 10 еллык педагогик стажлы, партиясез, башка җирдә дә эшли, эшен канәгатьләнерлек алып бара, кечкенә кимчелеге бар: тотлыга, фәнен ярата һәм белә. Хисмәтуллин А. — урта белемле, 5-6 еллык педагогик стажлы, партиядә. Кантонда да, үзәктә дә профлиния буенча күп эшләгән. Бөтен күңелен биреп эшли, ләкин педагогик эшчәнлегендә методик агымнардан берникадәр артта калу күзәтелә, ләкин яхшыра бара. Биккулов И. — урта белемле, 16 еллык педагогик стажлы. Башка җирдә дә эшли, тыңлаучылар тарафыннан кире фикерләр юк.

Татар теле укытучыларыннан тыш, 4 рус теле укытучысы (шуларның 3се — керәшен татары: 3 ел Курслар мөдире булып торган, бу вакытта Керәшен педагогик техникумы мөдире Горохов В., рус теле белгече, тәҗрибәле, татарларга рус телен бик яхшы өйрәтүче Даулей Г., Курсларда гына эшләүче, ветеринария буенча

югары белемле Косьмин Г.), 4 математика укытучысы (араларында зур галим, педагог, рус һәм татар телләре, математика укыту буенча күп дәреслекләр авторы Корбангалиев М., Гыйльми үзәктә дәреслекләр төзү комиссиясе әгъзасы Нигъмәтуллин С. да бар), 2 — экономик география, 1 — җәмгыять белеме, 1 — бухгалтерия укытучылары исемлеге китерелә һәм аларга да уңай бәя бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 68).

Махсус фәннәр укытучылары исә теге яки бу циклны оештыруга матди ярдәм күрсәткән оешмалар тарафыннан вакытлыча эшләү өчен чакырыла һәм акча белән тәэмин ителә. Шулай ук махсус предметларның план һәм программалары да Курслар һәм шул оешмалар катнашында төзелә. Бу фәннәрне укытучыларның барысын да диярлек руслар тәшкил итә, чөнки татарлар арасында югары белемле, квалификацияле, Курсларда, мәсәлән, финанс хокукы, бухгалтерия, кооперация кебек фәннәрне укыта алырлык белгечләр булмый (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 77). Шунлыктан махсус предметлар русча укытыла һәм бу күпчелеген авылдан килгән татарлар тәшкил иткән курсантлар өчен авырлык тудыра.

5.1.7. Курсларның эшен татарчалаштыру. 1924 елның 10 мартында «Татарстан» газетасында Курсларда укыту рус телендә алып барылу нәтиҗәсендә, курсантларның нәрсә үткәннәрен аңламаулары, эшнең продуктивлыгы, укучыларның үзләштерү дәрәҗәсе кимүе хакында кечкенә генә мәкалә басыла. Шуңа җавап рәвешендә ТТГК ҮКга юллаган хатында Курслар мөдире Горохов президиумның инде күптән махсус фәннәрне татар телендә укыта алырлык кешеләр эзләве, ләкин нәтиҗәсе һаман юклыгы турында ачынып яза. Курсантларның берни дә аңламавы фикеренә каршы килә. Үзләренең гомуми җыелышларында курсантлар теге яки бу предметны укытудагы кимчелекләргә шунда ук үз бәяләрен бирәләр

(ф. 732, оп. 1, д. 531, л. 40). Димәк, аңламасалар, шунда ук бу турыда уку-укыту бүлегенә хәбәр иткән булырлар иде.

Шулай да чынбарлык шуны күрсәтә: хәтта Татар телен гамәлгә кую курсларының үзендә дә уку планнары, программалар, сметалар, айлык һәм еллык хисаплар рус телендә язылa. Бик аз сандагы кәгазьләр: президиум беркетмәләре һәм кайбер хатлар гына татар телендә алып барыла (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 259). 1926 елның 16 февралендә генә президиум утырышы Курсларның эшен мөмкин кадәр татарчалаштыру турында карар кабул итә (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 312). Бу карар нигезендә, ТТГК ҮК, кантоннар, барлык учреждениеләр белән элемтәләрне татар телендә йөртергә тырышырга, Курсның эчендә курсантлар арасында эшне татарча алып барырга кирәк була. Моннан тыш, татар теле түгәрәгенә катнашмый һәм татар телен начар укый торган курсантларга президиумның иң ахыргы чараларга керешәчәген аңлатырга, татар телен өйрәнү түгәрәгенә катнашуларын мәҗбүри итәргә дигән карар да шул ук утырышта кабул ителә (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 141).

ТТГК ҮКның 1926 ел, 21 августтагы карары нигезендә, Курсларда эш башкару татар теленә күчерелә. Карарның дәвамы буларак, татар сөйләм телен һәм язуын белмәгән хезмәткәрләр эшләреннән азат ителәләр (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 312). Курсларны татарчалаштыру хакында башка мәгълүматлар юк.

5.1.8. Курсантлар тормышы. Курсантлар укудан тыш ни белән шөгыльләнгәннәр соң? Сакланып калган чыганаклардан күренгәнчә, курсантлар көненә 10-12шәр сәгать укыганнан соң да актив эш алып барганнар. Алдарак Курсларның төзелешенә тукталганда күргән идек: президиум составына да, совет, укыту бюросы, предмет комиссияләренә дә укучылардан вәкилләр керә. Алар үз фикерләрен әйтергә хокуклы булалар. Моннан тыш, курсант оешмалары бюросы

киң эш җәелдереп җибәрә. Бюро 3әр курсанттан торган 4 комиссиягә һәм 10 кешелек 1 комиссиягә бүленә. Аларның һәрберсе төрле тармак буенча эш алып бара: хуҗалык комиссиясе Курслар ашханәсендәге тәртип, продуктларны дөрес алу һәм бүлүне күзәтү белән шөгыльләнә.

Санитар комиссиясе тулай торакларның санитар хәлен тикшереп, актлар төзи, урын-җир әйберләрен җыю һәм тапшыру вазифаларын да үти.

Мәдәни-агарту комиссиясе драмтүгәрәк оештырып, спектакльләр, концертлар кую, уку залы, төрле фәннәр буенча почмаклар ясауны башлап йөри, стена газетасы чыгара. Курсантлар өчен газеталар алдыру да аның карамагында була.

Иптәшләр суды курсантлар арасындагы төрле конфликтларны хәл итә, кайбер укучыларның социаль чыгышы мәсьәләсен дә игътибардан читтә калдырмый.

Старостат составына исә 10 кеше керә: аларның 7се — группаларның старосталары. Старостат тәртип саклау, аерым группаларда көндәлек алып бару эшләрен башкара. Курсантларның дәрескә йөрүләре югары класслар аркылы исәпкә алына, алар һәр ай ахырында укытучыларның класс журналына куйган билгеләре буенча мәгълүмат туплап, Курсларның Уку-укыту бүлегенә тапшыралар (ф. 732, оп. 1, д. 778, лл. 81-82).

Күренгәнчә, Курсларда уку-укыту эше дә, идарә итү, курсантларның укудан тыш эшләре дә тәртипле, системалы рәвештә, оешкан төстә алып барыла. Тәртип бозу проблемасы булмый диярлек. Курсантлар дәресләргә йөриләр, практик эшләргә актив катнашалар (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 80). Мәсәлән, статистика циклы курсантлары, гомуми фәннәр буенча белем алганнан соң, тулай торaклардагы курсантларның санын статистика фәне таләпләре

нигезендә исәпкә алалар. Яки кооператив циклы курсантларының бер өлеше Авыл хуҗалыгы банкына бухгалтерия бүлеге эшчәнлеге белән танышу өчен барып, андагы кәгазьләрдән күп кенә цифрлы мәгълүматлар һәм материаллар күчермәсен алып кайталар һәм дәресләрдә файдаланалар (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 9). Моннан тыш, элемтә идарәләрендә, Главмилициядә, Татстрахта, Эчке эшләр комиссариатында һ.б. урыннарда практика уздырыла (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 169).

5.1.9. Түгәрәкләр. Курсантлар өчен Курсларда иҗтимагый-сәяси, табигать белеме, дингә каршы түгәрәкләр оештырылуы билгеле. Моннан тыш, рус телен начар белгән татарлар өчен рус теле, ә керәшеннәр һәм аз сандагы руслар өчен татар теле түгәрәкләре дә эшли. Түгәрәкләрдәге дәресләр атнага бер тапкыр, 2 сәгать күләмендә үтә. Курсантлар аларга канәгатьләнерлек йөри (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 79).

5.1.10. Махсус тикшерү комиссиясе. Цикллар тәмамланганнан соң, курсантлар тагын Махсус комиссия тикшерүе аша узалар. Комиссиягә циклны оештыруга катнашкан оешмалардан, ТТГК ҮКдан вәкилләр һәм укытучылар керә. Зачетларын уңышлы тапшырган курсантлар, белем дәрәҗәләренә карап, берничә категориягә бүленеп, таныклык алып чыга. Мәсәлән, 1924 елның 1 июнендә чыгарылган кооператив циклы курсантлары 3 категориягә бүленә: I категория — яхшы билгеләргә тәмамлаучылар — кооперация инструкторы; II категория — канәгатьләнерлек билгеләргә тәмамлаучылар — хисапчы дәрәҗәләрен ала; III категория — начар билгеләргә тәмамлаучыларга курсны тыңлаучылар исеме генә бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 523, л. 21).

Һәр цикл тәмамланганнан соң диярлек курсантлар, ТТГК ҮК, кызыксынган оешмалар, төрле учреждениеләр, партия, комсомол

вәкилләре катнашында тантаналы җыелыш үткәрелә, чыгарылыш кичәсе, табын оештырыла (ф. 732, оп. 1, д. 522, л. 9; д. 524, л. 1).

5.1.11. Курсантларны эшкә урнаштыру. Курслар курсантларны укытып чыгу белән генә чикләнмичә, аларны эшкә урнаштыру чараларын да күрә. Циклларны оештыручы һәм курсантларның бер өлешен эшкә алучы оешмалардан тыш, Курслар идарәсе әле укулар тәмамлаганчы ук төрле учреждениеләргә, банкларга цикллар, аларны бетерүче курсантлар хакында мәгълүмат җибәрә. Нәтиҗәдә, Курсларны бетереп чыккан белгечләр тиз арада эшкә урнаштырыла. Тик курсантларны эшкә алмау очраклары да бу вакытта еш күзәтелә. Мисал өчен 1924 елның 8 июлендә Габдулла Нигъмәтуллин исемле кешенең ТТГК ҮКга язган хатыннан өзек китерик. Ул ниндидер бер оешма мисалында язмый, ә гомуми хәлне сурәтли: «Комиссия бер татар хезмәтчесен берәр урынга командировать итсә, шул мөәссәсәнең (оешманың — З.К.) мөдире яки рәисе җибәрелгән хезмәтчене үзенең спецына (бухгалтер яки секретарена) җибәрә, ул, әлбәттә, бер рус булып, кәефенә килсә, кабул итә. Әгәр дә кәефенә килми икән, «безгә кул түгел — несоответствующий по назначению, яки штат тулган, урын юк» дип резолюция салуга да иренми...» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 127). Тагын конкретрак ике мисал: Авыл хуҗалыгы банкы 1926 елда кооператив циклны оештыруга катнашкан булса да, җибәрелгән 3 кешене «хезмәткәрләр кирәк түгел» сылтавы белән кабул итми (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 275). Яки тагын да элегрәк, 1924 елда, Чистай кантонына Курсларны бетереп кайткан эшчеләрнең күбесен эшкә яраксыз табып кабул итмәгәннәр (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 117). 1927 елның 12-13 мартында үткән ТҮБКның өченче сессиясендә дә Курсларны бетергән кешеләрнең эшсез йөрүе, аларны алырга теләмәүләре ассызыклана (Доклад, 1927, с. 27).

5.1.12. Курсларның эшен тоткарлаучы сәбәпләр. Димәк, курсантларны эшкә алмауга, бер яктан, кайбер оешма һәм аларның җитәкчеләре гаепле булса, икенче яктан, курсантларның әзерлек дәрәҗәсе, тәҗрибәсез булуы да оешмаларны канәгатьләндерә алмый. Өченчедән, кайбер курсантларның үзләренә бирелгән эш яки ставка белән килешмәгән очраклар да була. Дүртенчедән, бу вакытта учреждениеләрдә бара торган штат кыскарту процессы да яңа татар хезмәткәрләрен алуга комачаулык итә торган объектив сәбәпләрнең берсе була. Татарларны эшкә тартуга аеруча салкын карый торган оешмалардан бигрәк тә Халык хуҗалыгы советы, Коммуналь хуҗалык идарәсе, Азык-төлек тресты, Елга Флотының Казан агентлыгы, Урман тресты, Татторг исемнәре еш очрый (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 90).

Курслар эшен тоткарлаучы зур сәбәпләрнең тагын берсе — матди хәлнең кыенлыгы. Бу мәсьәлә Курсларның үзәгенә үткәнлеге архив материалларында ачык чагыла.

Курслар ачылганнан соң, баштарак ТҮБК акчасына яши. 1922 елның 1 октябреннән җирле бюджет тарафыннан финанслана башлый (ф. 732, оп. 1, д. 531, лл. 180-182) һәм бервакытта да төзелгән һәм расланган смета буенча тулы күләмдә акча ала алмый. Финанс комиссариаты тарафынан хезмәт хаклары, ашау-эчү, стипендия һәм социаль страховка өчен генә кредит ачыла, ә хуҗалыкны алып бару, уку кирәк-яраклары, канцелярия чыгымнары өчен бик авырлык белән генә, төрле оешмаларның бусагасын күп таптаганнан соң ала торган булалар, анда да тулысынча түгел (ф. 732, оп. 1, д. 531, л. 110; д. 778, л. 82). Хезмәт хакы да кичегеп түләнә, курсантларны ашату һәм стипендия өчен акча аз бирелә, медикаментлар юк, дәреслекләр, китапханә өчен әдәбият, җиһаз, савыт-саба, урын-җир әйберләре җитешми... Бу гына да түгел,

Курслар үзләренең биналары булмау белән озак вакыт азапланалар. Башта Керәшен педагогик техникумы бинасында укыйлар, аннары бер бинадан икенчесенә күчеп йөриләр. Тулай тораклар белән дә шул ук хәл була (ф. 732, оп. 1, д. 531, л. 181). Дөрес, кайчагында акчаның җиткән һәм эшнең гөрләп барган вакытлары да була. Әмма алар бик сирәк вакыйганы тәшкил итәләр (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 84).

Ачлыктан соңгы авыр, икътисади тотрыксыз заманда Финанс комиссариатын гына гаепләү дә дөрес була алмый. Икенчедән, төрледән-төрле цикллар белән эш итүче Курслар һәрвакыт күп чыгым таләп итәләр: курсантларның һәм махсус фән укытучыларының гел алмашынып торуы, һәр циклга яңа дәреслекләр, уку ярдәмлекләре кирәк булу, машинкада басу циклы өчен генә дә 6 башка цикл чыгымнары таләп ителү, гел яңа программа һәм уку планнары төзелү, бинадан бинага күчү нәтиҗәсендә ремонт ясату өчен күп акча китү һ.б.

Шундый зур авырлыклар белән булса да, Курслар үзләренең эшчәнлеген дәвам итәләр. Документлар буенча, Татар телен гамәлгә кую Курслары 1932 елга кадәр эшли (Языковая политика, 1998, с. 8). Ләкин 1926 елдан соңгы эшчәнлекләре турында тулы мәгълүмат юк. Бары 1931 елның 2 августында Курсларның хисапчылык, машинкада басу һәм страховка циклларын бетергән курсантларга бирелгән таныклыклар тупланмасы гына сакланган.

Таныклык зур форматлы калын һәм шома кәгазьдән гыйбарәт. Аның сул ягына латин хәрефләре белән татарча, уң ягына русча язылган, кырыйларына матур бизәкләр төшерелгән. Язу өчен кызыл һәм кара төсләр, төрле зурлыктагы хәрефләр файдаланылган (ф. 732, оп. 10, д. 88. — 113 л.).

5.1.13. Курсларның эш нәтиҗәләре, әһәмияте. Бик изге максатта башланып киткән эш шулай итеп 10 ел әле көчәеп, әле бик

сүлпәнләнеп дәвам итә һәм ахырда томаланып юкка да чыга. Язмышы кыска гомерле булуга да карамастан, Курслар төрле белгечлекләр буенча татар һәм рус телләрендә эшли алырлык хезмәткәрләр укытып һәм тәрбияләп чыгару юнәлешендә уңай нәтиҗәләргә ирешә. Курсларның да эшчәнлеге катнашында оешмаларда татар хезмәткәрләренең саны шактый үсә. ТАССРның Халык комиссариатлары һәм үзәк оешмаларында эшләүче татар хезмәткәрләренең санын (%ларда) 5 ел буенча чагыштырып карыйк (За 5 лет, 1925, с. 44):

| | Җаваплы хезмәткәрләр | Техник канцелярия хезмәткәрләре | Түбән персонал | Татар-ларның уртача %ы |
|---|---|---|---|---|
| 1921, 1 гыйнвар | 10,4 | 4,5 | 9,7 | 7,8 |
| 1922, 1 гыйнвар | 11,5 | 5,6 | 10,5 | 8,9 |
| 1923, 15 май | 15,6 | 6,7 | 12,1 | 9,7 |
| 1924, 1 июнь | 18,6 | 8,7 | 22,4 | 13,2 |
| 1925, 1 апрель | 20,0 | 11,5 | 21,2 | 15,4 |

Күренгәнчә, татарларның саны аз гына булса да артып торган һәм 4 ел эчендә % ягыннан ике тапкырга үскән. 1932 елга күз салсак, бу елда республиканың үзәк органнарында эшләүче җитәкчеләр

арасында татарлар 36% тәшкил иткән (Языковая политика, 1998, с. 8).

Курслар үз заманы өчен гаять әһәмиятле эш башкарганнар һәм 30 нчы елларда милләтләрне берләштерү идеясе, гомуми сәясәт җирлегендә юкка чыгарылмасалар, тагын да зуррак эш башкара алган булырлар иде.

Хәзерге вакытта да төрле белгечләр әзерли торган курслар шактый. Арасында татар һәм рус телләрендә эш башкаруга өйрәтә торганнарыннан суд сәркатибләре һәм сәркатиб-референт курсларын гына күрсәтергә мөмкин. Калганнарында исә укулар рус телендә алып барыла.

20-30 нчы еллардагы Татар телен гамәлгә кую Курслары тәҗрибәсенең аерым элементларын гына булса да файдалану ул заман белән аваздаш хәзерге чорда татарча эш башкара алырлык белгечләр әзерләү мәсьәләсен хәл итүгә ярдәм итә алыр иде.

5.2. Руслар өчен татар теле курс-түгәрәкләре. 1921 елның 25 июнендәге Декретка кадәр үк, шул ук елның 24 маенда Татарстан Халык комиссарлары Советы (СНК) президиумы утырышында Мәгариф комиссариатына өч атна эчендә татар теле курслары ачарга тәкъдим ителә (Языковая политика, 1998, с. 17). 25 июньдәге Декретның 4 нче маддәсендә дә теләгән хезмәткәрләр өчен татар теле курслары оештыру турында сүз бара (Сб., 1925, с. 5-6).

Шул вакыттан алып Татарстанның күпчелек үзәк оешмаларында, Халык комиссариатларында һәм кантоннарда рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү курс-түгәрәкләре оештырыла башлый. 1923-1924 елларда бу эш аеруча җанлана (Отчет к 5-му съезду, 1925, с. 38).

5.2.1. Курс-түгәрәкләрнең төп нигезләре. 1924 елның 23 декабрендә ТТГК Үзәк комиссиясе тарафыннан татар теле курс-

түгәрәкләренең төп нигезләре игълан ителә (Сб., 1925, с. 24-26). Курсларны оештыру эше баштарак, бигрәк тә 1921 елгы беренче декрет һәм карарларда Мәгариф комиссариатына тапшырылган булса, соңрак исә бу эш белән гомуми идарә итү вазифасын Казандагы ТТГК Үзәк комиссиясе башкара.

Курс-түгәрәкләр учреждение, предприятие хезмәткәрләрен татар сөйләм теленә, язарга, укырга, эш башкарырга һәм, гомумән, татар телендә телдән дә, язмача да үз фикерләреңне иркен бирә алуга өйрәтү максатында төзеләләр (Сб., 1925, с. 24). Дәресләрдә сөйләшү методы өстенлек алып торырга һәм оешма юнәлешендә эш алып барылырга тиеш була (Сб., 1925, с. 26).

Тиз вакыт эчендә һәм артык көч түкмичә генә татар теле өйрәнү теләге белән килгән рус хезмәткәрләре, билгеле инде, беренче авырлыклар алдында ук аптырап калалар. Үзәк комиссиянең түбәндәге аңлатмасы андыйларга бик яхшы җавап була алыр иде: «Татар теле дәресләре, түгәрәк утырышларында атнага 3-4 сәгать шөгыльләнеп, бу дәресләр күпме генә дәвам итсәләр дә, бөтенләй таныш булмаган телне практик максатларда куллана алырлык дәрәҗәдә өйрәнү һич мөмкин түгел. Татар теле — өйрәнү өчен бик ансат тел, ләкин бу рәвешле аны да өйрәнеп булмый. Бу курс-түгәрәкләр бары тик берникадәр күләмдәге сүзләр, аларның дөрес әйтелеше, фразаларның дөрес конструкциясе, телнең грамматикасы, шулай ук язу, уку һәм эш алып баруның трафарет формалары белән таныштыру өчен генә хезмәт итә алалар. Сөйләшә алуга килгәндә исә, бу бары тик телне игътибар белән, дәвамлы рәвештә һәм тырышып, баш күтәрмичә өйрәнгәндә, шактый күп практика һәм сөйләшү, уку һәм язу булганда гына мөмкин. Шуңа күрә тел белән гамәли яктан танышу тыңлаучының үзендә җитди теләк, вакыт һәм тел өйрәнү өчен шартлар булганда гына мөмкин. Киресенчә

булганда, еш күзәтелгәнчә, бу түгәрәкләр бары тик вакытны һәм акчаны бушка туздыру булып кына калалар» (Сб., 1925, с. 24).

Шуның нәтиҗәсе буларак, Комиссия фикеренчә, татар телен өйрәнү һәм курсларга йөрү беркем өчен дә мәҗбүри рәвештә үткәрелә алмый. Курслар җитди теләк һәм татар теленә өйрәнү мөмкинлегенә ия кешеләргә ярдәм итү өчен генә оештырылырга тиеш була (Сб., 1925, с. 24-25). Ләкин, кагыйдә буенча шулай булса да, рус хезмәткәрләренең татар телен өйрәнүгә бик салкын карауларын күреп, кайбер комиссариат һәм оешмалар татар теле өйрәнүне мәҗбүри итеп куялар. Мәсәлән, Күн тресты (Таткожтрест) 1924 елның 31 январендә шундый боерык чыгара: «Игътибарга алынмаслык сәбәпләр белән курсларга йөрмәгән хезмәткәрләргә җәза биреләчәк: беренче тапкыр дәрес калдырган өчен — каты шелтә, икенче тапкыр — бер көнлек хезмәт хакын Кызыл Һава флоты файдасына алып калу, өченче тапкыр — Татарстан үзәк башкарма комитеты карарына буйсынмаган өчен, бу хезмәткәрне эшеннән азат итү хакында трест идарәсенә һәм профсоюзга мөрәҗәгать итү» (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 45). Трестта эшләүче һәм татар теле курсларына мәҗбүри рәвештә йөрергә тиешле 68 кеше исемлеген китереп, Күн тресты тагын ике боерык чыгара (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 46).

5.2.2. <u>Халык комиссариатлары һәм үзәк оешмалардагы татар теле түгәрәкләре эшчәнлеге</u>. Эчке эшләр комиссариаты шулай ук 1924 елда барлык хезмәткәрләрнең дә мәҗбүри рәвештә татар теле өйрәнергә тиешлеге, начар йөргәннәргә эштән азат итүгә кадәр дәрәҗәдә административ җәза биреләчәге турында боерык игълан итә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 46).

Болардан тыш, Хезмәт комиссариты һәм Мәркәз ветеринария идарәсе дә хезмәткәрләр өчен татар теле курсларын мәҗбүри итеп куялар (ф. 732, оп. 1, д. 527, лл. 105, 108).

Бары административ чаралар ярдәмендә генә зур уңышларга ирешеп булмаячагы ачык аңлашылса да, шунысы кызык: Үзәк комиссиягә бирелгән мәгълүматларда нәкъ шул комиссариат һәм оешмалар хезмәткәрләргә татар теле өйрәтү буенча чагыштырмача алгырак сафта торалар. Шулай ук Элемтә идарәсе, Финанс комиссариаты, Тегү тресты идарәсе һәм Металл трестында эшләр яхшырак куелган була. Кайберләренә аерым-аерым тукталып үтик.

Элемтә идарәсендә татар теле курслары 1924 елда оештырыла (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 18). 1925 елның 1 январенә 50 кеше түгәрәк исемлегендә санала (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 54). 1925/26 уку елында 2 группадан торган курслар эшли: башлангыч һәм дәвам итүчеләр өчен. Беренче группага — 8, икенчесенә 30 кеше язылган була (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 18). Татар теле өйрәнүчеләр атнага ике тапкыр икешәр сәгать күләмендә шөгыльләнәләр. «Дәресләр шактый уңышлы бара, тыңлаучылар кызыксынып һәм яхшы йөриләр, белемнәре дә канәгатьләнерлек. Татар телен өйрәнүче руслар киләчәктә җирле халык белән татарча шактый җиңел аңлаша алырлар дигән өмет бар»,— дип хәбәр итәләр Элемтә идарәсеннән (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 4).

Бүгенге көн өчен уйландырырлык мәгълүмат: 1926 елның 1 июненә элемтә оешмаларында эшләүче рус хезмәткәрләренең 97се татарча белә: 20се укый, яза һәм сөйләшә ала, 77се — сөйләшә генә белә (ф. 732, оп. 1, д. 786, л. 58).

Алда әйтеп үтелгән Күн трестында 1924 елда 36лап кеше татар теле курсларына йөри. «Нәтиҗә яхшы, руслардан байтак кына кеше

укый, яза һәм сөйли беләләр»,— дип мәгълүмат бирелә (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 106).

Финанс комиссариатында эшләүчеләр өчен дә татар теле курслары эшли. 1924 елгы мәгълүматлар буенча, анда 42 кеше йөри һәм араларында укый-яза белүчеләр күренә башлый. Нәтиҗә яхшы, ләкин «җаваплы хезмәткәрләр укуларын дәвам итә алмаячаклар» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 107). 1925 ел башына 23 кеше татар теле өйрәнә (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 54). 1925/26 уку елында курсларга 17 кеше языла һәм аларның 11е атнага ике тапкыр даими рәвештә дәресләрдә катнаша (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 37).

Хезмәт комиссариатында 1924 елга кадәр үк татар теле курслары була. 1925 елда ул 2 группага бүленә: 1) әлифбадан башлап Тимофеев дигән кеше 18 хезмәткәрне укыта һәм 2) азмы-күпме әзерлекле 12 тыңлаучы белән укытучы Рәхимова шөгыльләнә (ф. 732, оп. 1, д. 783, л. 7).

Эчке эшләр комиссариатында 1925 ел башына 32 кеше татар теле түгәрәгенә йөри (ф. 732, оп. 1, д. 784, л. 54). 1925/26 уку елы өчен түгәрәк 27 октябрьдә генә оештырыла. Дәресләр атнага ике тапкыр, иртәнге сәгать 8дән 9га кадәр үтә. Язылган 20 кешенең 12се һәр дәрескә йөри. Хезмәткәрләр белән махсус чакыртылган укытучы шөгыльләнә (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 34).

Металл тресты идарәсендә, 1925 елгы мәгълүматлар буенча, 2 ел дәвамында, күбесенчә кыш көннәрендә, татар теленә өйрәтү курслары эшли. Аерым түләү белән укытучы итеп хезмәткәр Ибраһимов А. чакырыла. Хезмәткәрләрнең кайберләре шактый зур уңышларга ирешә, гомумән алганда, татар теле белән танышу үтәләр (ф. 732, оп. 1, д. 984, л. 10).

Тегү тресты идарәсе һәм фабрикалары хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү өчен, 1924 ел ахырында бирелгән мәгълүматлар

буенча, көндәлек курслар эшли (Красная Татария. — 1924. — 14 ноябрь). Идарә хезмәткәрләре курсы 3 группага бүленә һәм аларга барлыгы 60лап кеше йөри. Дәресләр уңышлы үтә: йөрүчеләр инде татарча укый, яза һәм хәтта азрак сөйләшә дә алалар (Красная Татария. — 1924. — 16 октябрь).

Калган комиссариат һәм оешмаларда исә татар теле курслары бер ачылып, бер ябылып, сүлпәнлек белән генә эшли. Аларга язылучы рус хезмәткәрләренең саны күп булмый, дәресләргә йөрүчеләр исә тагын да азрак санны тәшкил итәләр. Кайбер комиссариат һәм оешмаларга күзәтү ясау бу фикерне расларга ярдәм итәр.

Сәламәтлек саклау комиссариатының үзендә, сметада акча каралмавы сәбәпле, татар теле курслары ачылмый, аның каравы 1925 елда Медторгта оештырыла. 20 кеше язылган булса да, дәресләргә 5 кенә кеше даими йөри. Нәтиҗәдә комиссариат каршындагы татар телен гамәлгә кую комиссиясе, татар теле өйрәнүнең кирәклеген аңлатып, циркуляр хат белән чыгарга мәҗбүр була (ф. 732, оп. 1, д. 782, лл. 19-23).

Халык хуҗалыгы советында (ТСНХ) 1925 елга кадәр «башка кайбер комиссариатларда мондый курсларның берәр реаль нәтиҗә бирмәве» (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 44) һәм «татар теле өйрәнергә теләүчеләр булмау» (ф. 732, оп. 1, д. 984, л. 82) сәбәпле, курс оештырылмый. Болар гына да түгел, курс өчен сметага кертелгән акчаны Финанс комиссариаты кабул итми һәм бу эш өчен акча бөтенләй бирелми. Шулай да, татар теле өйрәтү өчен, укытучы Мөштәриев чакырыла. Дәресләр 4 айдан артык дәвам итәләр, ләкин 2 генә кеше укыганлыктан, укытучы алга таба да эшләүдән баш тарта. Шуннан соң курслар туктала. Сорашу нәтиҗәсендә, 6 кеше татар теле өйрәнергә теләк белдерә һәм аларны башка берәр

оешмадагы түгәрәккә кушарга карар бирәләр (ф. 732, оп. 1, д. 984, л. 83).

Иҗтимагый тәэминат комиссариаты: «руслар өчен татар телен гамәлгә ашыру курслары дәвам итә, ләкин фәкать 8 генә кеше йөри. Наркомат тарафыннан һичбер төрле ярдәм күрсәтелми» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 107).

Коммуна хуҗалыгы: 1924 елга кадәр «курслар ачылган булса да, берәү дә йөрмәгәнлектән, киредән япканнар» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 108). «Красная Татария» газетасы мәгълүматы буенча, 1924 елның май башында курслар ачыла, Үзәк комиссиядән укытучы чакыртыла. Курсларга 37 кеше йөри (Красная Татария. — 1924. — 4 июнь). 28 октябрьдәге санда исә бу курслар тәнкыйть ителә: дәресләрне иртән сәгать 9га кадәр генә үткәрергә мөмкинлек бар, чөнки кич белән җаваплы хезмәткәрләр һәрвакыт диярлек төрле утырышларда булалар. Курсларда барлыгы 60 җаваплы хезмәткәр укырга тиеш булса да, фактта 12 генә кеше татар теле өйрәнә. Түбән хезмәткәрләрдән курска 40 кеше язылган, 17се генә дәресләргә йөри (Красная Татария. — 1924. — 28 октябрь).

Халык комиссарлары советында «1924 елда руслар өчен татар теле курслары булган, ләкин атнасына ике генә көн йөргәнгә, нәтиҗә начар» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 108). 1925 елда инде курслар бөтенләй оештырылмый (ф. 732, оп. 1, д. 781, л. 11).

Җир эшләре халык комиссариатында 1924 елда «курслар булган, нәтиҗә күренми, йөрүче аз» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 105).

Эшче-крестьян инспекциясе (РКИ): 1924 елда курслар бөтенләй булмаган, 1925 елның 25 ноябрендә башланачак курсларга 6-8 кеше язылган. Ләкин инспекция алдан ук искәртә: контингент даими булмаячак, чөнки хезмәткәрләр еш кына ашыгыч эш белән кантоннарга чыгып китәләр (ф. 732, оп. 1, д. 773, л. 11).

Татторг: 1924 елның 13 ноябренә татар телен өйрәнергә теләүче 82 кеше курсларга языла (Красная Татария. — 1924. — 13 ноябрь). 1925 елның 1 январенә бу сан 60ка кала (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 54).

Урман трестында 1924 елда татар теле курслары булган, ләкин 5 кенә ай дәвам иткән. Нәтиҗә начар. (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 107).

Гомумсоюз Текстиль синдикатының Казан бүлеге: 1925 елның декабреннән 1926 елның язына кадәр татар теле түгәрәге эшли. Акча түләп, укытучы чакыралар. Ләкин эш нәтиҗәләре бик начар. Сәбәпләре: чагыштырмача аз вакыт эшләве, укытучының озак вакытлар авыруы. «Бу түгәрәк кирәк һәм көздән алып Мәскәү ризалыгы белән яңадан эшкә керешәчәк», — дип хәбәр итә трест мөдире (ф. 732, оп. 1, д. 984, л. 15).

Татсиликаттрест: «татар телен өйрәнергә теләүчеләр бар, ләкин мөмкинлекләр юк» (ф. 732, оп. 1, д. 984, л. 85).

ВКП(б) Өлкә комитетында да 1926 елның 1 октябреннән җаваплы партия хезмәткәрләре өчен атнасына 2 тапкыр 3әр сәгать күләмендә татар теле түгәрәге ачылырга тиеш була (ф. 732, оп. 1, д. 779, л. 37). Ләкин түгәрәкнең алдагы язмышы билгеле түгел.

1924 елның 4 сентябрендә «Красная Татария» газетасы Татстрахта татар теле түгәрәге эшли башлавы турында хәбәр итә. Атнага 4 сәгать күләмендә 3 төркем татар теле өйрәнә. 1925 елда исә 12 кешелек түгәрәк оештырыла һәм аны Үзәк комиссия тарафыннан Татстрахка тәрҗемәче булып җибәрелгән Бакиров җитәкли. 1 мартта татар теленең нигезләрен өйрәнү тәмамлана. Ә белемнәрен дәвам итәргә теләүчеләрнең саны аз булу сәбәпле (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 48), курс өчен акча бирелми һәм хезмәткәрләр үз акчаларына укуларын дәвам итәргә мәҗбүр булалар (ф. 732, оп. 1, д. 778, л. 89).

Газета редакцияләре, нәшрият хезмәткәрләре дә татар теле өйрәнү эшеннән читтә калмый. 1924 елда «Красная Татария», «Новая деревня» газеталары хезмәткәрләренә аларның редакторы тарафыннан 3 ай эчендә татар теле һәм язуы нигезләре белән танышырга тәкъдим ителә (Красная Татария. — 1924. — 5 июнь).

Үзәк туберкулез диспансерында 1925 елда татар теле түгәрәге оештырыла һәм хезмәткәрләрнең яртысы дәресләргә йөри (Красная Татария. — 1925. — 28 гыйнвар).

Һава флоты дуслары җәмгыятендә дә 1924 ел ахырында регуляр рәвештә татар теле дәресләре барганлыгы мәгълүм. Түгәрәкне җәмгыятьнең агитация секциясе җаваплы сәркатибе Садыйков җитәкли (ф. 732, оп. 1, д. 777, л. 3).

Хәтта төрмәдә дә (Центрисправдомда) татар теле түгәрәге эшләгән! 1925 елның 1 январенә, мәсәлән, 27 кеше (тоткыннар һәм надзирательләр) өчен 3 укытучы татар теле дәресләре алып барган (ф. 732, оп. 1, д. 766, л. 54).

20 нче елларда шулай ук Юстиция комиссариатында, Татсоюз, Урман тресты, Совет сәүдә хезмәткәрләре клубы, Үзәк эшче клубы, Всекобанк, Дәүләт банкы һәм Татар банкында, Татпищетрест, Тышкы сәүдә халык комиссариатының Казан өлкә идарәсендә, Артиллерия полкында рус хезмәткәрләре өчен татар теле түгәрәкләре эшләве мәгълүм (ф. 732, оп. 1: д. 778, л. 89; д. 766, л. 54; д. 784, лл. 100, 158; д. 767, л. 25; оп. 9, д. 43, лл. 92, 328).

Күренгәнчә, барлык комиссариат һәм учреждениеләрдә дә диярлек, төрле нәтиҗәләр белән булса да, татар теленә өйрәтү курс-түгәрәкләре эш алып бара. Бары тик Татар статистика идарәсе (ф. 732, оп. 1, д. 772, л. 11 об.) һәм Дәүләт сәясәт идарәсендә (ГПУ) (Красная Татария. — 1924. — 5 июнь) генә курсларның ачылуы

мәгълүм түгел. Алары да күп мәртәбәләр акча сорап та, үтенечләре канәгатьләндерелмәү нәтиҗәсендә оештырыла алмый.

5.2.3. Кантоннардагы татар теле түгәрәкләре. Кантоннарда да, шәһәрләрдәге кебек үк, татар теле курс-түгәрәкләре ачыла. Ләкин алар турында мәгълүмат бик аз. Булганнары да курслар файдасына сөйләми. 1924 ел буенча бер-ике мисал китерик.

Мамадыш кантонында «руслар өчен татар теле курсларының бертөрле дә нәтиҗәсе күренмәгәнгә, аларны юк итеп, аның урынына 25 кешегә 2 айлык совет эшчеләре хәзерләү курсы ачылган» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 124).

Лаеш кантонында «ни руслар өчен вә ни дә булса татар эшчеләре хәзерләү өчен бертөрле дә курс ачылмаган, аны кирәксенгән кеше дә булмаган» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 123).

Минзәлә кантонында «руслар өчен татар теле курсы ачылса да, аның һичбер төрле нәтиҗә бирмәгәнлеген канткомиссия үзе үк әйтеп бирә» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 120).

Чистай кантонында «руслар өчен ачылган татар теле курслары бер төрле дә нәтиҗә бирмәгәннәр. Рус хезмәткәрләре тарафыннан курска йөрү соң дәрәҗәдә начар булганга, 5 апрельдән курсны ябарга мәҗбүр булганнар» (ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 117).

Спас кантоны (1925-1926 еллар): «шәһәрдә булган учреждениеләрдәге бөтен рус хезмәтчеләре өчен «берләшкән татар теле өйрәнү түгәрәге» ачарга карар кылынып, укырга бина, укытучы табып, (комиссия) укырга теләүчеләрнең исемлекләрен җыйнады, ләкин ачылыр көн җитеп, вакыт тәгаен ителгәч, башта язылучы 60тан артык булса да, укырга 3-4 кеше генә килде. Икенче, өченче мәртәбәләр игълан ителеп каралса да, теләп килүче булмады. Шулай итеп, укулар башланмый калды. Хәзер шәһәрдә ялгыз потребительләр обществосында гына 6-7 урыслы түгәрәк дәвам итеп

килә, ләкин түгәрәкне киңәйтеп, җөмһүрият шартына муафыйк хәлгә кую өчен, укучыларның дәртләре булмагач, аңар көлеп кенә карагач, көткән нәтиҗәне алу читен» (ф. 732, оп. 1, д. 793, л. 26 а).

Күренгәнчә, кантоннардагы татар теле курсларының хәле шәһәрдәгеләргә караганда да начаррак булган.

5.2.4. <u>Русларга татар теле өйрәтү өчен вакыт күләмен билгеләү</u>. Курс-түгәрәкләрдә руслар татар телен өйрәнсен өчен, ничә сәгать вакыт таләп ителгән соң? Гыйльми үзәк тарафыннан билгеләнгән чикләр буенча, уртача хәзерлеккә ия руслар татар теленә өйрәнсен өчен, 400 сәгать вакыт кирәк: татарча иркен укый һәм яза белү, оешмага килүчеләрне кабул итү өчен җитәрлек күләмдә сөйләшә алу, язуларның гомуми эчтәлеген аңлау максатында 200 сәгать һәм татар телендә иркен рәвештә төрле язулар, докладлар төзү өчен тагын өстәмә 200 сәгать (ф. 732, оп. 1, д. 526, л. 26). 1925 елның 1 декабрендә татар теле түгәрәкләре эшчәнлеге турында Казанда җыйналган киңәшмәдә татар теле курсын башка милләтләргә урта күләмдә бирер өчен 400 сәгатьнең аз булуы ассызыклана, иң кимендә 550 сәгать чамасы вакыт билгеләнә (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 18 об.). Ләкин Гыйльми үзәк каршындагы фәнни-педагогик комиссия тарафыннан төзелеп, 1926 елда басылып чыккан «Татар булмаган җаваплы хезмәткәрләр курслары өчен татар теле программасы»нда исә 8 ай дәвамында, атнасына 6 сәгать шөгыльләнеп, ягъни 192 сәгать вакыт эчендә татар теленә өйрәнергә мөмкин дип саныйлар (Программа по татарскому языку для курсов, 1926, с. 3). Күренгәнчә, русларга татар телен өйрәтү өчен җитәрлек вакыт күләмен билгеләү өлкәсендә дә бу чорда төрлелек хөкем сөрә.

Гаять күп сандагы түгәрәкләр эшчәнлеген контрольдә тоту, билгеле, авыр була. Алар һәрберсе аерым-аерым эш алып баралар, укытучыларның да һәркайсы үзенчә, булдыра алганча укыта.

Җитмәсә, кайбер оешмаларда татар теле дәресләрен алып баручыларның «укытучы»лыгы татарча сөйләшә һәм яза алулары белән чикләнә, ә русларга татар теле укыту методикасын, рус аудиториясе үзенчәлекләрен белмәүләре исә исәпкә алынмый. Мәсәлән, 1924 елда Тышкы сәүдә халык комиссариатының Казан өлкә идарәсендә татар теле укыткан Галиев Әхмәд — «политехника институты студенты, русларга бер дә татар теле укытканы юк» (ф. 732, оп. 9, д. 43, л. 92); шул ук елда Күн трестында укыткан Локманов Фазыл — шулай ук вуз студенты, үзе үк: «татар телен һәм язуын урта дәрәҗәдә беләм», — дип күрсәтә (ф. 732, оп. 9, д. 44, л. 389); 1923 елда киез итек фабрикасында татар теле укыткан Маликов Латыйф — моңа кадәр балалар бакчасында эшләгән (ф. 732, оп. 9, д. 43, л. 79) һ.б. Мондый мисалларны күпләп китерергә булыр иде.

5.2.5. Түгәрәкләрне эреләндерү. Төрлесе төрле җиргә сибелгән һәм артык күп сандагы түгәрәкләр эшчәнлеген оешканрак итү максаты белән, 1925 ел ахырында аларны территориаль билге буенча район курсларына берләштерергә, бары тик зур оешмаларда гына мөстәкыйль түгәрәкләр калдырырга карар кылына (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 18). 1926 елда Казанда — 13, кантоннарда 14 түгәрәк оештыру күздә тотыла (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 56 об.). Ләкин 1927 елгы хисапта: «узган ел 45ләп түгәрәк эшләде», — дип күрсәтелә (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 11). Димәк, түгәрәкләр саны әле бер ел эчендә генә кыскартылып бетми. Ә 1927 елда исә аларның саны 6-7гә генә кала. Ләкин тагын каршылык: бу елда ике телне дә белмәүче хезмәткәрләрне татарлар яки ике телне дә белүчеләр белән алмаштыру планы кабул ителгәннән соң (Доклад, 1927, с. 65-66), «чын күңеленнән» татар теле өйрәнергә теләүчеләр саны күбәя һәм аларны укытып бетерү өчен элеккеге кебек күп санлы курслар һәм өстәмә чыгымнар таләп ителә. Әмма, бер яктан, инде түгәрәкләр

саны азайган, икенче яктан, бу вакытта аппарат чыгымнарын кыскарту кампаниясе башлану нәтиҗәсендә, күп учреждениеләр үз сметаларыннан түгәрәкләр өчен дә акча бүлеп бирергә теләмиләр (ф. 732, оп. 1, д. 1138, л. 11).

Эрерәк түгәрәкләр үз эшчәнлекләрен аклаганмы соң? Моны белү өчен, 1929 елга күз ташлыйк. Бу елда барлыгы 22 курс-түгәрәк эшләгән һәм аларда 597 кеше татар теле өйрәнгән. Мәгариф комиссариатында төзелгән тикшерү комиссиясе 80ләп кешенең татар теле буенча белемнәрен тикшерә һәм аларның бары 1сенә генә уңай бәя бирелә! Бу сәер нәтиҗәне азрак йомшарту йөзеннән булса кирәк, «ләкин икенче елда шул 80 кешенең 60ы тикшерүне уңышлы үтә алачак», — дип хәбәр ителә (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 33). 1930 елгы докладта исә артык җәелмичә, бер җөмлә белән генә курсларны 35 кеше бетереп чыгуы турында әйтеп үтәләр (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 339). Димәк, түгәрәкләрнең санын киметү, аларны районнар буенча берләштерү дә көтелгән нәтиҗәләргә китерми.

Татар теле курс-түгәрәкләре белән идарә итү 1925 ел ахырында Мәгариф комиссариатына тапшырыла (ф. 732, оп. 1, д. 767, л. 18). Бу елларда русларга татар теле өйрәтү өчен махсус программа һәм дәреслекләр чыгарылу, югары квалификацияле укытучыларны туплау, Татар педагоглары җәмгыятендә махсус секция төзү түгәрәкләр эшен азрак алга җибәрергә ярдәм итә (ф. 732, оп. 1, д. 1307, л. 33). Ләкин, гомумән алганда, 20 нче елларның барлык документларында да диярлек татар теле курс-түгәрәкләренең бернинди реаль нәтиҗәләргә китермәве ассызыклана. Күп еллар дәвамында эшләүләренә карамастан, аларда укып чыккан рус хезмәткәрләре татарча сөйләшә һәм оешмаларда татар телендә эш алып бара алмыйлар, 1927 елгы 3 нче сессия докладында әйтелгәнчә, «... татарча бер сүз дә диярлек белмиләр, я сүгенү сүзләрен генә

беләләр» (Доклад, 1927, с. 18). Шулай да бу сүзләр гомумән алганда дөрес булса да, югарыда уңай яктан телгә алынган оешма хезмәткәрләренең барысына да «бер сүз дә татарча белми» дигән бәяләмә бирсәк, аларның тырышлыкларын санга сукмау булыр иде.

5.2.6. Рус хезмәткәрләре өчен татар теленә өйрәтү Үзәк курслары эшчәнлеге. 30 нчы елларда да хәл яхшырмый. Дөрес, бу елларда таркау түгәрәкләрне берләштереп, бер үзәккә туплау юнәлешендә омтылыш ясап карала. 1933/34 елларда ТҮБКның Оештыру бүлеге каршында рус хезмәткәрләренә татар теле өйрәтү Үзәк курслары ачу турында положениеләр игълан ителә (ф. 128, оп. 1, д. 2291, лл. 27-28). Анда Курсларны 2 еллык итеп оештыру, шул вакыт эчендә 320 сәгать күләмендә программа материалын үтеп бетерү турында сүз бара. Моннан тыш, эре предприятиеләрдә һәм районнарда Үзәк курсларның турыдан-туры идарәсе һәм контроле астында эшли торган 35 кешелек мөстәкыйль группалар оештырылырга; Курсларга татар халкы белән тыгыз бәйләнештә торган хезмәткәрләр тартылырга һәм бу оешмадагы татар эшчеләре гомуми санының 10%ын тәшкил итәргә; Курсларны бетергәннәр Үзәк квалификация комиссиясе тикшерүе аша үтеп, аларга таныклама бирелергә һәм андый кешеләр татарлар белән алмаштырылмаска; укытучыларның хезмәт хакы техникум укытучылары белән тигез булырга; Курслар үзләренең штамп һәм печатенә ия булырга тиеш була (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 29).

Ләкин русларны татар теленә өйрәтү Үзәк курслары 1932/33 уку елында да эшләгән булырга тиеш, чөнки бу чорга караган берничә документ сакланып калган. Аларның беренчесе Үзәк курсларның эчке тәртип кагыйдәләренә багышланган (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 29). Бу кагыйдәләр буенча, уку елы 1932 елның 1 октябреннән башланып, 1933 елның 1 июнендә тәмамланырга тиеш. Каникул

вакытлары да билгеләнә: кышкысы — 20 гыйнвардан алып 1 февральгә кадәр, җәйгесе — 1 июньнән 1 октябрьгә кадәр. Дәресләр алты көнлеккә ике тапкыр 18 сәгать 30 минуттан 21 сәгатькә кадәр дәвам итәргә тиеш була. Курсларның ял итү көннәре бик кызык билгеләнә: һәр айның 6 нчы, 12 нче, 18 нче, 24 нче һәм 30 нчы числолары.

Педагогларның саны һәм исемнәре 1932/33 еллар өчен күрсәтелми, ләкин бурычлары бик ачык билгеләнә. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) дәрескә 5 минут алдан килергә; 2) укыту һәм эш планнары булырга, аларны уку-укыту бүлеге мөдиренә тапшырырга; 3) һәр курсантның өлгерешен һәм дәрескә ничек йөрүен билгеләп барырга; 4) үзенең группасындагы дисциплина өчен җавап бирергә; 5) яхшы дәреслекләр сайлануга җавап бирергә һәм кирәкле дәреслекләр исемлеген завучка үз вакытында тапшырырга; 6) педагогик һәм Курсларның башка җыелышларында катнашырга; 7) дәресләрнең булу вакыты һәм сәгате турында төгәл мәгълүмат тапшырырга һәм дәрес өзелгән өчен җавап бирергә; 8) Курслар администрациясе белән мөнәсәбәтләре эш буенча гына булырга тиеш һ.б. (ф. 128, оп. 1, д. 2291, лл. 31-32).

1932/33 елларга караган икенче документ — Үзәк курсларның төрле оешмалар белән төзегән килешүләре. Бу уку елы өчен Курслар 12 октябрьдән 10 февральгә кадәр 53 оешма белән килешү төзи. Оешмаларның күбесендә татар теле өйрәнергә теләүчеләр саны күп түгел: 2-3тән алып 15кә кадәр, ләкин кайберләрендә 25-30, хәтта 55 кеше саны китерелә. Килешүдә оешманың ничә сум акча түләргә һәм кайчан түләп бетерергә тиешлеге күрсәтелә. Бу елда түләү бер курсант өчен 65 сум исәбенә билгеләнә (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 21).

Ләкин килешү төзелгән 53 оешманың бары 16сында гына татар теле түгәрәкләре эшләгән булырга тиеш, чөнки исемлектә шуларның

гына астына сызылып, курсантлар саны буенча нәтиҗә ясала. Ул оешмалар түбәндәгеләр: Мәгариф комиссариаты, Казан дәүләт университеты, Татар коммунистик университеты, Татполиграф, Милиция, Татторг, Татсоюз, Райпо, Татснабсбыт, язу машиналары заводы, «Урак һәм чүкеч» заводы, Татжилсоюз, Дәүләт банкының Татарстан өлкә конторасы, 40 нчы завод, «Красный Восток» сыра заводы һәм тимер юлчылар профсоюзы. Аларда барлыгы 470 кеше татар теле өйрәнә (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 21).

1932/33 елларда да русларга татар теле өйрәтүдә каршылыклар дәвам итә. Оешмалар тарафыннан бирелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, укытучылар үзләре үк дәрескә килмиләр яки соңга калалар; алар тарафыннан укучыларны кызыксындырырга тырышу күзәтелми; укытучылар еш алмашына (тимер юл эшчеләре профсоюзында, мәсәлән, 4 айга 3 укытучы алмашынган); курсантлар группаларга бүленми, шуның нәтиҗәсендә, бөтенләй татарча белмәүчеләр белән беррәттән яхшы укый һәм аңлый торганнар да утыра; Курслар администрациясе тарафыннан тиешле күзәтү булмый, кимчелекләр турында хәбәр иткәндә дә, моңа әһәмият бирелми; 1933/34 уку елы өчен килешү төзү турында алдан хәбәр ителмәгән һ.б. (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 14).

1933/34 елларда Үзәк курсларның ТҮБКның Оештыру бүлеге каршында эшли башлавы эшкә аз булса да уңай йогынты ясый, чөнки ТҮБКның авторитеты нәтиҗәсендә татар телен гамәлгә кую эшеннән читләшергә тырышкан, төзелгән килешүләрнең шартларын үтәргә теләмәгән кайбер оешмаларның каршылыклары җимерелә (ф. 128, оп. 1, д. 2012, л. 136 об.).

1933/34 уку елында Курслар практик эшкә 15 августта гына керешәләр. 1 октябрьгә кадәр татар теле өйрәнүчеләре саны 300

кешене тәшкил иткән 25 оешма белән элеккеге килешүләр яңартыла, 215 кеше исәбенә 16 яңа договор төзелә (ф. 128, оп. 1, д. 2012, л. 10).

Бу еллар өчен Курслар штаты һәм укытучылар саны да билгеле. Курслар белән 3 кешедән торган аппарат идарә итә: Курслар мөдире Бикчәнтәев Ш., инструктор-оештыручы Сәлимов Х. һәм эш башкаручы Гладышев В. Штатта 8 укытучы билгеләнә (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 2). Алар арасында күренекле татар язучысы һәм шагыйре Г.Кутуй, тел галиме Л.Җәләй дә бар. Сакланып калган документлар буенча, Г.Кутуй турында оешмалар уңай фикердә була. Мәсәлән, Казан тимер юлчылар профсоюзы Г.Кутуйның, башка укытучылардан аермалы буларак, укучыларны кызыксындырырга тырышуын, ләкин, кызганычка каршы, башка җиргә күчерелүен хәбәр итәләр (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 14). Г.Кутуй һәм Л.Җәләйдән тыш, бу вакытта Курсларда КДУ укытучысы, доцент К.Хамзин, доцент Галиев, татарлаштыру секторында эшләүче Бадамшин, безнең өчен таныш булмаган Тләшова, Еналиев, Зоричев кебек укытучылар татар теле укыталар. Мәсәлән, Милиция һәм Татснабсбытта — Г.Кутуй, КДУда — Хәмзин, Татсоюзда — Л.Җәләй, Дәүләт банкында — Еналиев, Элемтә идарәсендә — Галиев, Мәгариф һәм Финанс комиссариатларында — Тләшова, «Красный Восток» сыра заводында Бадамшиннарның укытуы мәгълүм (ф. 732, оп. 1, д. 2291, л. 2 об.). Гомумән алганда, укытучыларның 60%ы — югары белемле, алар арасында доцентлар һәм ассистентлар була; 30%ы — урта белемле һәм 5 елдан да ким булмаган укыту стажына ия; 10%ы — түбән белемле, ләкин тәҗрибәле һәм зур педагогик стажлы (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 136).

Милициянең Курслар белән төзегән килешүеннән күренгәнчә, бу елларда оешмалар өчен түләү бер курсантка 45 сум исәбенә билгеләнә һәм 20 кешегә килешү төзелеп, тагын 10-15 кешелек

резерв күздә тотыла. Резерв өчен акча түләнми һәм алар, башкаларның дәресләргә катнашу-катнашмауларына бәйсез рәвештә, татар теле түгәрәкләренә йөрергә хокуклы булалар (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 4).

КДУда исә 21 кеше татар теле өйрәнергә тиеш була, алар арасында канцелярия һәм китапханә эшчеләре күпчелекне тәшкил итә (ф. 128, оп. 1, д. 2291, л. 7).

Курслар эшендә бу елларда ТҮБКның ярдәме бик зур булса да, авырлыклар дәвам итә. Әгәр оешмалар Курсларны, аларның администрациясен гаепләгән булса, Курслар исә үзләренең хисапларында оешма җитәкчеләренең татар телен гамәлгә кую эшен аңлап һәм бәяләп җиткермәүләрен, алай гына да түгел, Курсларга ниндидер кимсетүле, санга сукмый торган мөнәсәбәттә торуларын күрсәтәләр. Учреждениеләрдә бервакытта да татар теле өйрәнү өчен акча булмый: яки ул сметада каралмый, яки югары инстанцияләр тарафыннан кабул ителми. Шулай ук оешмалар татар теле өйрәнү өчен, я уку мөмкинлеге булмаган, я эшендә татар теле кирәк булмаган кешеләрне билгелиләр (предприятие җитәкчеләре, кучер һәм каравылчылар). Шуларның нәтиҗәсе буларак, түбәндәге каршылыклар күзәтелә: дәресләргә начар йөрү (30-35%), контроль булмау, техник проблемалар (бина, ут, җиһаз булмау), экстрен җыелышлар, өстәмә эшләр белән дәресләрне өзү һ.б. Хезмәткәрләрнең дәресләргә аз йөреп, эшнең нәтиҗәсе булмавын сылтау итеп, оешмалар акча түләүдән баш тарталар, моның белән Курсларның матди хәлен дә начарайталар, укытучыларның кызыксынуын да бетерәләр (ф. 128, оп. 1, д. 2012, л. 136 об.).

Күренгәнчә, нинди генә омтылышлар ясап карасалар да, Курслар эше уңышка китерми. Курслар оешмаларны, оешмалар исә үз чиратларында Курсларны гаепли-гаепли, 30 нчы еллардагы татар

теле түгәрәкләре эшчәнлеге дә ахырына якынлаша. 1934 елдан соң алар турында бөтенләй мәгълүмат юк. Бу вакытларда Сталинның милләтсез һәм бер телле җәмгыять төзү идеясе тормышка ашырыла башлау, караңгы шәхес культы нәтиҗәсендә татар телен гамәлгә кую эше, шул исәптән түгәрәкләр дә, әкренләп онытыла, юкка чыга.

5.2.7. Курс-түгәрәкләрнең уңышка ирешә алмау сәбәпләре. 20-30 нчы елларда русларга татар теле өйрәтү теләге белән оештырылган курс-түгәрәкләрнең уңышка ирешә алмау сәбәпләре бик күп. Югарыда алар азмы-күпме чагылыш тапты инде. Аеруча әһәмиятлеләрен төркемләп, түбәндәге тәртиптә китерергә мөмкин:

1. Курсларның нәтиҗәсе булмауга китергән иң зур сәбәпләрнең берсе — руслар тарафыннан кызыксыну һәм теләк булмау, тарихи хәтернең саклануы. Моңа кадәр дә татар телен файдаланмыйча яшәгән һәм хәзер дә аның кирәк булмавын күреп торган рус хезмәткәрләре бу телне өйрәнүне мәгънәсез һәм файдасыз бер эш дип саныйлар. Мисал итеп бер рус эшчесенең «Красная Татария» газетасында басылып чыккан мәкаләсен китерергә мөмкин: «...Мин Татарстан Республикасында ике ел яшим, ләкин әле һаман бу совет республикасымы, юкмы — аңлый алмыйм. ...Газетаның һәр санында диярлек авылны татарлаштыру, совет оешмаларын татарлаштыру кебек сүзләрне күрәм, ТРның 1 нче һәм 2 нче баскыч мәктәпләрендә, гомуми белем бирү курсларында, профтехник, урта һәм югары уку йортларында беркемгә дә кирәк булмаган, артта калган татар телен укыталар, аның урынына халыкара эсперанто телен өйрәтсәләр, барлык милләтләрне берләштерүгә тизрәк ирешер идек, юкса без Ильич васыятьләрен онытачакбыз» (Красная Татария. — 1924. — 13 август). Газета хезмәткәрләре бу мәкаләгә бик нык каршы чыгалар. Дөрес, алар Ленин сүзләренә таяналар, шул чор идеологиясе буенча фикер йөртәләр. Ләкин татар теленә мондый мөнәсәбәт, билгеле

булганча, хәзерге вакытта да русларга татар теле өйрәтүдә зур авырлыклар тудыра.

2. Ике телне дә белүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру, ягъни матди яктан кызыксындыру турында күп сөйләп, карарлар кабул итсәләр дә, гамәлдә бу эш тормышка ашырылмый кала. Эшкә алганда яки азат иткәндә татар телен белүчеләргә өстенлек бирү хакындагы карарлар да тулысынча кулланылмый.

3. Матди яктан кызыксындыру һәм башка бик күп шартларны тудыруга киртә булып торган зур сәбәп — акча булмау. Шулай ук кайбер оешма җитәкчеләре дә түгәрәкләр ачу һәм укытучы чакыру өчен акча бүлеп бирергә теләмиләр.

4. Русларга татар теле өйрәтү өчен белемле, методик әзерлекле һәм тәҗрибәле укытучылар җитешми. 30 нчы елларда исә аларның булганнары да шәхес культы корбаны була.

5. Укытучыларның һәркайсы үзенчә укыта, уртак программа һәм дәреслекләр (бигрәк тә баштагы дәвердә) бөтенләй булмый.

6. Түгәкләрнең эшчәнлегенә җитәрлек контроль булмый, алар белән идарә итү, оештыру эшләре кулдан-кулга күчеп йөри.

7. Дәресләр кичен, сигез сәгатьлек авыр эш көненнән соң уздырыла, ә хезмәткәрләргә исә эш сәгатеннән тыш та оешма хезмәтләрен башкарырга, җыелыш, лекцияләргә барырга кирәк була.

8. Аеруча оешма җитәкчеләре, җаваплы хезмәткәрләр дәресләргә йөрергә вакыт таба алмыйлар, күбесенчә техник хезмәткәрләрдән торган түгәрәкләрнең исә шул сәбәпле авторитеты булмый.

9. Дәрескә йөрүчеләрнең составы гел алмашынып тора. Бу укытучының эшен дә бик нык авырайта, укытуның нәтиҗәлелеген дә киметә.

10. Кайсы хезмәткәрнең мәҗбүри рәвештә татар теле өйрәнергә тиешлеге төгәл билгеләнми, «татар халкы белән тыгыз бәйләнештә булган» дигән гомуми сүзләр белән генә чикләнелә.

11. Түгәрәкләрнең күпме вакыт дәвам итүе, укытылачак сәгатьләр саны, дәресләрнең башлану һәм тәмамлану көннәрен билгеләүдә дә төрлелек хөкем сөрә.

12. Авыр язылышлы гарәп язуы да русларның татар теле өйрәнүендә авырлык тудыра һ.б.

# Йомгак

Тарихыбызда беренче тапкыр татар телен рәсми рәвештә дәүләт теле итеп игълан иткән 1921 елгы Декреттан соң ТТГК буенча киң эш җәелеп китә һәм бу процесс иҗтимагый тормышның барлык өлкәләренә дә үтеп керә. Хөкүмәт тарафыннан чыгарылган гаять күп сандагы декрет һәм карарлар татар телен дәүләт оешмаларында, кооперативларда, кантон һәм волостьларда, авыл советларында, мәгариф өлкәсендә гамәлгә кую мәсьәләләренә багышлана. Аларны тикшереп, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

I. Татарстан республикасындагы ТТГК эшләре белән гомуми җитәкчелек итү вазифасын 1921 елның 12 сентябрендә төзелгән ТТГК Үзәк комиссиясе башкара. Комиссия президиумы һәм әгъзаларының саны да, составы да гел үзгәреп тора. Комиссия рәисе хезмәтен һәрвакыт ТҮБК рәисе, җаваплы сәркатипне — гадәттә ТҮБК сәркатибе үти. Үзәк комиссиядә әгъза булып югары органнарда эшләүче җитәкчеләр билгеләнә. Комиссия Татарстан республикасындагы 50ләп оешмада, алар карамагындагы учреждениеләрдә һәм 12 кантонда ТТГК эшләрен оештыра. Шундый күп сандагы оешмаларның эшчәнлеге белән идарә итүне җиңеләйтү максатында, һәр комиссариатта һәм үзәк оешмаларда диярлек ТТГК өчле комиссияләре, ә кантоннарда 5 кешедән торган комиссияләр төзелә. ТТГК эше белән җитәкчелек итү, законнар чыгарудан тыш, Үзәк комиссия татар хезмәткәрләрен исәпкә алу һәм эшкә урнаштыру, курслар оештыру, татарча шрифтлы язу машиналары әзерләү, башка республикалардагы телне гамәлгә кую комиссияләре белән бәйләнеш урнаштыру һ.б. бурычларны үти. Комиссия елына якынча 350ләп татар хезмәткәрен эшкә урнаштыруга ирешә, ләкин бу вазифаның артык күп вакытны алуы сәбәпле, 1930 елдан ул

Хезмәт комиссариатына тапшырыла. Үзәк комиссиянең Башкорт телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе, Мари телен гамәлгә кую өлкә комиссиясе, Удмурт телен гамәлгә кую өлкә комиссиясе, Кыргызыстан, Төркмәнстан, Белоруссия республикаларының «аппаратка җирле халыкны тарту» комиссияләре, Идел буе немецлары автономияле республикасының үзәк башкарма комитеты белән ана телен гамәлгә кую эшенең торышы хакында актив хәбәр алышуы мәгълүм.

II. Күп санлы документлар һәм чыганаклар буенча нәтиҗәләр ясап, 20-30 нчы елларда барган ТТГК процессын 3 этапка бүлергә мөмкин:

1. ТТГК эшенең башлану, оештырылу һәм беренче нигезләре салыну этабы (1921-1924).

2. Эшне план нигезендә алып баруга күчү, алдагы елларга йомгак ясау этабы (1925-1926).

3. «Аппаратка җирле халыкны тарту (коренизация)» ягына борылыш этабы (1927-1936).

1921-1924 еллардагы эшчәнлек нәтиҗәсендә, ТТГКның юнәлешләре, бурыч һәм максатлары билгеләнеп җитә. 1925-1930 еллар өчен перспектив план төзелү эшне шактый җиңеләйтә. 1925-1927 елларда күп санлы съезд, сессия һәи киңәшмәләрдә татар телен төрле тармакларда тормышка үткәрү мәсьәләләре һәрьяклап тикшерелә. 1927 елдан исә оешмаларга татарларны күбрәк җәлеп итү иң әһәмиятле мәсьәләгә әверелә. Моның өчен барлык дәүләт учреждениеләренең хезмәт урыннары исемлеге төзелеп, шул урыннарның кайсыларын ике дәүләт телен дә белүче хезмәткәрләр белән алмаштырырга кирәклеге билгеләнә. 1927 елдан соң шактый сүлпәнләнгән ТТГК процессын 1930 ел белән тәмамларга да мөмкин булыр иде, чөнки шуннан соң Үзәк комиссиянең хисап һәм

докладлары бирелми, хөкүмәтнең бер генә съезд яки сессиясендә дә ТТГК эше аерым алып тикшерелми. Ләкин, документлар буенча, ҮК үзе 1932 елга кадәр эшли, ә архивларда сакланган ТТГК буенча соңгы чыганак 1936 ел белән билгеләнә. Шунлыктан ТТГК процессы, бик акрынлык белән булса да, 1936 елга кадәр дәвам иткән дигән фикергә килдек.

III. Халык комиссариатларында һәм үзәк оешмаларда ТТГКга аеруча зур игътибар бирелә: 1921 елгы Декретның беренче маддәсе үк әлеге мәсьәләгә багышлана.

1. Комиссариатларда һәм дәүләт оешмаларында ТТГК хакында чыгарылган күп санлы карарларның нигезен түбәндәгеләр тәшкил итүе ачыкланды:

1) барлык учреждениеләрдә дә татар телендәге телдән һәм язмача мөрәҗәгатьләрне кабул итү һәм аларга татарча җавап бирү мәҗбүри итеп куела;

2) барлык җыелыш, утырыш, съезд һәм конференцияләрнең рәсми теле итеп бертигез хокукта рус һәм татар телләре санала;

3) хезмәткәрләрне эшкә алганда, башка тигез шартларда, ике дәүләт телен дә белгәннәргә өстенлек бирелә;

4) һәрвакыт татар халкы белән аралашырга туры килгән хезмәт урыннарына ике телне дә белүче хезмәткәрләр билгеләнә;

5) барлык оешмаларның да боерыклары, инструкцияләр, карарлар, гаризалар, плакатлар һ.б. бер үк вакытта рус һәм татар телләрендә игълан ителергә тиеш дип табыла;

6) татар телендәге эш кәгазьләре һәм документлар (таныклык, мандат, ышаныч язуы, расписка, килешү, беркетмә, акча документлары һ.б. ) ТАССР чикләрендә рус телендәге шундый ук документлар белән бер үк хокукка ия булалар;

7) барлык учреждение һәм предприятиеләрнең мөһер, штамп һәм эленмә такталары татар һәм рус телләрендә булдырыла;

8) дәүләт оешмалары түбәнге органнардан татар телендә килә торган хисап, ведомость һ.б. материалларны рус теленә тәрҗемә итеп җибәрүне таләп итмәскә тиеш булалар һ.б.

2. Тикшерү объекты итеп алынган комиссариат һәм оешмалар арасында Сәламәтлек саклау, Эчке эшләр, Юстиция халык комиссариатлары, Татар статистика идарәсе, кайбер кооператив оешмалар һәм кредит органнарында ТТГК эше чагыштырмача яхшырак җайга салына. Элемтә идарәсе, Финанс, Иҗтимагый тәэминат комиссариатлары, Коммуналь хуҗалык идарәсенең ТТГК буенча эшчәнлекләре канәгатьләнерлек булмый.

IV. Кантон, волость һәм авыл советларында ТТГК процессын чагылдырган мәгълүматлар 20 нче еллар буенча гына табылды.

1. Чыганаклардан күренгәнчә, ТТГК иң түбән совет оешмаларыннан — авыл советлары һәм волостьлардан башланып китә. 1922 елдан алып даими рәвештә кантон, волость һәм авыл советларында татар телен файдалануга багышланган карарлар чыгып килә. Хөкүмәт карарлары нигезендә, татар авыл советлары һәм волостьларында татар теле актив кулланылышка кертелергә тиеш була, татар халкы азчылыкны тәшкил иткәннәрендә исә төп эш башкару рус телендә кадырылып, татарлар белән аңлашу татар телендә булдырыла. Татар авыл советлары һәм волостьлары 1922 елның ахырына ук татар телен гамәлгә кертеп бетерергә тиеш булсалар да, бу эш бары 1928 елга гына төгәлләнә ала, анда да күпчелек волостьларда хәрби һәм налог эшләре рус телендә калдырыла.

2. Татарстан 20 нче елларда 12 кантонга бүленгән була, аларның 7сендә татар халкы күпчелекне тәшкил итә (Минзәлә,

Мамадыш, Арча, Бөгелмә, Тәтеш, Чаллы, Буа) һәм шул нигездә барлык эш йөртүләр татар телендә башкарылырга тиеш була. Руслар күпчелекне алып торган кантоннарда исә (Лаеш, Алабуга, Зөя, Спас, Чистай) эш башкару рус телендә калдырыла. ТТГК буенча бишьеллык перспектив план нигезендә, татар кантоннарының барлык бүлек һәм оешмалары да 1927 елга кадәр тулысынча татар телендә эш йөртүгә күчеп бетәргә тиеш булсалар да, бу план тормышка ашмый, бары 70% татарлы Мамадыш һәм Минзәлә кантоннарында гына үтәлү алдында тора. Күп чыганакларны чагыштыру нәтиҗәсендә, ТТГК буенча иң алда барган кантоннар исемлегенә Мамадыш, Арча, Чаллы, Минзәлә һәм Бөгелмә кантоннарын кертергә мөмкин. Буа һәм, татарларның саны буенча иң соңгы урынны биләсә дә, Чистай кантоны да урта дәрәҗәдә татарчалаштырылалар. Лаеш, Алабуга, Зөя һәм Спас кантоннары татар телен куллану ягыннан иң артта сөйрәләләр. Шулай ук, татар халкының саны 60%ны тәшкил итсә дә, Тәтеш кантоны да һәрвакыт тәнкыйть ителә.

V. Мәгариф комиссариаты ТТГК эшләрен гамәли яктан тормышка ашыручы ролен үти. Аның карамагында эшләүче Социаль тәрбия бирү баш идарәсе (Главсоцвос), Профессиональ белем бирү баш идарәсе (Главпрофобр) һәм Гыйльми үзәк җитәкчелегендә республикада ТТГК буенча зур эш башкарыла.

1. 1 нче һәм 2 нче баскыч мәктәпләр, крестьян яшьләре мәктәпләре Главсоцвос кул астында эшлиләр. 1 нче баскыч татар мәктәпләрендә укыту татар телендә алып барыла, ләкин 1924 елдан ук инде аларда рус телен укытуга зуррак әһәмият бирергә кирәклеге хакындагы фикерләр күзәтелә башлый. Тарихтан билгеле булганча, кызганычка каршы, нәкъ шул юл соңрак зур күтәрелеш алып, татар телен мәктәпләрдән кысрыклап чыгара да инде. Ләкин, икенче

яктан, әлеге фикер тарафдарлары татар балаларының белемнәрен дәвам итә алмауларын бетерү ниятен күздә тоталар, чөнки 2 нче баскыч, профтехник уку йортларында укыту рус телендә алып барыла, вузларга кергәндә дә русча белергә кирәк була. 1921 елгы Декретта теләгәннәр өчен генә дип билгеләнсә дә, 1922 елның 21 декабрендәге инструкция нигезендә, барлык 2 нче баскыч, профтехник уку йортларында, партия мәктәпләрендә, эшче факультетларында һәм вузларда, ә шәһәрләрдә шулай ук 1 нче баскыч мәктәпләрнең соңгы сыйныфларында да барлык укучылар өчен татар теле өйрәнү мәҗбүри итеп куела. Нигездә бу эш тормышка ашырылса да, нәтиҗәләре бик начар була, бигрәк тә рус балаларына татар теле укыту иң артта сөйрәлә. Рус мәктәпләре өчен татар теле программасы да 1927 елда гына басылып чыга.

2. Главпрофобр профтехник уку йортлары, курслар, ФЗӨ мәктәпләре, техникумнар, эшче факультетлары һәм югары уку йортлары эшчәнлеге белән җитәкчелек итә. Бу уку йортларына татарларны күбрәк җәлеп итү буенча сизелерлек алга китеш күзәтелә. Мәсәлән, 1922-1931 еллар эчендә вузларда укучы татарларның саны 18,8%ка арта. Татарлар өчен 1920-1925 еллар аралыгында 6 техникум, 1 эшче факультеты ачыла. Татарларның укырга керүләрен җиңеләйтү максатында, уку йортларында әзерлек курслары һәм группалары оештырыла. Ләкин, кызганычка каршы, бу елларда хәтта татарлар күпчелекне тәшкил иткән уку йортларында да укытуны татар теленә күчерә алмыйлар. Хөкүмәтнең күп санлы карарлары нигезендә, урта һәм югары уку йортларында татар телен укыту мәҗбүри итеп куелса да, чынлыкта бу мәҗбүрият бары Көнчыгыш педагогия институтында гына тормышка ашырыла, ә башка уку йортларында исә күбесенчә я бөтенләй кертелми, я теләгәннәр өчен генә укытыла. Вузлардагы рус

студентларына татар теле өйрәтү өчен махсус төзелгән программа юклык та зур авырлык тудыра.

Эшче һәм крестьяннарны югары уку йортларына хәзерләү максатында төзелгән эшче факультетлары 20-30 нчы елларда татар яшьләренә дә югары белем алуда зур ярдәм күрсәтәләр. 1919 елдан КДУ янында Дәүләт эшче факультеты, ә 1923 елдан Көнчыгыш педагогия институты каршында татарлар өчен махсус Татар эшче факультеты эшчәнлекләрен җәелдерәләр. Дәүләт эшче факультетына керү өчен дә татарлар әзерлек группалары аша үтәргә мәҗбүр булалар, чөнки аларның белемнәре укыту фәкать рус телендә алып барылган университетка гына түгел, хәтта эшче факультетына керү өчен дә җитәрлек булмый.

Главпрофобр идарәсе үз карамагындагы уку йортларында татар телен укыту мәсьәләсенә җитәрлек әһәмият бирми, татар теле атнасына 2 сәгать 2 ел буе укытыла дигән кәгазеннән башка бер нәрсә дә булмый.

3. Мәгариф комиссариатының фәнни, уку-укыту, агарту эшләре һәм әдәби эшчәнлек белән гомуми җитәкчелек итүче Гыйльми үзәк Татарстанда ТТГК буенча аеруча зур эш башкара. Аның эшчәнлеге нигездә 3 төп юнәлештә алып барыла: фәнни-педагогик, редакция-нәшрият эшчәнлеге һәм туган якны өйрәнү эше.

1) Фәнни-педагогик комиссия тарафыннан башкарылган эшләрнең иң әһәмиятлеләре булып төрле тип уку йортлары өчен программалар, уку планнары һәм дәреслекләр төзү санала. 20 нче еллар — элекке программа һәм дәреслекләрне кире кагып, яңаларын уйлап табарга тырышу, эзләнүләр һәм бәргәләнүләр чоры. Бу елларда Гыйльми үзәк тарафыннан 1 нче һәм 2 нче баскыч мәктәпләр, җаваплы хезмәткәрләр, совет учреждениеләре, рус мәктәпләре, техникумнар һәм ФЗӨ мәктәпләре өчен татар теле

программалары төзелә. Дәреслекләр күбесенчә коллектив авторлар тарафыннан иҗат ителә. Авторлар арасында күренекле галимнәр М.Корбангалиев, Г.Ибраһимов, Ф.Сәйфи, Г.Шәрәф, Х.Бәдигый, Г.Сәйфуллин һ.б. бар. Ул вакыттагы дәреслекләр баштанаяк үз чоры идеяләре белән сугарылган булалар, марксистик теорияне, хезмәт процессларын нигез итеп алалар. Бу чорда предметлык системасыннан баш тартып, рус программаларына иярү һәм комплекслы система буенча дәреслекләр төзү эше киң җәелә.

2) Гыйльми үзәк карамагында татар, рус һәм милли азчылык телләрендәге китапларны тикшерү өчен редакция коллегияләре төзелә. Татарстан республикасында чыгарыла торган барлык китаплар, дәреслек-кулланмалар, уку-укыту характерындагы һәм фәнни хезмәтләр Гыйльми үзәк карап чыгып, раслаганнан соң гына бастырылалар. Бу хезмәтләрнең күпчелеген татар телендәге китаплар тәшкил итә. Кулъязмалар тикшерү, редакцияләү, бастырырга рөхсәт бирү эшеннән тыш, Гыйльми үзәк тарафыннан «Мәгариф», «Безнең юл» һәм рус телендәге «Вестник просвещения» журналлары да нәшер ителә.

3) Гыйльми үзәк татар телендә фәнни терминология эшләү мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә, моның өчен махсус комиссия оештырыла. Татар телендә терминнар төзү өчен кабул ителгән карарлар нигезендә, Гыйльми үзәк тарафыннан бик күп фәннәрнең атамалары төзелә һәм шул атамалар буенча дәреслекләр, гыйльми хезмәтләр һәм фәнни-популяр китаплар мәйданга чыгарыла.

4) Татар теле орфографиясенә реформа ясау мәсьәләсе буенча 10 елдан артык барган бәхәсләр дә 20 нче еллар башында күренерлек нәтиҗәгә китерә: 6 сузык аваздан торган орфография нигез итеп алына һәм бу татар халкы өчен шактый зур адым була. Язулар алмашынуга бәйләнешле рәвештә, орфографиягә һаман

үзгәрешләр керә бара һәм алар Г.Алпаров, И.Рәми, Гыйльми үзәк һ.б. тарафыннан төзеп бастырылган сүзлекләрдә чагылыш таба.

5) Билгеле булганча, 20-30 нчы елларда татар халкы ике тапкыр алфавит алыштыруга дучар ителә. 1930 елның 1 январеннән Татарстанда барлык язу-сызу эшләре, матбугат, язма эш башкару латин графикасына күчерелә. Латин шрифты татар теленең фонетик үзенчәлекләренә туры китереп яраклаштырыла, орфографиянең төп принцибы итеп фонетик принцип алына. Ләкин телебез өчен камил графиканың гомере озын булып чыкмый: 30 нчы елларның ахырында рус алфавитына күчү мәсьәләсе күтәрелә. Латинлаштырудан аермалы буларак, бу эш күбрәк өстән басым ясау юлы белән алып барыла. Кириллицага корылган татар графикасының зур җитешсезлекләргә ия булуы аны гамәлдә куллана башлауның беренче көннәрендә үк бик ачык күренә. Аны татар теленә яраклаштырып камилләштерү өчен күп мәртәбәләр омтылыш ясап каралса да, алар бернинди нәтиҗәгә китерми. Һәм хәзерге вакытта да алфавит мәсьәләсе ахыргача хәл ителмәгән бәхәсле проблемаларның берсе булып кала бирә.

6) 1923-1927 елларда Гыйльми үзәк каршында эшләгән Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте татар халкының телен, тарихын, мәдәниятен төрле яклап өйрәнү буенча зур хезмәт күрсәтә, үзенең тирәсенә танылган галимнәрне, шул исәптән татарлар арасыннан күренекле белгечләрне туплый.

VI. Бишенче бүлектә яктыртылган Татар телен гамәлгә кую үзәк курслары 1922 елның июлендә татарларны эшкә урнаштыруга зур киртә булып торган квалификациясез эшчеләр мәсьәләсен хәл итү, ягъни аларга төрле белгечлекләр буенча белем бирү максаты белән төзелә. Курслар башта вакытлы һәм кыска сроклы (1,5-2 айлык) буларак ачыла. 1922 елның 17 декабрендәге карар нигезендә, алар

даими эшләүче оешмага әйләнәләр. 2 айлыктан соң 3-4, 5-9 айлык курслар эшли һәм 1926 елдан алар 2 еллыкка үзгәртелә. Бу курсларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә 15ләп белгечлек буенча татар хезмәткәрләре әзерләнә.

Шулай ук русларны да татар теленә өйрәтү һәм моның белән ике дәүләт телен дә белүче хезмәткәрләр әзерләү максатында, 1921 елдан башлап төрле үзәк оешмаларда, комиссариатларда һәм кантоннарда русларга татар теле өйрәтү курс-түгәрәкләре эшли башлый. Түгәрәкләр рус хезмәткәрләрен татар сөйләм теленә, язарга, укырга, эш башкарырга һәм, гомумән, татар телендә телдән дә, язмача да үз фикерләреңне иркен бирә алуга өйрәтү максатында төзеләләр. Дәресләрдә сөйләшү методы өстенлек алып торырга һәм оешма юнәлешендә эш алып барылырга тиеш була. 1932-1933 елларда вак һәм таркау түгәрәкләрне берләштереп, бер үзәккә туплау юнәлешендә омтылыш ясап карала: ТҮБК каршында 2 еллык Үзәк курслар оештырыла. Ләкин Курслар хакында 1934 елдан соң бөтенләй мәгълүмат юк. Аерым очракларны исәпләмәгәндә, русларга татар теле өйрәтү курс-түгәрәкләре зур уңышларга ирешә алмый.

VII. Безнең тикшеренү күрсәткәнчә, 15 ел чамасы бик авыр шартларда дәвам иткән ТТГК процессы билгеле бер күләмдә үзенең функцияләрен үти алды.  Бу елларда татар теленең дәүләт теле сыйфатында нигезләре салына башлап, бәлки, шуңа да үзгәртеп кору чорында аңа икенче мәртәбә рәсми рәвештә дәүләт теле хокукы бирү мөмкинлеге барлыкка килгәндер. Ләкин 20-30 нчы елларда ТТГК процессы үз юлында гаять зур авырлыкларга очрады. Аларның кайберләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. 1921 елда ТТГК процессы зур күтәренкелек белән башланса да, 20 нче еллар ахырында һәм бигрәк тә 30 нчы елларда

Сталинның милләтсез һәм бер телле коммунистик җәмгыять төзү идеясе тормышка ашырыла башлау, бу идеягә каршылык күрсәтергә мөмкин булган кешеләрнең коточкыч шәхес культы корбаннары булуы нәтиҗәсендә, татар теле тулысынча диярлек рус теле тарафыннан кысрыклап чыгарыла.

2. Революция, канкойгыч гражданнар сугышы, 1921 елгы коточкыч ачлык нәтиҗәләре татар телен гамәлгә ашыру эшендә гаять зур тоткарлык тудыралар.

3. Чыганакларда бик күп мәртәбәләр кабатланган икенче зур сәбәп — акчасызлык. Бер яктан, хөкүмәт органнары тарафыннан ТТГК хакында бер-бер артлы карарлар чыгарылып тора, икенче яктан, бу юнәлештә гамәли эш алып бару өчен Мәскәүдән акча бирелми, ә җирле бюджет исә ул елларда бик ярлы була. Бүлеп бирелгән бик аз күләмдәге акча да Финанс комиссариаты тарафыннан үз вакытында җибәрелми, кайбер елларда тагын да азайтыла яки бөтенләй бетерелә. Күпчелек халык комиссариатлары һәм үзәк оешмалар татар телен гамәлгә кертү эше өчен чыганакларны үз хисапларыннан тотарга мәҗбүр булалар. Бу кимчелекләрне булдырмас өчен, регуляр рәвештә карарлар чыгып килә, ләкин гадәттә алар бернинди нәтиҗә дә бирмиләр.

4. Акча юклык башка бик күп каршылыклар килеп чыгуга этәргеч бирә. Шуларның кайберләре: ике телне дә белүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру, премияләр бирү, ягъни матди яктан кызыксындыру хакында күп сөйләп, карарлар кабул итсәләр дә, гамәлдә бу эш тормышка ашырылмый; акчасызлык сәбәпле, оешмалар махсус тәрҗемәчеләр һәм практикантлар тота, укытучылар чакыра, дәреслекләр, язу машиналары сатып ала алмыйлар; татар белгечләре гаять кирәкле урыннарда хезмәт хакы аз түләнү сәбәпле, татарлар башка эшкә күчәргә мәҗбүр булалар һ.б.

5. Алдагы зур сәбәпләрнең берсе — руслар тарафыннан кызыксыну һәм теләк булмау, тарихи хәтернең саклануы. Моңа кадәр дә татар телен файдаланмыйча яшәгән һәм хәзер дә аның кирәк булмавын күреп торган рус хезмәткәрләре бу телне өйрәнүне мәгънәсез һәм файдасыз бер эш дип саныйлар. ТТГК ул — татарларның үз эше һәм безгә кагылмый дигән ялгыш караш таралу да русларның татар теленә битараф мөнәсәбәтен барлыкка китерә.

6. Кайсы хезмәткәрнең мәҗбүри рәвештә татар теле өйрәнергә тиешлеге төгәл билгеләнми, «татар халкы белән тыгыз бәйләнештә булган» дигән гомуми сүзләр белән генә чикләнелә.

7. Махсус хәзерлеккә ия булган, белемле, квалификацияле һәм тәҗрибәле татар хезмәткәрләренең бик аз булуы да татар телен дәүләт теле итүдә гаять зур авырлык тудыра. Төрле типтагы уку йортлары, ТТГК Үзәк курслары әлеге каршылыкны бетерү юнәлешендә актив эш алып баралар һәм сизелерлек нәтиҗәләргә киләләр.

8. Русларга татар теле өйрәтү өчен дә белемле, методик әзерлекле һәм тәҗрибәле укытучылар җитешми. Булганнарының да күбесе хезмәт хакы аз түләнү һәм тиешле шартлар тудырылмау сәбәпле, эштән баш тарталар. Укытучыларның һәркайсы үзенчә укыта, уртак программа һәм дәреслекләр (бигрәк тә баштагы дәвердә) бөтенләй булмый.

9. Руслар өчен татар теле түгәрәкләренең уңышка ирешә алмавына тагын түбәндәгеләр дә зур йогынты ясый: дәресләр кичен, сигез сәгатьлек авыр эш көненнән соң уздырыла, ә хезмәткәрләргә исә эш сәгатеннән тыш та оешма хезмәтләрен башкарырга, җыелыш, лекцияләргә барырга кирәк була; аеруча оешма җитәкчеләре, җаваплы хезмәткәрләр дәресләргә йөрергә вакыт таба алмыйлар, күбесенчә техник хезмәткәрләрдән торган түгәрәкләрнең исә шул

сәбәпле авторитеты булмый; дәрескә йөрүчеләрнең составы гел алмашынып тора, бу укытучының эшен дә бик нык авырайта, укытуның нәтиҗәлелеген дә киметә; түгәрәкләрнең күпме вакыт дәвам итүе, укытылачак сәгатьләр саны, дәресләрнең башлану һәм тәмамлану көннәрен билгеләүдә дә төрлелек хөкем сөрә; авыр язылышлы гарәп язуы да русларның татар теле өйрәнүендә авырлык тудыра; түгәрәкләрнең эшчәнлегенә җитәрлек контроль булмый, алар белән идарә итү, оештыру эшләре кулдан-кулга күчеп йөри; уку шартлары бик начар була: бина (бүлмә), өстәл, такта, кәгазь кебек беренче чиратта кирәкле әйберләр җитешми һ.б.

10. Учреждение һәм оешма җитәкчеләренең ТТГК эшенә каршылык күрсәтүләре, аны икенче чираттагы мәсьәлә итеп караулары, башка «әһәмиятлерәк» эшләр белән күмелеп бетүләре дә зур авырлык тудыра. Бу очракта руслар турында гына түгел, ә татарлар хакында да сүз йөртергә туры килә, чөнки ул елларда ук татар җитәкчеләренең хәтта русларга караганда да битарафрак мөнәсәбәттә булулары ассызыклана.

11. Оешмаларга эшкә алганда яки азат иткәндә хезмәткәрләрнең ике дәүләт телен дә белүләре нигездә исәпкә алынса да, кайбер учреждениеләр татар телен белмәүче хезмәткәрне «кызганып», аны алмаштырудан баш тарталар.

12. Бу елларда учреждениеләрнең штатларын, чыгымнарны кыскарту процессы киң җәелгәнлектән, өстәмә рәвештә татар хезмәткәрләрен алу, тәрҗемәчеләр, практикантлар булдыру омтылышы да каршылыкка очрый.

13. Хезмәткәрләрне эшкә алу өчен профсоюз әгъзасы булу кирәклеге, ә профсоюзга хезмәттәге кешеләрне генә кабул итүләре кебек мәгънәсез тоткарлык та күп кенә татарларны эшкә алганда киртә тудыра.

14. Шулай ук татарча шрифтлы язу машиналарының җитешмәве, татар типографияләренең техник шартлары начар булу, татар хәреф җыючыларының җитәрлек булмавы кебек техник каршылыклар да ТТГК юлында тоткарлык ясый.

20-30 нчы еллардагы татар телен гамәлгә кую тарихын тикшереп чыкканнан соң, без шундый нәтиҗәгә килдек: тарих кабатлана. Бүгенге көндә дә татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүен тоткарлап торучы сәбәпләр шул ук диярлек. Моннан тыш, 20-30 нчы еллардан аермалы буларак, хәзерге вакытта русларның гына түгел, ә беренче чиратта татарларның татар телен белмәүләре һәм өйрәнергә дә теләмәүләре, ягъни социолингвистика термины белән әйткәндә, «тел нигилизмы» күренеше, телне гамәлгә куюда гаять зур авырлык тудыра. Шуңа күрә барыннан да элек татарларның милли үзаңын һәм милли горурлыгын уяту юнәлешендә эш алып барырга туры килә.

Шул ук вакытта, зур проблемаларны таныган хәлдә, бүгенге көннең 20-30 нчы еллар белән чагыштырганда өстенлекләрен дә инкарь итеп булмый. Безнең карашыбызча, алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) суверен республика буларак, Татарстан мәдәният, тел сәясәте һ.б. ягыннан үз проблемаларын үзе хәл итә ала һәм хөкүмәтнең бу юнәлештә эшләү мөмкинлекләре артты. Министрлар Кабинеты каршында төзелгән «ТР халыклары телләре турындагы» Законны гамәлгә ашыру Комитеты һәм ТТГК буенча махсус бүлек бу катлаулы һәм гаять кирәкле эш белән җитәкчелек итәләр; 2) татар халкы милли яңарыш һәм рухи мирасның кире кайту процессын кичерә; 3) татар милли мәгариф системасы программасы (ясле-бакча — мәктәп — югары уку йорты), акрынлык белән булса да, үтәлә башлады; 4) мәктәпләрнең матди яктан тәэмин ителеше тикшерелгән чор белән чагыштыргысыз рәвештә югарырак дәрәҗәдә һәм

мәктәпләр татар теле дәреслекләре, укыту программалары һәм кулланмалар белән нигездә тәэмин ителгән; 5) язу машиналары да җитмәгән чор белән чагыштырганда, хәзерге вакытта компьютерлаштыру процессы белән бәйле рәвештә татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә куюның техник мөмкинлекләре күпкә артты һ.б.

Бүгенге көндә эзлекле тел сәясәтен дәвам итү, татар теленең мәдәният, мәгариф, нәшрият өлкәләренә генә түгел, иҗтимагый тормышның барлык сфераларына да үтеп керүенә ирешү сорала. Заман бездән ике чор өчен дә уртак булган һәм татар теленең XXI гасырда дәүләт теле буларак тормышка ашырылуына тоткарлык тудыручы сәбәп һәм киртәләрне булдыра алганча юкка чыгаруны; 20-30 нчы еллар тәҗрибәсеннән сабак алып, тарихның тулысынча кабатлануын булдырмауны таләп итә.

## Библиография

Абрамов К. Татарстан в завершающем году пятилетки. — Казань: Татиздат, 1932. — 48 с.

Абрамов К. Татарстан на рубеже двух пятилеток. — Казань: Татпартиздат, 1933. — 56 с.

Аврорин В.А. Проблемы изучения функциональной стороны языка (К вопросу о предмете социолингвистики). — Л.: Наука, 1975. — 276 с.

Автономияле Татарстан социал Советлар җөмһүриятенең дәүләт мөәссәсәләрендә вә дәүләт кархонәләрендә татар телен гамәлгә кую турында тәгълимат. — Казань: тип. комб. изд. "Восток", 1923. — 8 с.

Алпаров Г. Бакуда тюркология съезды // Мәгариф. — 1925. — №9. — Б. 126-127.

Алпаров Г.Х. 10 ел эчендә татар теле // Мәгариф. — 1927. — №10-11. — Б. 60-66; №12. — Б. 39-45.

Аппаратны төп халыклаштыру һәм татар телен эшкә ашыру турында ВКП(б) Өлкә Комитеты карары // Кызыл Татарстан. — 1930. — 11 гыйнвар.

Асадуллин А.Ш. Из опыта преподавания русского языка в татарской школе. Методическое наследие. — Казань: Тат. кн. изд-во, 1981. — 143 с.

Ахунзянов Э.М. Двуязычие и лексико-семантическая интерференция. — Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. — 189 с.

Әхмәдиев Ш. Татарстанда тел мәсьәләсе // Мәгариф. — 1925. — №9. — Б. 3-8.

Байрамова Л.К. «Равноправие языков нейтрализует конфликты» // Научный Татарстан. — 1997. — №2. — С. 8-12.

Баембитов Г. Национальный вопрос в Татреспублике // Известия ТатЦИКа. — 1921. — №42.

Баембитов Г. Нужно помочь! // Известия ТатЦИКа. — 1921. — №71.

Баскаков А.Н., Насырова О.Д., Давлатназаров М. Языковая ситуация и функционирование языков в регионе Средней Азии и Казахстана. — М.: Доминант, 1995. — 166 с.

Башка милләтләргә татар телен ничек укытырга? // Мәгариф. — 1921. — №1-2. — Б. 22.

Бәдигъ Хуҗа. 15 ел эчендә татар әдәби теле // Яңалиф. — 1932. — №9-10. — Б. 84-94.

Беренче тел-әдәбият конференциясе материаллары. 1927 ел 15-22 июнь көннәрендә Казанда Бөтенсоюз күләмендә беренче мәртәбә җыйналган төрек-татар тел һәм әдәбият укытучылары конференциясенең тулы хисабы. — Казан: Татар мәдәнияте йортының басмасы, 1927. — 202 б.

Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов. Дооктябрьский период под ред. и с введением А.Н.Кононова. — М. : гл. ред. восточной литературы, 1974. — 342 с.

Биш ел эчендә. 1920-1925 /Татарстан Социаль Советлар Җөмһүриятенең бишьеллыгы/. — Казан: Изд. ТЦИК, 1925. — 293 б.

Богородицкий В.А. О научных задачах татарского языкознания (к 15 летию ТАССР). — Казань: Татгосиздат, 1935. — 15 с.

Бондалетов В.Д. Социальная лингвистика. — М., 1989. — 158 с.

Бюллетень 2-й сессии ТатЦИКа 3 созыва. — Казань: Изд. ЦИК, 1923. — №1-3.

Валеев Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX — 20-е гг. XX вв.). — Казань: Изд-во КГУ, 1998. — 377 с.

Валидов Дж. Татарский язык. — В кн. : Информ. бюллетень. — №1, ВОКС. — М. : Мосполиграф, 1927. — №23-25, с. 9.

Вәлид Г. Тагын да тел турында (Баку киңәшмәсе җае белән) // Мәгариф. — 1925. — №10-11. — Б. 112-118.

Вәлиди Җ. Татар телен эшләү мәсьәләсе // Безнең юл. — 1922. — №4. — Б. 51-56.

Вәлиди Җ. Төрек-татар телләренең язмышы // Безнең юл. — 1922. — №12. — Б. 14-19; 1923. — №1 (13). — Б. 22-27; 1923. — №2 (14). — Б. 62-67.

Вәлиди Җ. Галимҗан Ибраһимовның тел мәйданындагы хезмәтләре. — В кн. : Г.Ибраһимов. — Казань: Татиздат, 1928. — Б. 131-142.

Вәлиев Р. Фаҗига. — Казан: Тат. китап нәшр., 1996. — 191 б.

Вәлиева Ф. М.Х.Корбангалиевның татарларга һәм татар булмаганнарга татар телен укыту буенча методик системасы. Дис...фил. ф. канд.. — Казан, 1951. — 286 б.

Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәптә татар телен укыту методикасы. — Казан, 1978. — 328 б.

Вәлитов Г. Химия атамалары. — Казан: Татиздат, 1931. — 57 б.

Векслин. Татарстан профессия Мәгариф бүлегенә караган мәктәпләрдә татар телен эшкә ашыру // Мәгариф. — 1925. — №12. — Б. 29-31.

Вторая сессия ЦИК 5-го созыва, приуроченная к 5-летнему юбилею ТССР 25 июня 1925 г. Стенографический отчет. — Казань: Изд. ЦИК ТССР, 1925. — 192 с.

Габидуллин Х. Татарстан за семь лет (1920-1927). — Казань: Татиздат, 1927. — 92 с.

Габидуллин Х. К национальному вопросу // Известия Тат. ЦИКа. — 1921. — №30.

Гайнуллин Т. Тагын татар теле турында // Татарстан хәбәрләре. — 1921. — 9 ноябрь.

Ганеев А. К вопросу о РТЯ // Известия ТЦИК. — 1923. — 28 июня.

Ганиев А. 3-й объединенный пленум областного Комитета РКП(б) и областной контрольной комиссии. Доклад комиссии по РТЯ // Известия ТатЦИКа. — 1924. — №98.

Ганиев Ф.Ә. Татар грамматика фәненең үсеше // Совет мәктәбе. — 1968. — №9. — Б. 26-28.

Ганиев Ф.Ә. Татарская грамматическая наука за 50 лет. — В кн. : Развит. филол... — Казань, 1969. — С. 5-12.

Гарипова З.Г. Из опыта введения татарского языка в в делопроизводство в Татарстане (20-е годы) // Языковая ситуация в республике Татарстан: состояние и перспективы (Материалы научно-практической конференции. 17 ноября 1998 года). Ч. II. — Казань: Изд-во «Мастер Лайн», 1999. — С. 21-24.

Гарипова З.Г. Культурно-просветительная работа в Татарии в годы первой пятилетки (1928-1932). — Казань: Тат. кн. изд-во, 1985. — 160 с.

Гарипова З.Г. Оныклар безне гафу итмәс // Татарстан. — 1992. — №9-10. — Б. 150-153.

Гарипова З.Г. Осуществление закона о государственном языке в Татарстане (20-е годы) // Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность (Материалы международной тюркологической конференции. 9-13 июня 1992 года). Т. I. — Казань: АН РТ, 1992. — С. 34-35.

Гарипова З.Г. Төрки халыклар егерменче елларда // Татарстан. — 1997. — №6. — Б. 33-37.

Гарипова З.Г. Үткәннәрдән сабак алыйк // Ватаным Татарстан. — 1994. — 20 июль.

Гарипова З.Г., Загитов Х.Н., Мусина Т.К. Развитие культуры в Татарии. Указатель литературы на русском и татарском языках. 1917-1975 гг. — М.: АН СССР, 1978. — 294 с.

Гаффар Әхәт. Татарстанда шәрыкне өйрәнү (Тюркология съезды уңае белән) // Мәгариф. — 1925. — №10-11. — Б. 95-99.

Гаффар Ә. Казан университетының Көнчыгышны өйрәнүгә хезмәте (Университетта татар теле һәм әдәбияты кафедрасы төзелү уңае белән) // Яңалиф. — 1930. — №5. — Б. 54-61.

Гәрәев Ф. Безнең гасырның 20 нче елларында татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре // Гыйльми язмалар (Татар дәүләт гуманитар институты). — 1997. — №2. — Б. 164-169.

Гобәйдуллин Газиз. Иҗтимагый гыйлемнәр бабында ниләр эшләнде (шул исәптән татар тел белеме өлкәсендә)? — В кн.: Биш ел эчендә. — Казань: тип. "Камиль Якуб", 1925. — Б. 143-150.

Госманов Ш. Татар телен гамәлгә кую тирәсендә // Татарстан хәбәрләре. — 1922. — №197.

Давлетшин Тимурбек. Советский Татарстан. Теория и практика ленинской национальной политики. — Мюнхен, 1974. — 392 с.

Деятельность Общества Татароведения (1923-1925 гг.) // ВНОТ. — 1925. — №1-2. — С. 57-60.

Дмитриева З. 20 нче елларда татар телен гамәлгә кую процессы («Красная Татария» газетасы буенча) // Языковая ситуация в республике Татарстан: состояние и перспективы (Материалы научно-практической конференции. 17 ноября 1998 года). Ч. II. — Казань: Изд-во «Мастер Лайн», 1999. — С. 38-40.

Доклад Центральной Комиссии по реализации татарского языка при ЦИК Тат. АССР "О положении дела по РТЯ и перспективах" на

3-ей Сессии ЦИКа Татарской АССР 12-13 марта 1927 г. (Стенограмма). Прения и постановление по докладу. — Казань: Изд. ЦК РТЯ при ТЦИК-е, 1927. — 68 с.

Җәләй Л., Әмиров Г. 40 ел эчендә татар тел белеме. — Совет әдәбияты, 1954. — №10. — Б. 92-100.

З. Реализация постановления об огосударствлении татарского языка // Известия ТатЦИКа. — 1923. — №130 (16 июнь).

Закиев М.З. Некоторые социальные факторы и эволюция языка. — В кн. : Вопр. тюрк. — Казань, 1970. — С. 10-14.

Закиев М.З. О некоторых закономерностях развития национальных языков. — В кн. : Торжество Ленинской национальной политики в Татарии. — Казань: Таткнигоиздат, 1968. — С. 209-217.

Закиев М.З. Основные этапы развития татарского языкознания. — В кн. : Итог. конф. КГУ за 1963 г. — Казань: Изд-во КГУ, 1964. — С. 97-102.

Закиев М.З. Татарский язык. — В кн.: Языки народов СССР. Т. II. Тюркские языки. — М. : Наука, 1966. — С. 139-154.

Закиев М.З. Татары: проблемы истории и языка. — Казань: ИЯЛИ АНТ, 1995. — 464 с.

Закиев М.З. Успехи татарского языкознания за 50 лет. — В кн. : Вопр. тюрк... — Казань, 1970. — С. 3-9.

Закиев М.З., Тумашева Д.Г. Роль Казанского университета в развитии тюркологии. — В кн. : Пробл. Тюркологии. — Казань: Изд-во КГУ, 1964. — С. 9-20.

Заляй Л.З., Амиров Г.С. Татарское языкознание за 40 лет. — Изв. КФАН СССР. Юбилейный сборник. — Казань, 1957. — С. 183-194.

Заляй Л., Амиров Г. Подготовка лингвистических кадров в ТАССР за 40 лет. — В кн. : Пробл. Тюркологии. — Казань, 1960. — С. 9-12.

За 5 лет. К 5-й годовщине провозглашения ТССР. — Казань: Изд. ТЦИК, 1925. — 208 с.

Зарипов И. Милли мохит — миллəт көзгесе // Əллүки. — 1998. — 13 февраль.

Зəкиев М.З. «Татарстан халыклары телләре турында» Татарстан Законын гамəлгə кую концепциясе // Мəгариф. — 1997. — №12. — Б. 43-44.

Зəкиев М.З. Туган тел үсеше. — Казань: Таткнигоиздат, 1967. — 83 б.

Зəкиев М.З. Үле телне терелтү. Телләр турындагы Закон ничек үтəлə? // Ватаным Татарстан. — 1996. — 4 декабрь.

З.Р. О реализации татарского языка // Известия ТатЦИКа. — 1923. — №131.

Ибраһимов Г. Беренче тюркология съезды. Баку. 1926. // Безнең юл. — 1926. — №1-2.

Ибраһимов Г. Əсəрлəр. Сигез томда. 5 том. — Казан: Тат. китап нəшр., 1978. — 615 б.

Ибраһимов Г. Əсəрлəр. Сигез томда. 8 том. — Казан: Тат. китап нəшр., 1987. — 430 б.

Ибраһимов Ф. Белем əлифбадан башлана (Татарча уку-язуга өйрəтү методикасы һəм татар əлифбалары тарихы). — Казан: Мəгариф, 1994. — 256 б.

Ибраһимова Ф. Исеме халкыбыз күңелендə (Əхмəтһади Максудиның тууына 130 ел тулу уңаеннан) // Мəгариф. — 1998. — №9. — Б. 57-58.

Икенче баскыч (9 еллык) рус мәктәпләре, шулай ук, вакытлыча, югары мәктәпләр өчен татар теле программасы. — Наркомпрос басмасы, 1927. — 33 б.

Информационный бюллетень Наркомпроса. — М., 1922. — №3-4.

Исламов Ф. Татар булмаганнарны татар теленә өйрәтү тарихыннан (20-30 нчы еллар) // Языковая ситуация в республике Татарстан: состояние и перспективы (Материалы научно-практической конференции. 17 ноября 1998 года). Ч. II. — Казань: Изд-во «Мастер Лайн», 1999. — С. 24-28.

Казаков И. На исходе 2-й годовщины ТССР // Известия ТатЦИКа. — 1922. — №140.

Казан дәүләт университетында татар теле кафедрасы // Мәгариф. — 1929. — №8. — Б. 110-111.

Казанец. В ТатЦИКе // Известия ТатЦИКа. — 1922. — №21.

Казан сөйли! Татарстан радиосы тарихыннан // Татарстан. — 1995. — №9-10. — Б. 66-71.

Кәримуллин Ә.Г. Татар тел белеме библиографиясе. — Казан: Тат. китап нәшр., 1958. — 116 б.

Кәримуллин Ә.Г. Тел — милләтнең сакчысы. — Казан: Тат. китап нәшр., 1997. — 256 б.

Кириллова З. Тарих кабатланырмы? (20-30 нчы елларда татар телен гамәлгә кую курслары) // Татарстан. — 1999. — №1. — Б. 58-60.

Кириллова З. Үткәннәрдән сабак алыйк. Руслар өчен оештырылган татар теле курслары тарихыннан // Казан утлары. — 1999. — №6. — Б. 150-157.

Кириллова З. Татар телен гамәлгә кую тарихы (20 нче еллар рус матбугатыннан) // Мәгариф. — 1999. — №8. — Б. 28-29.

Кириллова З. Татар телен дәүләт теле итү: беренче омтылыш // Идел. — 1999. — №11. — Б. 37-47.

Кононов А.Н. История изучения тюркских яыков в России. Дооктябрьский период. — Л.: Наука, 1982. — 360 с.

Корбангалиев М., Газизов Р. Русларга татар телен өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек. — Казан: Татгосиздат, 1925. — 136 б.

Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен (Техникум, рабфак, ВУЗ һәм ВТУЗлар өчен). — Казан: Татгосиздат, 1934. — 252 б.

КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. Т. 2. (1917-1922). — М.: Политиздат, 1983. — 606 с.

КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. Т. 3. (1922-1925). — М.: Политиздат, 1984. — 494 с.

Культурное строительство в Татарии (1917-1941 гг.): Документы и материалы. — Казань, 1971.

Курбангалиев М., Газизов Р. Систематическая грамматика татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка. — Казань: Татиздат, 1932. — 171 с.

Курбангалиев М., Газизов Р. Учебник татарского языка для русских (для школ 2-й ступени). — Казань: Татиздат, 1928. — Ч.1. — 148 с.

Курбатов Х.Р. Татат теленең алфавит һәм орфография тарихы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 129 б.

Литвин А.Л. Запрет на жизнь. — Казань: Тат. кн. изд-во, 1993. — 224 с.

Лотфуллин М. Телне саклап калу — халыкны саклау ул // Мәгариф. — 1998. — №9. — Б. 78-79.

Магнов. К постановке национального вопроса в татарской организации // Известия ТатЦИКа. — 1924. — №69.

Максуд Г. Җавап // Мәгариф. — 1924. — №1-2. — Б. 78-87.

Максуд Г. Караш аермалары // Мәгариф. — 1921. — №3-4. — Б. 3-4.

Максуд Г. Тагын бер зур мәдәни адым (Тел, әдәбият конференциясе җыелу уңае белән) // Мәгариф. — 1927. — №6-7. — Б. 61-67.

Максуд Г. Тел турында (Гыйльми мәркәзнең тел турындагы карарларына сүз башы һәм изах урынына) // Мәгариф. — 1924. — №5. — Б. 330-338.

Максуд Г. Тел мәсьәләсе // Мәгариф. — 1927. — №12. — Б. 35-36.

Максуд Г. Фән эшләребез турында кайсыбер фикерләр // Мәгариф. — 1927. — №12. — Б. 35-38.

Максудов А. Татарстан. Самоучитель татарского языка для русских, составленный по индуктивному методу и десятичной системе. 2-е изд.— Казань: Татгосиздат, 1926. — 252 с.

Мамадыш кантоны татар телен гамәлгә кую кәмиссиясендә. Тәтеш кантонында. — В кн. : Информ. бюллетень Тат. АССР. — Казань, 1923. — №16-17. — Б. 5-6.

Мансур Б. Татар телен гамәлгә кую // Татарстан хәбәрләре. — 1921. — 13 июнь.

Мансуров Г. Больше усилий к окончанию дела реализации татарского языка // Известия ТатЦИКа. — 1923. — №267.

Мансуров Г. Ко второй годовщине Татреспублики // Известия ТатЦИКа. — 1922. — №140.

Математика терминнары. — Казан, 1927. — 27 б.

Материалы для докладчиков к восьмилетнему юбилею АТССР. — Казань, 1928.

Материалы к отчету правительства АТССР за время с 8-го по 9-й съезд Советов. — Казань: Изд. Орготдела ЦИК АТССР, 1931. — 28 с.

Медицинада татарча атамалар. 1- кисәк. — Казан, 1929. — 43 б.

Миңнуллин Р. Дәүләт эше итеп карау җитми! Татар теле — дәүләт теле // Ватаным Татарстан. — 1996. — 27 апрель.

Михайлов М. Введение татарского языка // Известия ТатЦИКа. — 1924. — №44.

Мөхәррәмов М. Татар тел, әдәбият һәм тарих фәннәре үсештә (күзәтү урынында) // Сов. мәкт. — 1967. — №11. — Б. 24.

Насырова О.Д. Языковая ситуация в республике Каракалпакстан. — М.: ИЯз РАН, 1997. — 98 с.

Нәбиуллина Г. 20-30 нчы елларда татар телен гамәлгә кую проблемалары // Языковая ситуация в республике Татарстан: состояние и перспективы (Материалы научно-практической конференции. 17 ноября 1998 года). Ч. II. — Казань: Изд-во «Мастер Лайн», 1999. — С. 40-43.

Нигъмәти Г., Мөхәммәдиев М., Шәрәфетдинов С. Сәяси лөгать. — М., 1925. — 200 б.

Низамов И. И туган тел... : Татар теле — дәүләт теле. — Казан: Мәгариф, 1998. — 207 б.

Низамов И. Карары эшкә ашмаган бер сессия тарихыннан // Татарстан хәбәрләре. — 1992. — 16 май.

Низамов И. Конституция һәм туган тел // Әллүки. — 1993. — 23 февраль.

Низамов И. Нәрсә ул «дәүләт теле»? // Мәгърифәт. — 1997. — 18 октябрь, 12 декабрь.

Низамов И. Нияте эшкә ашмаган бер чыгыш тарихыннан // Татарстан хәбәрләре. — 1992. — 22 декабрь.

Низамов И. Татар теле — дәүләт теле // Мәгариф. — 1997. — №12. — Б. 49-52; 1998. — №4. — Б. 66-68; №9. — Б. 68-70.

Низамов И. Тел тормышы. Социолингвистик караш // Татарстан. — 1999. — №1. — Б. 52-55.

Низамов И. Терминология комиссиясе: бар да, юк та // Татарстан хәбәрләре. — 1993. — 31 декабрь.

Ничек телле булырга? // Татарстан яшьләре. — 1995. — 7 март.

Ногман М. XVII — XVIII йөзләрдәге русча-татарча кулъязма сүзлекләр. — Казан: КДУ нәшр., 1969. — 112 б.

Нуркай З. Пять лет научной работы // ВНОТ. — 1925. — №3. — С. 5-11.

Обзор деятельности научного общества Татароведения (1923-1929) // ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 201-208.

Отчет о деятельности НОТ за период с 1 января 1928 г. по 11 октября 1929 г. // ВНОТ. — 1930. — №9-10. — С. 209-211.

Отчет о деятельности ЦИК и СНК за 1923-1924 гг. — Казань: Изд. ЦИК и СНК ТССР, 1924. — 88 с.

Отчет о деятельности ЦИК и СНК за 1924-1925 гг. — Казань: Изд. ЦИК и СНК ТССР, 1925. — 76 с.

Отчет о деятельности ЦИК и СНК за 1925-1926 гг. — Казань: Изд. ЦИК и СНК ТССР, 1926. — 42 с.

Отчет Центральной комиссии при ТатЦИКе 5 съезду Советов о реализации татарского языка. — Казань: типо-лит. Комб. изд-ва и печати "Восток", 1925. — 29 с.

Отчет ЦИК и СНК за время с 3-го по 4-й съезд Советов. — Казань: тип. «Красн. Печатн.», 1923. — 304 с.

Отчет ЦИК и СНК к 5-му съезду Советов. — Казань: Изд. ЦИК и СНК, 1925. — 200 с.

Отчет ЦИК и СНК 5 созыва ТССР. — Казань: Изд. СНК, 1926. — 339 с.

Отчет ЦИК и СНК 6 созыва ТССР. — Казань: Изд. ЦИК и СНК, 1927. — 482 с.

Постановление 8-го съезда Советов ТАССР по докладу Наркомпроса и Госкомитета "Яналиф" о введении "Яналиф"а в республике. — Съезды Советов СССР. — М., 1962, т.4, ч.1. — С. 630-632.

Постановления 2-й сессии ЦИК ТАССР 6-го созыва /10-17 сентября 1926 г./. — Казань: Изд. ЦИК ТССР, 1926. — 126 с.

Проблемы языковой жизни Российской Федерации и зарубежных стран. Материалы к XIII Всемирному конгрессу социологов (Германия, Билефельд, 18-23 июля 1994 г.). — М.: Доминант, 1994. — 200 с.

Программа по татарскому языку для нетатар. — Казань: Татиздат, 1932. — 42 с.

Программа по татарскому языку курсов ответственных работников не татар. Сост. научно-пед. комиссией акадцентра ТНКПроса. — Казань: Изд. ЦК по РТЯ, 1926. — 14 с.

Рамазанов Ш. Совет чорында татар әдәби теленең үсеше // Совет әдәбияты. — 1945. — №6. — Б. 87-97.

Рәми И. Татар теленең орфография сүзлеге. — Казан: Яңалиф, 1930. — 355 б.

Рәхим Гали. Утыз еллык хезмәт. 1895-1925. (Мөхетдин абзый Корбангалиевның мәдәни-иҗтимагый хезмәтенә 30 ел тулу уңае белән). — Казан: Татгосиздат, 1925. — 36 б.

Реализация татарского языка // Татреспублика в цифрах. — 1923. — №12. — С. 51-52.

РСФСР кодексларында очрый торган атамалар лөгатьчәсе. — Казан, 1927. — 36 б.

Самойлович А.Н. Галимджан Ибрагимов как татаровед // ВНОТ. — 1928. — №8. — С. 9-13.

Сатрапинский И. Итоги народного образования в Татреспублике // Татреспублика в цифрах. — 1923. — №14. — С. 28-34.

Саттаров Г.Ф. Татар телле Татарстан // Казан утлары. — 1995. — №7. — Б. 177-183.

Саттаров Г.Ф. Тел язмышы — милләт язмышы // Ватаным Татарстан. — 1994. — 13 октябрь.

Саттаров Г.Ф. Тел язмышы — милләт язмышы // Әллүки. — 1997. — 21 февраль.

Саттаров Г.Ф. Туган тел, дип телгәләнмәсен күңел // Әллүки. — 1993. — 17 декабрь.

Сафиуллина Ф.С. Татарский язык. Самоучитель. — Казань: Таткнигоиздат, 1991. — 445 с.

Сборник декретов и распоряжений с 25 мая 1920 г. — 25 мая 1921 г. — Казань: Изд. СНК ТССР, 1921. — 205 с.

Сборник Декретов, Постановлений, важнейших Циркуляров и других материалов в области реализации татарского языка. — Казань: Изд. Центр. комиссии по реализации татарского языка при ЦИК ТАССР, 1925. — 88 с. (К 5-летию Татреспублики). В прилож. дана карта.

Сейфи Ф. Самоучитель татаро-башкирского языка или руководство научиться без помощи учителя читать, писать и говорить по-татаро-башкирски. Вып. I. — Уфа: Изд. книгоизд. т-ва «Башкнига», 1923. — 47 с.

Сибәгатов Р.Г. Башкортстанда телләрнең хокукый статусы турында. — Уфа, 1997. — 35 б.

Советская политика за 10 лет по национальному вопросу в РСФСР. Систематический сборник действующих актов правительств Союза ССР и РСФСР по делам национальностей РСФСР (октябрь 1917г. — ноябрь 1927 г.). — М.: Госиздат, 1928. — 499 с.

Солтанбәков Б.Ф., Харисова Л.А., Галямова Ә.Г. Татарстан тарихы. XX гасыр. 1917-1995 еллар. IV кисәк. Гомуми белем йортлары өчен уку әсбабы. — Казан: Хәтер, 1998. — 448 б.

Солтанов Ф. Эшли белергә кирәк // Мәгариф. — 1998. — №9. — Б. 86.

Суверенный Татарстан. Документы. Материалы. Хроника. Т. I. — М.: ЦИМО, 1998. — 280 с.

Султанбеков Б.Ф. Сталин и «татарский след». — Казань: Тат. кн. изд-во, 1995. — 252 с.

Султанбеков Б.Ф. Страницы секретных архивов. — Казань: Тат. кн. изд-во, 1994. — 253 с.

Султанбеков Б.Ф., Малышева С.Ю. Трагические судьбы. — Казань: Тат. кн. изд-во, 1996. — 284 с.

Татар дәүләт университетында татар теле кафедрасы. Мөхиттин абзый Корбангалиев // Татарстан. — 1929. — №4. — Б. 24-26.

«Татарстан Республикасы халыклары телләре» турында Татарстан Республикасы Законын гамәлләштерүнең төп юнәлешләре // Мәгариф. — 1996. — №9. — №68.

Татарстан Республикасы халыклары телләре турында Татарстан Республикасы Законы. Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы. — Казан: ТР Дәүләт Советы басмасы, 1996. — 42 б.

Татарстан Үзәк башкарма комитеты янындагы татар телен гамәлгә кую Үзәк комиссиясенең Татарстанның 5 нче Советлар съездына хисабы. — Казан: типо-лит. Комб. изд-ва и печати "Восток", 1925. — 29 б.

Татарстан Үзәк башкарма комитеты янындагы татарчалаштыру Үзәк комиссиясенең татарчалаштыру эшенең барышы һәм киләчәге турында (ТҮБК. 1927 елның 12-13 март, 3-сессиясендә ясалган доклад). — Казан: изд. ЦК РТЯ при ТЦИКе, 1927. — 86 б. (5 б. табл.)

Татар теле // Татарстан хәбәрләре. — 1920. — 7 сентябрь.

Татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре. — В кн. : 5 ел эчендә. — Казан: тип. "Камиль Якуб", 1925. — Б. 251-253.

Татар телен гамәлгә кую турындагы декрет, карар, циркуляр һәм башка материаллар. — Казан: Центр. комиссия РТЯ при Тат. ЦИКе, 1925. — 114 б.

Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясенең Татарстанның 6 нчы Советлар съездына хисабы. — Казан: Изд. ТЦИК, 1926. — 29 б.

Татар телен гамәлгә кую эше. — В кн.: Информ. бюллетень Тат. АССР. — Казань: Изд. СНК, 1923. — №14-15. — Б. 5-6.

Татар теле һәм мәдәнияте бүлеге турында // Мәгариф. — 1928. — №5. — Б. 68-69.

Таһири Ибраһим. Галимҗан Ибраһимовның телчелек, тарихчылык һәм тәнкыйтьчелеге. — В кн.: Галимҗан Ибраһимов. 20 еллык әдәби, гыйльми, иҗтимагый хезмәт туена каратылып чыгарылган мәҗмуга. — Ташкент, 1928. — Б. 23-25.

Тезисы к докладу Ш.Шаймарданова на 3-й сессии ТЦИК «О положении дела по РТЯ и перспективах». — Казань: Изд-во Гажур, 1927. — 23 с.

Телләр турындагы канун ничек үтәлә? // Мәдәни җомга. — 1998. — 11 декабрь.

Телле халык — илле халык // Әллүки. — 1997. — 30 май.

Тел фронтында ныклы үзгәреш кирәк. Г.Толымбайский доклады буенча карар // Колхоз яшьләре. — 1931. — №2.

Третья сессия ЦИК ТССР 3-го созыва 21—24 июля 1923г. /Стенограф. отчет/. — Казань: Изд. ЦИК, 1923. — 196 с.

Третья сессия ЦИК 5-го созыва (с 3-го по 5-е дек. 1925 г.). Стенографический отчет. — Казань: Изд. ЦИК ТССР, 1926. — 159 с.

Туган телдән йөзен чөергәннең Сукыр йолдыз янсын күгендә // Ватаным Татарстан. — 1996. — 7 декабрь.

Тумашева Д.Г. Развитие татарского языкознания в советскую эпоху и его задачи.- В кн.: Конф.- 50-летию СССР... Казань, 1972.- С. 69-78.

Тумашева Д.Г., Усманов М.А., Хисамова Ф.М. Об особенностях развития старотатарской деловой письменности // Советская тюркология. — 1977. — №3. — С. 51-66.

Тутаев М.З. Развитие народного образования в Татарии (1917-1940 гг.). — Казань: Тат. кн. изд-во, 1975. — 204 с.

Фазлулла М. Татар теле белегенә мәдхәл // Мәгариф. — 1923. — №7-8. — Б. 52-57; №9-10. — Б. 41-48.

Фасхи. Профсоюзы и национальный вопрос // Известия ТатЦИКа. — 1923. — №285.

Фәтхи. Тагын татар теле хакында // Татарстан хәбәрләре. — 1921. — 13 июль.

Фәтхи. Татар телен гамәлгә кую эшләре // Татарстан хәбәрләре. — 1922. — 4 сентябрь.

Фәтхи. Татар телен гамәлгә куюны гавәмләштерү // Татарстан хәбәрләре. — 1922. — №194.

Фәтхи. Урыннарда татар теле мәсьәләсе // Татарстан хәбәрләре. — 1922. — 20 август.

Фирсов. Общество татароведения // Известия ТатЦИКа. — 1923. — №229.

Хаков В.Х. Г. Ибраһимов — күренекле тел галиме. — В кн.: Тат. тел бел... 3 китап. — Казан: КДУ нәшр., 1969. — Б. 5-19.

Хаков В.Х. Некоторые вопросы и задачи изучения истории татарского литературного языка. — В кн.: Вопр. тат. яз-ия. — Казань, 1971. — С. 120-129.

Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. — Казан: Тат. китап нәшр., 1972. — 221 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теленең совет чорында үсеше (20-30 нчы еллар). — Казан: КДУ нәшр., 1985. — 148 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы. — Казан: КДУ нәшр., 1993. — 325 б.

Хаков В.Х. Әдипнең татар телен гамәлгә кую өлкәсендәге эшчәнлеге (Г. Ибраһимов турында) // Совет мәктәбе. — 1977. — №3. — Б. 34-37.

Ханазаров К.Х. Решение национально-языковой проблемы в СССР. — М.: Политиздат, 1982. — 224 с.

Харисов Ф. О языковой ситуации в бывшем СССР // Научный Татарстан. — 1998. — №3. — С. 54-57.

Харисов Ф. Проблемы возрождения и сохранения языков этносов в поликультурном обществе // Мәгариф. — 1998. — №9. — Б. 49-51.

Харисов Ф.Ф. Рус телендә сөйләшүче балаларны татарчага өйрәтүнең башлангыч чоры: Укытучылар өчен методик кулланма. — Казан: Мәгариф, 1996. — 43 б.

Харисов Ф.Ф. «Учредить единожды всегда...» Социально-исторические условия обучения татарскому языку русских и других народов: Учебное пособие. — Казань: «Таң—Заря», 1995. — 58 с.

Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов. — Казань: Тат. кн. изд-во, 1977. — 432 с.

Хатипов Ф. Өметебез татар мәктәбендә // Әллүки. — 1993. — 23 май.

Хәсәнов Җәләл. Тел мәсьәләләре // Мәгариф эшчесе. — 1926. — №1. — Б. 19-30.

Хисамова Ф.М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре. — Казан: КДУ нәшр., 1981. — 162 б.

Хисамова Ф.М. Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности (XVII — XIX вв.): Автореф. дис...доктора филол. наук. — Казань, 1995. — 57 с.

Һадиуллин И. Туган телдә өзлексез белем бирелсен // Мәгариф. — 1998. — №9. — Б. 63-64.

Центральный государственный архив ТАССР. Путеводитель. — Казань: Тат. кн. изд-во, 1967. — 278 с.

Четвертая сессия ЦИК ТССР 7-го созыва. 12-14 февраля 1928 г. — Казань: Изд. ЦИК ТССР, 1928. — 108 с.

Шәймәрдәнов Ш. Татар телен тормышка үткәрү эшенең хәзерге һәм киләчәге турында. — Казань: тип. "Восток", 1927. — 31 б.

Шаймарданов Ш. Дорогу татарскому языку // Красная Татария. — 1926. — 12 февраля.

Шараф Г. К вопросу о принятии для тюркских народностей латинского шрифта // ВНОТ. — 1926. — №5. — С. 15-80.

Шнаси. Ун ел эчендә Татарстанда гыйльми атамалар эшләү нәтиҗәсе // Мәгариф. — 1927. — Б. 66-71.

Этническое и языковое самосознание. Материалы конференции (Москва, 13-15 декабря 1995 г.). — М.: Фианфонд, 1995. — 172 с.

Юлдашев А.А. Изучение татарского языка в советскую эпоху. — В кн. : Пробл. тюркологии — 1964. — Казань: Изд-во КГУ, 1964. — С. 25-42.

Юсупов Р.А. Горур булыйк! // Ватаным Татарстан. — 1996. — 24 декабрь.

Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы: Укытучылар өчен ярдәмлек. — Казан: Тат. китап нәшр., 1987. — 214 б.

Юсупов Р.А. Педагогик югары уку йортларында татар теле // Мәгариф. — 1998. — №9. — Б. 71-75.

Юсупов Ф.Ю. Деятельность Галимджана Шарафа в области языкознания. — В кн. : Сб. научн. раб... — Казань: Изд-во КГУ, 1966. — С. 122—129.

Юсупова Ә.Ш. Әхмәтһади Максуди үзөйрәткече // Мәгариф. — 1996. — №5. — Б. 13-14.

Юсупова А.Ш. Историко-лингвистическая характеристика и анализ самоучителей и разговорников татарского языка конца XVII — начала XX вв.: Автореф. дис...канд. филол. наук. — Казань, 1994. — 18 с.

Языковая политика в Республике Татарстан: Документы и материалы (20-30-е гг.). — Казань: Магариф, 1998. — 207 с.

Языковая ситуация в Республике Татарстан: состояние и перспективы (Материалы научно-практической конференции. 17 ноября 1998 года). В 2-х частях. — Казань: Изд-во «Мастер Лайн», 1999. — Ч.I. — 212 с., Ч. II. — 264 с.

Языковая ситуация в Российской Федерации. — М., 1992.

Языковые проблемы Российской Федерации и Законы о языках. — М., 1994.

Якупова Г. К. Библиография по татарскому языкознанию (1778—1980). — Казань: Таткнигоиздат, 1988. — 132 с.

## Татарстан Республикасының Милли архив материаллары

Ф. Р-128. Халык комиссарлары Советы (СНК).

Оп. 1.

Д. 641. Переписка с ТатЦИКом о РТЯ (8 декабря 1925 г. — 27 августа 1926 г.). — 46 л.

Д. 771. Переписка с ЦК по РТЯ при ТатЦИКе о РТЯ (17 марта 1926 г. — 1 февраля 1927 г.). — 66 л.

Д. 1065. Переписка с ЦК по РТЯ и коренизации аппарата ЦИК и СНК ТАССР (2 января 1928 г. — 5 декабря 1930 г.). — 20 л.

Д. 2010. Программы и учебные планы по подготовке председателей и секретарей сельсоветов ТАССР (26 ноября 1933 г. — 16 ноября 1934 г.). — 116 л.

Д. 2012. Материалы по проведению курсовых мероприятий (21 декабря 1933 г. — 31 декабря 1934 г.). — 249 л.

Д. 2284. Учебные планы и программы по подготовке и переподготовке кадров районных инструкторов при ТатЦИКе (8 января — 20 апреля 1934 г.). — 203 л.

Д. 2291. Материалы о работе курсов РТЯ (17 января — 19 февраля 1934 г.). — 32 л.

Д. 2529. Учебные планы и программы одномесячных районных курсов по переподготовке секретарей сельсоветов (1 января — 25 декабря 1935 г.). — 237 л.

Д. 2530. Учебные планы и программы двухмесячных курсов по подготовке председателей сельсоветов (25 января — 25 марта 1935 г.). — 29 л.

Д. 2531. Учебные планы и программы двухмесячных курсов по подготовке машинисток при ТатЦИКе (5 мая — 5 июля 1935 г.). — 28 л.

Ф. 3682. Мәгариф халык комиссариаты (Наркомпрос).

Оп. 1.

Д. 2. Протоколы заседаний Президиума Наркомпроса ТАССР и материалы к ним. Подлинники (12 августа — 3 декабря 1920 г.). — 203 л.

Д. 5. Протоколы заседаний Коллегии Наркомпроса ТАССР и его отделов (15 октября — 7 декабря 1920 г.). — 133 л.

Д. 7. Протоколы заседаний Коллегии Наркомпроса ТАССР и его отделов, положение об отделе Снабжения и список инструкторов Наркомпроса по кантонам ТАССР (24 ноября — 20 декабря 1920 г.). — 114 л.

Д. 24. Текстовые отчеты о деятельности Наркомпроса ТАССР и его отделов за 1920-1921 гг. — 132 л.

Д. 25. Статистические сведения о населении ТАССР, о количестве детей дошкольного и школьного возраста, детских учреждениях, сети культурно-просветительных учреждений и др. за 1920, 1922 и январь 1923 г. — 43 л.

Д. 59. Протоколы заседаний Президиума, Коллегии и подотделов Наркомпроса ТАССР и материалы к ним. Подлинники (4 января — 30 декабря 1921 г.). — 437 л.

Д. 62. Протоколы заседаний Президиума, Коллегии Наркомпроса ТАССР, Казгорроно и отчеты о деятельности КОНО за 1921 г. (1 февраля — 10 августа 1921 г.). — 41 л.

Д. 75. Текстовые отчеты о деятельности Наркомпроса ТАССР и его отделов за 1920-1921 гг. — 124 л.

Д. 76. Текстовые отчеты о деятельности Наркомпроса ТАССР за 1921 г. и июнь 1922 г. — 232 л.

Д. 283. Протоколы заседаний Президиума и Коллегии Наркомпроса ТАССР. Подлинники (2 января — 30 декабря 1922 г.). — 111 л.

Д. 288 а. Отчеты о работе Наркомпроса и Главполитпросвета ТАССР (1 января — 22 сентября 1922 г.). — 115 л.

Д. 288 б. Отчеты и сводки о работе Наркомпроса и Главполитпросвета ТАССР (27 января — 25 ноября 1922 г.). — 325 л.

Д. 409. Циркуляры, положения, приказы, протоколы заседаний Коллегии Наркомпроса ТАССР и отдела (1 февраля — 28 декабря 1922 г.). — 56 л.

Д. 410. Протоколы заседаний Коллегии Наркомпроса, Академцентра, научно-методической комиссии нацменьшинств при Академцентре НКП ТАССР и материалы к ним (22 февраля 1922 г. — 13 мая 1924 г.). — 160 л.

Д. 488. Протоколы заседаний коллегии Академцентра при Наркомпросе ТАССР и протоколы заседаний и совещаний временных комиссий при Академцентре (22 февраля — 23 апреля 1923 г.). — 13 л.

Д. 489. Протоколы заседаний научно-педагогической комиссии Академцентра Наркомпроса ТАССР. Подлинники (8 февраля — 28 декабря 1923 г.). — 51 л.

Д. 501. Текстовой отчет о деятельности Наркомпроса ТАССР за 1922/23 гг. — 100 л.

Д. 526. Постановления, циркуляры и инструкции Наркомпроса ТАССР (копии) (29 января — 21 декабря 1923 г.). — 136 л.

Д. 627. Протоколы заседаний Коллегии и Президиума Наркомпроса ТАССР (3 января — 30 сентября 1924 г.). — 125 л.

Д. 628. Протоколы заседаний Президиума и Коллегии Наркомпроса ТАССР. Подлинники (1 октября 1924 г. — 28 сентября 1925 г.). — 150 л.

Д. 690. Академический Центр. Протоколы заседаний Президиума отдела (25 сентября 1924 г. — 30 сентября 1926 г.). — 41 л.

Д. 997. Материалы о деятельности Наркомпроса ТАССР (15 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 907 л.

Д. 1108. Протоколы заседаний Президиума и Коллегии ТАССР (подлинники) (23 февраля 1926 г. — 30 сентября 1927 г.). — 87 л.

Д. 1147. Сводные отчеты о деятельности Наркомпроса ТАССР за 1926-27 гг. — 79 л.

Д. 1148. Текстовые отчеты о деятельности Наркомпроса ТАССР за 1925/26 учебный год (27-30 сентября 1925 г.). — 261 л.

Д. 1149. Материалы о деятельности Наркомпроса ТАССР (1 октября 1926 г. — 30 января 1927 г.). — 18 л.

Д. 1154. Статистические сведения о количестве ВУЗов, о сети учреждений и профтехобразования, о школах, о наличии учащихся школ ФЗУ и курсов по г. Казани и по ТАССР за 1925/26 уч. год. — 103 л.

Д. 1155. Статистические сведения о количестве учащихся нацменьшинств в ВУЗах и профтехнических учебных заведениях г. Казани за 1925/26 уч. год (списки студентов Татглавпрофобра). — 98 л.

Д. 1166. Протоколы конференции работников просвещения школ 1-й и 2-й ступени города Казани (2 июня — 3 сентября 1926 г.). — 42 л.

Д. 1167. Протоколы заседаний методической конференции КОНО (27 января 1926 г. — 15 сентября 1926 г.). — 83 л.

Д. 1168. Протоколы заседаний редакционной коллегии ТатГИЗа (копии) (1 октября 1926 г. — 21 июня 1927 г.). — 35 л.

Д. 1170. Отчеты о деятельности Академцентра НКПроса ТАССР за 1925/26 уч. год (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 126 л.

Д. 1171. Материалы о деятельности Академцентра НКПроса ТАССР и подведомсвенных ему учреждений (29 декабря 1926 г. — 24 июня 1927 г.). — 127 л.

Д. 1172. Материалы о деятельности Научно-методической комиссии Академцентра (1 октября 1926 г. — 30 сентября 1927 г.). — 64 л.

Д. 1175. Материалы о применении комплексной системы преподавания в условиях ТАССР (1 октября 1926 г. — 30 сентября 1927 г.). — 174 л.

Д. 1189. Протоколы заседаний Научно-контрольного бюро ВСФК при ЦИКе ТАССР и материалы к ним (10 июля — 15 апреля 1926 г.). — 36 л.

Д. 1190. Протоколы заседаний Президиума методического Совета при Наркомпросе и Наркомздраве ТАССР (1 октября 1926 г. — 30 августа 1927 г.). — 70 л.

Д. 1191. Протоколы заседаний научно-педагогической комиссии Академцентра НКПроса ТАССР (16 ноября 1926 г. — 2 августа 1927 г.). — 41 л.

Д. 1192. Переписка с КОНО об организации методической работы (23 ноября 1926 г. — 30 сентября 1927 г.). — 229 л.

Д. 1201. Протоколы III общегородской конференции работников просвещения, школ 1-й и 2-й ступени города Казани (4-29 мая 1926 г.). — 8 л.

Д. 1206. Производственные планы Главсоцвоса на 1926/27 уч. год. — 62 л.

Д. 1207. Производственные планы отделов НКПроса ТАССР на 1926/27 уч. год. — 41 л.

Д. 1214. Материалы конференции школьных работников 2-й ступени г. Казани (29-30 марта 1926 г.). — 111 л.

Д. 1239. Материалы обследования школ г. Казани (31 декабря 1926 г. — 31 января 1927 г.). — 37 л.

Д. 1240. Материалы обследования татарских школ 1-й ступени г. Казани за 1926/27 уч. год (27 февраля — 28 мая 1927 г.). — 73 л.

Д. 1261. Перспективный план подготовки научных работников по ВУЗам г. Казани на 1926-1931 гг. и списки профессоров, доцентов, преподавателей и студентов ВУЗов г. Казани. — 169 л.

Ф. Р-732. Татарстан Үзәк башкарма комитеты (ТатЦИК).

Оп. 1.

Д. 4. Протоколы заседаний Президиума ТатЦИКа (28 сентября 1920 г. — 15 июля 1921 г.). — 217 л.

Д. 7. Протоколы пленарного заседания ТатЦИКа, 2-й сессии ВсеТатЦИКа и переписка о созыве и проведении 1-й сессии ВсеТатЦИКа (20 сентября 1920 г. — 10 декабря 1921 г.). — 140 л.

Д. 8. Материалы I съезда Советов ТАССР, I-й, II-й и III-й сессий ТатЦИКа (копии) (26 сентября 1920 г. — 24 мая 1921 г.). — 139 л.

Д. 9. Материалы о годовщине празднования ТАССР (28 ноября 1920 г. — 20 августа 1921 г.). — 172 л.

Д. 20. Стенограмма I съезда Советов ТАССР и 1-й сессии ТатЦИКа (копии) (26 сентября 1920 г. — 3 декабря 1922 г.). — 40 л.

Д. 49. Протоколы ЦИКа ТССР (протоколы заседаний Президиума) (1 октября — 6 декабря 1921 г.). — 103 л.

Д. 50. Постановления ТатЦИКа и объединенные постановления ТатЦИКа и СНК (копии) (23 июля 1921 г. — 20 мая 1922 г.). — 59 л.

Д. 51. Штатное расписание ВсеТатЦИКа на 1921 г. Списки сотрудников (13 марта — 31 декабря 1921 г.). — 70 л.

Д. 52. Протоколы заседаний и резолюции 2-й, 3-й, 4-й сессий ТатЦИКа (29 ноября 1921 г. — 25 июня 1922 г.). — 50 л.

Д. 53. Протоколы заседаний Президиума ТЦИКа ТАССР (2-й созыв) (31 июня 1921 г. — 1 декабря 1922 г.). — 106 л.

Д. 54. Протоколы заседаний Президиума ТЦИКа (30 июня 1921 г. — 31 октября 1922 г.). — 185 л.

Д. 55. Стенограмма 2-го съезда Советов ТАССР, 1-й, 2-й и 3-й сессий ТатЦИКа 2-го созыва (25 июня 1921 г. — 24 февраля 1922 г.). — 200 л.

Д. 56. Стенограмма 2-й сессии ТатЦИКа (1-го созыва) (2 марта 1921 г.). — 27 л.

Д. 57. Стенограмма 3-й сессии ТатЦИКа (1-го созыва) (21 мая 1921 г.). — 32 л.

Д. 59. Отчет о деятельности ТатЦИКа за период с 30 июня по 15 ноября 1921 г. Ежедневные информации о работе Президиума ТатЦИКа с 30 июня 1921 г. по 11 апреля 1922 г. (30 июня 1921 г. — 14 апреля 1922 г.). — 48 л.

Д. 86. Списки ответственных работников Наркоматов и ТатЦИКа за 1921 г. (30 сентября — 21 декабря 1921 г.). — 179 л.

Д. 87. Списки ответственных работников Наркоматов и кантисполкомов. — 59 л.

Д. 114. Постановления ТатЦИКа и СНК и материалы к ним (17 ноября 1922 г. — 19 декабря 1923 г.). — 892 л.

Д. 115. Приказы по Управлению делами ТатЦИКа. Сведения о структуре и штатах ТатЦИКа (2 января — 30 декабря 1922 г.). — 98 л.

Д. 116. Протокол заседания 1-й сессии ТатЦИКа 3-го созыва от 11 декабря 1922 г. — 1 л.

Д. 117. Протоколы заседаний Президиума ТатЦИКа и материалы к ним (9 сентября — 14 декабря 1922 г.). — 344 л.

Д. 117 б. Материалы с протоколами заседаний президиума ТЦИКа 3-го созыва (13 декабря 1922 г. — 29 декабря 1923 г.). — 794 л.

Д. 118. Протоколы 1-3 заседаний Малого Президиума ТатЦИКа (13-24 декабря 1922 г.). — 12 л.

Д. 119. Протоколы заседаний Комиссии ТатЦИКа по пересмотру советских учреждений и материалы к ним (16 мая — 11 декабря 1922 г.). — 72 л.

Д. 120. Стенограмма 3-го съезда Советов ТАССР (7 декабря 1922 г. — 11 января 1923 г.). — 522 л.

Д. 121. Стенограмма 3-й сессии ТатЦИКа (2-го созыва) (24-27 февраля 1922 г.). — 72 л.

Д. 122. Циркуляры, инструкции и другие материалы, поступившие для сведения в ТатЦИК, Татпредставительства и других учреждений (18 января — 30 сентября 1922 г.). — 188 л.

Д. 123. Статистические сведения о политико-просветительных учреждениях в Казани и кантонах. Сведения о штатах НКПроса и Главполитпросвета (5 мая — 28 октября 1922 г.). — 97 л.

Д. 135. Перечень декретов и постановлений ТЦИКа и СНК (13 декабря 1922 г. — 14 декабря 1923 г.). — 35 л.

Д. 136. Перечень протоколов Президиума и Секретариата ТатЦИКа. Списки комиссий при ТатЦИКе за 1922-1927 гг. — 73 л.

Д. 137. Циркуляры и совместные постановления ТатЦИКа и СНК (копии) (27 декабря 1922 г. — 6 марта 1923 г.). — 99 л.

Д. 138. Протоколы и другие материалы 3-го съезда Советов ТР и 1-й сессии ТатЦИКа 3-го созыва (5 декабря 1922 г. — 25 марта 1923 г.). — 123 л.

Д. 139. Протоколы заседаний Президиума ТатЦИКа (11 декабря 1922 г. — 16 декабря 1923 г.). — 87 л.

Д. 154. Обзор деятельности ТатЦИКа и его комиссии. Докладные записки о деятельности кантисполкомов (11 января — 16 декабря 1922 г.). — 347 л.

Д. 192. Собрание узаконений и распоряжений рабочего и крестьянского правительства ТАССР (27 апреля 1922 г. — 12 сентября 1923 г.). — 48 л.

Д. 193. Циркуляры ТатЦИКа кантисполкомам и наркоматам (26 января — 27 декабря 1923 г.). — 46 л.

Д. 194. Протоколы 1-8 4-го съезда Советов ТАССР и списки делегатов (копии) (7-24 декабря 1923 г.). — 36 л.

Д. 195. Протоколы 1-54 заседаний Президиума ТатЦИКа и материалы к ним (копии) (6 января — 16 декабря 1923 г.). — 103 л.

Д. 196. Протоколы 1-25 заседаний Президиума ТатЦИКа (подлинники) (28 декабря 1923 г. — 21 декабря 1924 г.). — 52 л.

Д. 197. Материалы к протоколам президиума ЦИК ТАССР за 1923 г. (4 мая — 16 августа 1923 г.). — 563 л.

Д. 198. Протоколы 40-50 заседаний Президиума ТатЦИКа и материалы к ним (20 сентября — 16 декабря 1923 г.). — 409 л.

Д. 199. Протокол 1-го заседания Президиума ТатЦИКа от 28 декабря 1923 г. и материалы к нему. — 90 л.

Д. 200. Стенограмма 4-го съезда Советов ТАССР (17 декабря — 26 декабря 1923 г.). — 417 л.

Д. 211. Циркуляры, распоряжения, выписки протоколов ВЦИКа (30 января — 20 октября 1923 г.). — 78 л.

Д. 212. Циркуляры ТатЦИКа Наркоматам и кантисполкомам (12 января — 17 декабря 1923 г.). — 141 л.

Д. 220. Протокол заседания 1-й сессии ТатЦИКа от 26 декабря 1923 г. о составе Президиума ЦИКа и СНК. Списки членов и кандидатов ТатЦИКа, народных комиссаров, председателей КИКов, делегатов 4-го съезда Советов и др. (26 декабря 1923 г. — 25 октября 1924 г.). — 262 л.

Д. 221. Протоколы заседаний Президиума и Секретариата ТатЦИКа (копии) (28 декабря 1923 г. — 9 сентября 1924г.). — 71 л.

Д. 238. Отчеты о деятельности Наркоматов и других республиканских учреждений ТАССР за 1922 и 1923 гг. (3-8 ноября 1923 г.). — 113 л.

Д. 248. Месячные отчеты и сводки о работе наркоматов и кантисполкомов ТАССР за 1922 и 1923 гг. (1 января — 30 августа 1923 г.). — 410 л.

Д. 252. Статистические сведения о составе ТатЦИКа. Списки членов и кандидатов ТатЦИКа и КИКов, председателейи членов КИКов (12 мая — 10 декабря 1923 г.). —112 л.

Д. 262. Материалы о деятельности комиссии по РТЯ (8 марта 30 октября 1923 г.). — 37 л.

Д. 336. Протокол №2 заседания Президиума ТатЦИКа от 12 января 1924 г. И материалы к нему (копия). — 35 л.

Д. 337. Протокол №3 заседания Президиума ТатЦИКа от 8 февраля 1924 г. и материалы к нему (копия). — 173 л.

Д. 446. Доклады о работе Комиссии по РТЯ (18 января — 20 июля 1924 г.). — 11 л.

Д. 520. Постановление и инструкция ТатЦИКа по РТЯ (копии) (11 мая — 6 августа 1924 г.). — 5 л.

Д. 521. Протоколы заседаний Президиума ЦК по РТЯ при ТатЦИКе (16 января — 20 августа 1924 г.). — 12 л.

Д. 522. Протокол торжественного заседания Комиссии по РТЯ от 19 апреля 1922 г. (18 января — 1 июня 1924 г.). — 11 л.

Д. 523. Протоколы заседаний совета курсов по РТЯ (13 февраля — 9 августа 1924 г.). — 25 л.

Д. 524. Протоколы заседаний Президиума курсов по РТЯ (13 февраля — 9 августа 1924 г.). — 34 л.

Д. 525. Протоколы пленарного заседания курсантских организаций при курсах РТЯ от 5 января 1924 г. — 5 л.

Д. 526. Материалы комиссии по РТЯ (1 января — 31 декабря 1924 г.). — 290 л.

Д. 527. Материалы о деятельности ЦК по РТЯ (1 января — 31 декабря 1924 г.). — 143 л.

Д. 528. Материалы о деятельности кантонных комиссий по РТЯ (Агрызский, Арский, Бугульминский, Буинский, Елабужский, Лаишевский кантоны) (1 января — 31 декабря 1924 г.). — 129 л.

Д. 529. Материалы о деятельности кантонных комиссий по РТЯ (Мамадышский, Мензелинский, Свияжский, Спасский кантоны за 1924 г.). — 106 л.

Д. 530. Материалы о деятельности кантонных комиссий по РТЯ (Тетюшский, Челнинский, Чистопольский кантоны за 1924 г.). — 152 л.

Д. 531. Материалы курсов по РТЯ (11 января — 29 сентября 1924 г.). — 186 л.

Д. 532. Материалы о работе курсов по РТЯ (1 февраля — 4 августа 1924 г.). — 24 л.

Д. 659. Статистические сведения по учету личного состава ТатЦИКа, СНК, Наркоматов, кантонных, волостных и сельских советов. Т. 1. (1 января — 10 октября 1925 г.). — 622 л.

Д. 660. Статистические сведения по учету личного состава ТатЦИКа, СНК, Наркоматов, кантонных, волостных и сельских советов. Т. 2. (1 октября — 10 декабря 1925 г.). — 115 л.

Д. 766. Статистические сведения о национальном составе центральных и подведомственных им организаций в республике. Списки членов кантонных комиссий по РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 204 л.

Д. 767. Материалы ЦК по РТЯ при ТатЦИКе (21 января 1925 г. — 7 мая 1926 г.). — 69 л.

Д. 768. Материалы о деятельности ЦК по РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 297 л.

Д. 769. Материалы о деятельности ЦК по РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 октября 1926 г.). — 235 л.

Д. 770. Материалы о деятельности кантонных комиссий по РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 октября 1926 г.). — 99 л.

Д. 771. Материалы о работе по РТЯ в различных организациях и учреждениях (1 октября 1925 г. — 6 сентября 1926 г.). — 126 л.

Д. 772. Материалы о РТЯ по НКВД (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 62 л.

Д. 773. Материалы о РТЯ по Наркомату РКИ (14 января 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 39 л.

Д. 774. Материалы о РТЯ по Татпрофсовету и обкомам профсоюза (30 августа 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 51 л.

Д. 775. Материалы о РТЯ по Татсовнархозу (21 октября 1925 г. — 2 августа 1926 г.). — 178 л.

Д. 776. Материалы о РТЯ по Татстатуправлению (19 ноября 1925 г. — 21 сентября 1926 г.). — 13 л.

Д. 777. Материалы о РТЯ по ГПУ ТАССР (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 15 л.

Д. 778. Материалы о работе курсов по РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 397 л.

Д. 779. Переписка с Татобкомом ВКП(б) о РТЯ (7 октября 1925 г. — 29 сентября 1926 г.). — 41 л.

Д. 780. Переписка с исполкомами автономных республик и областей о РТЯ (октябрь 1925 г. — октябрь 1926 г.). — 70 л.

Д. 781. Переписка с СНК и ЭКОСО о РТЯ (октябрь 1925 г. — сентябрь 1926 г.). — 66 л.

Д. 782. Переписка с Наркоматом здравохранения о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 48 л.

Д. 783. Переписка с НКТрудом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 74 л.

Д. 784. Переписка с НКФином о РТЯ (октябрь 1925 г. — сентябрь 1926 г.). — 164 л.

Д. 785. Переписка с Управлением Коммунального Хозяйства, управлением связи и др. учреждениями о трудоустройстве работников-татар (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 111 л.

Д. 786. Переписка с почтово-телеграфным ведомством о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 91 л.

Д. 787. Переписка с Арским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 85 л.

Д. 788. Переписка с Бугульминским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября г.). — 107 л.

Д. 789. Переписка с Буинским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября г.). — 53 л.

Д. 790. Переписка с Елабужским КИКом по РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября г.). — 76 л.

Д. 791. Переписка с Мензелинским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 71 л.

Д. 792. Переписка со Свияжским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 105 л.

Д. 793. Переписка со Спасским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 января 1926 г.). — 59 л.

Д. 794. Переписка с Тетюшским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 октября 1926 г.). — 176 л.

Д. 795. Переписка с Челнинским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 165 л.

Д. 796. Переписка с Чистопольским КИКом о РТЯ (1 октября 1925 г. — 30 сентября 1926 г.). — 93 л.

Д. 797. Переписка с Агрызским и Казанским горсоветом о РТЯ (2 июня — 23 июня 1926 г.). — 3 л.

Д. 798. План работы Комиссии по РТЯ на февраль-октябрь 1925 г. и отчет о работе за 1923-1924 гг.(3 января — 12 февраля 1925 г.). — 17 л.

Д. 945. Материалы о приеме учащихся и студентов на рабфаки и в вузы (19 марта — 18 сентября 1926 г.). — 135 л.

Д. 950. Анкеты делегатов 6-го съезда Советов ТАССР (март 1926 г.). — 140 л.

Д. 984. Переписка с предприятиями о РТЯ (10 апреля 7 сентября 1926 г.). — 87 л.

Д. 1110. Статистические сведения о ходе перевыборной кампании в Казанский горсовет. Списки делегатов 7-го съезда Советов ТАССР (12 апреля — 18 октября 1927 г.). — 98 л.

Д. 1138. Материалы о коренизации советского аппарата и РТЯ в республике за 1927 г. (1 января — 1 декабря 1927 г.). — 126 л.

Д. 1307. Материалы о состоянии сельского хозяйства в республике, о коренизации аппарата и РТЯ, о чистке низового советского аппарата, о развитии меховой промышленности и др. (6 июня 1929 г. — 5 ноября 1930 г.). — 429 л.

Д. 1342. Статистические сведения о выборах в Казанский горсовет. Мандаты и удостоверения делегатов 8-го Всетатарского съезда Советов (25 января — 26 апреля 1929 г.). — 112 л.

Д. 1367. Материалы о ходе работы по РТЯ в республике (18 сентября 1929 г. — 27 мая 1930 г.). — 71 л.

Д. 1559. Материалы о командировании рабочих и служащих на курсы и рабфаки (10 июня — 22 сентября 1931 г.). — 91 л.

Д. 2809. Сведения о состоянии работы по коренизации аппарата ТатЦИКа и СНК, Наркоматов и перевод делопроизводства на татарский язык (20 апреля — 10 ноября 1936 г.). — 52 л.

Оп. 9.

Д. 1. Анкеты и личные карточки членов ТатЦИКа (2-31 декабря 1920 г.). — 78 л.

Д. 2. Анкеты членов ТатЦИКа 2-го созыва (29 июля 1921 г. — 12 апреля 1922 г.). — 67 л.

Д. 6. Анкеты членов ТатЦИКа 4-го созыва. 1924 г. — 85 л.

Д. 8. Личное дело председателя ТатЦИКа Шаймарданова Шайгардана (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 2 л.

Д. 11. Личное дело секретаря ТатЦИКа Петрова Н.В. (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 2 л.

Д. 38. Личное дело члена ТатЦИКа Ибрагимова Г.Г. (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 1 л.

Д. 60. Личное дело члена ТатЦИКа Сабирова Р.А. (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 1 л.

Д. 71. Личное дело члена ТатЦИКа Усманова Ш. (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 1 л.

Д. 74. Личное дело члена ЦИКа ТССР Чанышева Якуба Джангировича (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 15 л.

Д. 120. Личное дело Наркома Просвещения ТАССР Ахмадеева Шагида Гимадутдиновича (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 7 л.

Д. 131. Личное дело начальника Центральной Военно-Тюркской школы Еникеева Нигмата (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 1 л.

Д. 138. Личное дело лектора Татарского Коммунистического университета Курбангалиева Мухутдина Хафизовича (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 3 л.

Д. 146. Личное дело заместителя Наркома земледелия ТАССР Сайфи Фатыха Камалетдиновича (9 января 1925 г. — 7 марта 1926 г.). — 2 л.

Д. 164. Личное дело председателя ТатЦИКа Шаймарданова Шайгардана (27 декабря 1926 г.). — 3 л.

Д. 174. Личное дело председателя ТатЦИКа Ахмедишина Миннигарея Ахметовича (21 сентября 1927 г. — 9 мая 1929 г.). — 2 л.

Д. 174 а. Личное дело председателя ТЦИКа Муратхузина Хариса Ибрагимовича (9 мая 1929 г.). — 5 л.

Д. 175. Личное дело секретаря ТатЦИКа Богаутдинова Гимаза Богаутдиновича (март 1927 г. — 1 января 1930 г.). — 7 л.

Оп. 10.

Д. 4. Приказы по Управлению делами ВсеТатЦИКа по личному составу (1 февраля — 30 октября 1921 г.). — 45 л.

Д. 6. Приказы по Управлению делами ТатЦИКа о личном составе (копии) (17 ноября 1921 г. — 30 декабря 1922 г.). — 22 л.

Д. 18. Приказы по Управлению делами ТатЦИКа по личному составу (4 января — 31 декабря 1923 г.). — 233 л.

Д. 25. Анкеты сотрудников ЦИКа ТР. 1924 г. — 224 л.

Д. 35. Материалы о сотрудниках Комисси по РТЯ при ТЦИКе Космине А.С. и Юнусове Н.З. (1 января — 31 декабря 1924 г.). — 6 л.

Д. 43. Анкеты и заявления граждан о принятии на работу по линии РТЯ. Том 1 (1 января — 31 декабря 1924 г.). — 719 л.

Д. 44. Анкеты и заявления граждан о принятии на работу по линии РТЯ. Том 2 (1 августа — 31 декабря 1926 г.). — 498 л.

Д. 50. Анкеты и заявления граждан о направлении на работу по линии РТЯ (1 октября 1925 г. — 9 октября 1926 г.). — 604 л.

Д. 51. Анкеты и заявления граждан о принятии на работу по линии РТЯ (1 октября 1925 г. — 31 марта 1926 г.). — 35 л.

Д. 52. Приказы по Секретариату и Управлению делами ТатЦИКа по личному составу (12 октября 1926 г. — 15 августа 1927 г.). — 35 л.

Д. 55. Анкеты и заявления граждан о принятии на работу по линии РТЯ (1 января — 31 декабря 1926 г.). — 681 л.

Д. 56. Анкеты и заявления граждан о принятии на работу по линии РТЯ (1 октября — 29 ноября 1926 г.). — 544 л.

Д. 57. Анкеты и заявления граждан о принятии на работу по линии РТЯ (1 июня — 30 сентября 1926 г.). — 445 л.

Д. 73. Личное дело ответственного секретаря ЦК РТЯ Камалетдинова Зияутдина Камалетдиновича (17 сентября 1929 г.). — 1 л.

Д. 88. Свидетельства об окончании курсов по РТЯ. 1931 г. — 113 л.

## Эчтәлек

**Кереш**

**1 бүлек. Татар телен гамәлгә куюның гомуми мәсьәләләре.**

1.1. «Татар телен гамәлгә кую» (ТТГК) атамасы.

1.2. Татар телен гамәлгә куюның тарихи алшартлары.

1.3. Беренче Декрет һәм эшнең башлануы.

1.4. ТТГКның максат һәм бурычлары.

1.5. ТТГК Үзәк комиссиясе эшчәнлеге.

1.5.1. Төзелеше.

1.5.2. Инструкторлар эшчәнлеге.

1.5.3. Үзәк комиссиянең бурыч һәм хокуклары.

1.5.3.1. ТТГК эше белән җитәкчелек итү, законнар чыгару.

1.5.3.2. Татар хезмәткәрләрен исәпкә алу һәм эшкә урнаштыру.

1.5.3.3. Курслар оештыру.

1.5.3.4. Татарча шрифтлы язу машиналары әзерләү.

1.5.3.5. Башка республикалар белән бәйләнеш.

1.6. ТТГКның төп этаплары.

**2 бүлек. Халык комиссариатларында һәм үзәк оешмаларда татар телен гамәлгә кую.**

2.1. Дәүләт учреждениеләрендә ТТГК максатында кабул ителгән карар һәм инструкцияләр.

2.2. Элемтә идарәсендә ТТГК.

2.3. Сәламәтлек саклау халык комиссариаты.

2.4. Эчке эшләр халык комиссариаты.

2.5. Юстиция халык комиссариаты.
2.6. Финанс халык комиссариаты.
2.7. Татар статистика идарәсе (ТСУ).
2.8. Иҗтимагый тәэминат халык комиссариаты.
2.9. Коммуналь хуҗалык идарәсе.
2.10. Кооператив оешмалар.
2.11. Кредит органнары.
2.12. Нәтиҗәләр.
**3 бүлек. Мәгариф өлкәсендә татар телен гамәлгә кую.**
3.1. Социаль тәрбия бирү баш идарәсендә ТТГК.
3.2. Профессиональ белем бирү баш идарәсе.
3.3. Гыйльми үзәк (Академцентр) эшчәнлеге.
3.3.1. Фәнни-педагогик эшчәнлек.
3.3.2. Редакция-нәшрият эшчәнлеге.
3.3.3. Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте (НОТ).
3.4. Нәтиҗә.
**4 бүлек. Кантон, волость һәм авыл советларында татар телен гамәлгә кую.**
4.1. Авыл советларында ТТГК.
4.2. Волостьларда ТТГК.
4.3. Кантоннарда ТТГК.
4.3.1. Минзәлә кантоны.
4.3.2. Мамадыш кантоны.
4.3.3. Арча кантоны.
4.3.4. Бөгелмә кантоны.
4.3.5. Тәтеш кантоны.
4.3.6. Чаллы кантоны.
4.3.7. Буа кантоны.

4.3.8. Лаеш кантоны.
4.3.9. Алабуга кантоны.
4.3.10. Зөя (Свияжск) кантоны.
4.3.11. Спас кантоны.
4.3.12. Чистай кантоны.
4.4. Нәтиҗәләр.
**5 бүлек. Татар телен гамәлгә кую Үзәк курслары һәм руслар өчен татар теле курс-түгәрәкләре эшчәнлеге.**
5.1. ТТГК Үзәк курслары.
5.1.1. Курсларны ачу идеясе һәм максатлары.
5.1.2. Төзелеше.
5.1.3. Кабул итү шартлары.
5.1.4. Әзерләгән белгечлекләре һәм чыгарылышларга күзәтү.
5.1.5. Уку юнәлешләре.
5.1.5.1. Татар теленең урыны.
5.1.6. Курсларда укытучылар.
5.1.7. Курсларның эшен татарчалаштыру.
5.1.8. Курсантлар тормышы.
5.1.9. Түгәрәкләр.
5.1.10. Махсус тикшерү комиссиясе.
5.1.11. Курсантларны эшкә урнаштыру.
5.1.12. Курсларның эшен тоткарлаучы сәбәпләр.
5.1.13. Курсларның эш нәтиҗәләре, әһәмияте.
5.2. Руслар өчен татар теле курс-түгәрәкләре.
5.2.1. Түгәрәкләрнең төп нигезләре.
5.2.2. Халык комиссариатлары һәм үзәк оешмалардагы

татар теле түгәрәкләре эшчәнлеге.
5.2.3. Кантоннардагы татар теле түгәрәкләре.
5.2.4. Русларга татар теле өйрәтү өчен вакыт күләмен билгеләү.
5.2.5. Түгәрәкләрне эреләндерү.
5.2.6. Рус хезмәткәрләре өчен татар теленә өйрәтү Үзәк курслары эшчәнлеге.
5.2.7. Курс-түгәрәкләрнең уңышка ирешә алмау сәбәпләре.
**Йомгак**
**Библиография**
**Архив материаллары**

Кириллова Зоя Николаевна

# Реализация татарского языка как государственного (1920-1930-е годы)